
# Казан
# УТЛАРЫ

ДЕКАБРЬ № 12

1966



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*КЫРЫК БИШЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

**12**

**ДЕКАБРЬ**

## Бу санда:

СССР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IV СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Барган саен еллар яктырак . . . . . . . . 3

ПОВЕСТЬЛАР, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

Г. Минский. Яшенле яңгыр. Шул исемдәге повестьтан . . . . . . . . . . . 7
Х. Камалов. Лирика. . . . . . . . . . . 38
С. Сабиров. Капитаннар. Хикәя . . . . . 42
Р. Фәйзуллин. Карт һәм шагыйрь. Шигырь. 61
С. Таҗетдинов. Үлемнән яшәүгә. Документаль повесть . . . . . . . . . . . 66

СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

К. Рәхим. Көрәш еллары. Ахыры. . . 104

ЭЖЕН ПОТЬЕНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Э. Потье. Шигырьләр . . . . . . . . . . 111

ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

Ф. Мусин. Нык адым белән . . . . . . 113

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Т. Хаҗиәхмәтов. Илһам чыганагы . . . 121
Г. Ибраһимов. Яңа табылган хат . . . . . 124

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ИДЕЛ БУЕ «ГӨЛСТАН»ЫНА 575 ЕЛ

Х. Госман. Ерак гасырларның шигъри авазы . . . . . . . . . . . . . . . . 126
С. Сараи. Төрки «Гөлстан», тәрҗемәләр, назыйрәләр, шигырьләр . . . . . . . . . 131

З. МАНСУРНЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

З. Мәҗитов. Таләпчән художник. . . . . 138

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ЯНЫНА

Г. Гобәй. Минем җаваплар. . . . . . 139

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Ә. Юныска котлау . . . . . . . . . . . 152

1966 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге . . . . . . . 153

*Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-35-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

# *СССР язучыларының IV съездын каршылап*

# БАРГАН САЕН ЕЛЛАР ЯКТЫРАК

*Совет халкы партиябезнең XXIII съезды билгеләгән грандиоз планнарны уңышлы үтәү өчен киеренке көрәш башлап җибәргән көннәрдә, бөек Октябрь революциясенең 50 еллыгын, Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулуны каршыларга җыенган көннәрдә дөньядагы иң кешелекле һәм иң алдынгы әдәбиятның, күп милләтле зур әдәбиятның танылган вәкилләре ватаныбыз башкаласы Мәскәүгә җыелалар. Анда СССР язучыларының чираттагы IV съезды ачыла.*

*Совет әдәбияты үзенең халыкчанлыгы, партияле булуы белән көчле. Безнең язучылар һәрвакыт ил, халык белән бергә булдылар, һәрвакыт партиянең даими кайгыртучанлыгын тоеп эшләделәр, илһамланып иҗат иттеләр.*

*Партиянең XXIII съездында, совет язучыларының коммунизм кешесен тәрбияләүдәге мактаулы һәм шул ук вакытта үтә җаваплы бурычларына тукталып, Л. И. Брежнев болай диде: «Коммунистлар партиясе иҗади интеллигенциянең — әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең роленә һәрвакыт югары бәя биреп килде. Партиялелекнең гүзәл рухы белән, халык эшенә хезмәт итү рухы белән сугарылган совет сәнгате һәм әдәбияты коммунистик тәрбиянең куәтле коралына әверелде.*

*Бездә әдәбият һәм сәнгать әсәрләре киң халык массаларының байлыгына әверелде. Совет халкының һәрьяклап белемле, югары культуралы һәм үз иленең хуҗасы булуы — болар бөтенесе совет әдәбиятын һәм сәнгатен чәчәк аттыру өчен бик яхшы шартлар тудырды. Иң яхшы әдәбият һәм сәнгать әсәрләре совет классикасы хәзинәсен генә түгел, бәлки бөтен дөнья сәнгатен, бөтен кешелек дөньясының прогрессив культурасын баеталар».*

*СССР язучыларының III съездыннан соң узган 7 елдан артыграк вакыт илебез тормышының барлык тармакларында барган тирән үзгәрешләр белән характерлы. Партиябез Үзәк Комитеты җитәкчелектә ленинчыл нормаларны һәм принципларны яңадан тормышка кайтар-*

ды, илдәге бөтен экономиканы чын мәгънәсендә фәнни нигезгә күчерү юлында күп эш эшләде. XX съездан соң урнашкан иҗади атмосфера гел ныгый, гел яхшыра бара.

Илебез тормышындагы уңышлар әдәбиятыбыз, сәнгатебез үсешенә дә уңай йогынты ясадылар. Иҗат кешеләре өчен күрелмәгән мөмкинлекләр, яңа горизонтлар ачылды. Кыска гына бер арада әдәбият һәм сәнгать үсешендә, илебез тормышының барлык тармакларындагы кебек үк, алга таба зур сикереш ясалды. Совет әдәбиятының идея эчтәлеге, сәнгатьчә эшләнеше үсте, халык тормышы, бүгенге заман белән бәйләнеше тирәнәйде, халыкара авторитеты артты.

Моны безнең татар әдәбияты үсешендә дә бик ачык күрергә мөмкин. Язучыларның III съездыннан соң узган вакыт эчендә дистәләрчә романнар, повестьлар, пьесалар, поэмалар, шигырьләр, әдәби тәнкыйть, әдәбият фәне буенча күп санлы хезмәтләр, монографияләр язылды. М. Әмирнең «Саф күңел», И. Газиның «Онытылмас еллар», Ф. Хөснинең «Утызынчы ел», А. Расихның «Ике буйдак», Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», Ш. Маннурның «Муса», Н. Фәттахның «Бала күңеле далада» романнары, А. Гыйләҗев һәм Ә. Еники хикәя-повестьлары укучыларның мәхәббәтен казанды. Татар поэзиясенә талантлы яшьләрнең кушылуы аеруча зур шатлык хисләре тудыра. Ш. Галиев, Г. Афзал, И. Юзиев, Х. Камаловлар артыннан Р. Фәйзуллин, Р. Гатауллин, Г. Рәхим кебек яшь шагыйрьләрнең бөтен бер буыны үсеп чыкты. Проза өлкәсендә дә соңгы вакытта яңа исемнәр күренә: 1965 елда В. Монасыйпов һәм Т. Миннуллинның хикәя җыентыклары басылды. Драматургия күзгә күренерлек уңышларга ирешә. Р. Ишморат, Х. Вахит, С. Кальметов, Ю. Әминов, Ш. Хөсәенов, А. Гыйләҗев пьесалары яңа әһәмиятле темалар һәм проблемалар күтәрә, бу авторлар һәркайсы үзенчә эзләнә, куелган проблемаларына үзенчә якын килә. Бер 1966 елда гына да Татарстан китап нәшрияты йөзгә якын әдәби китап бастырып чыгарды. Аларның күпчелеге татар язучылары тарафыннан язылган әсәрләр. Соңгы вакытта Г. Гобәй, Г. Минский, С. Рафиков, И. Салахов, С. Баттал, Н. Дәүли, Г. Ахунов, Р. Төхфәтуллин, Э. Касыймов, С. Сөләйманова, Ә. Давыдов, Х. Сарьян һәм башка язучылар иҗади активлыкларын көчәйттеләр.

Ләкин эш санда гына түгел, әлбәттә. Бүгенге татар әдәбияты бертуктаусыз үсә һәм ул үсеш, беренче чиратта, әсәрләребезнең сыйфаты күтәрелү хисабына бара. Язучыларның әдәби осталыклары артты, чынбарлыкны фәлсәфи үзләштерү тирәнәйде, һәм шуның нәтиҗәсе буларак укучылар алдында татар әдәбиятының дәрәҗәсе күтәрелде. Бу — китапларның, газета-журналларның тиражларында бик ачык чагыла. Мәсәлән, «Азат хатын» журналының тиражы инде 200 меңнән артып китте. «Казан утлары» журналының соңгы ике-өч ел эчендә 14 меңнән 36 мең данәгә җитүе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Болар бөтенесе — күңелле, шатландыра торган фактлар. Ләкин алар безне һич тә тынычландырырга тиеш түгелләр. Әйе, аз эшләнмәгән, әмма эшләнәсе эшләр тагын да күбрәк. Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгы һәм В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу кебек олы тарихи даталар язучылар оешмасы һәм язучыларның һәр-

*берсе алдына тагын да җаваплырак бурычлар куя. Бүгенгенең бөекләгән һәм революцион үткәннәрнең данын сәнгатьчә югары образларда гәүдәләндерү, замандашларыбызның бай рухи дөньясын ачык һәм тулы күрсәтү, кешеләр аңындагы яңалык яралгыларын дөрес сурәтләп бирү, искелек калдыкларына һәм кимчелекләргә каршы кискен көрәш алып бару — совет язучылары алдына куелган бурычлар менә шулар.*

*Заманыбыз язучыдан тормышның иң тирән катламнарына үтеп керүне, халык язмышы, Ватан язмышы хакында чын-чынлап кайгыртуны таләп итә. Язучы профессиясе — шома юллар язу яки мавыктыргыч сюжет кору гына түгел. Ул — барыннан да бигрәк, зур гражданлык хисләре белән яну, мәңге тынмый торган борчылу. Бүген бер караш, икенче көнне бүтән карашка күчеп яза ала торган язучы укучылар ихтирамын казана алмый. Тормышны тирәнтен белү, социалистик экономиканың төп законнарын аңлау, халык белән тыгыз элемтәдә яшәү, иң югары дәрәҗәдә, Ленин аңлаткан мәгънәдәге партиялелек кенә чын сәнгать әсәрләре тудырырга мөмкинлек бирә. Язучы бары шул вакытта гына схематизмнан, иллюстрацияләүдән котыла ала.*

*Татарстан язучылары әле зур проблемаларга, актуаль темаларга теләмичәрәк алыналар. Соңгы 2—3 ел эчендә кайсы татар язучысы Партия Үзәк Комитетының соңгы пленумнарында күтәрелгән мәсьәләләргә карата олы итеп үзенең тирән уйланылган, төпле сүзен әйтте? Әйбит ул пленумнарда һәм партия съездында күтәрелгән мәсьәләләр экономикага гына кайтып калмыйлар. Алар иң элек партия карарларын тормышка ашыручы җанлы кешеләргә, характерларга кагылалар.*

*Безнең заманда объектив чынбарлыкка игътибар аеруча көчәйде. Заман белән бергә атлыйм дисәң, беренче чиратта, тормышның үзен, аның объектив законнарын тирәнтен өйрәнергә, белергә кирәк. Әйзучының урыны — чынбарлыкны өйрәнүчеләрнең алгы рәтендә.*

*Шуннан чыгып, үзенең бөтен зурлыгы белән, бер мәсьәлә — язучының партияле һәм культуралы булуы мәсьәләсе килеп баса. Хәзер фәнни һәм техник яңалыкларны күзәтеп бармаучы, фәннең төрле өлкәләрендәге ачышлар белән кызыксынмаучы, фәлсәфи белемен тирәнәйтү буенча эшләмәүче язучының үз укучысыннан һәм тормыштан артта калу куркынычы көн кебек ачык. Партия куйган бурычларны уңышлы үтәү өчен язучы кешелек дөньясы тудырган барлык белем байлыклары белән коралланган булырга тиеш.*

*Партия әдәбияттан нинди дә булса әзер тезиска яки лозунгка иллюстрация ясауны, көндәлек вакыйгаларга ашык-пошык «отклик» бирәбаруны таләп итми. Ленинчыл партиялелек позицияләрендә торып, тормышның тирән катламнарына үтеп керә белү — социалистик реализм методының нигезе әнә шул. Ә моңа ирешү исә язучының дөньяга карашына, аның тәҗрибәсенә һәм культурасына бәйле.*

*Совет язучыларына заман үзе гаять зур җаваплылык йөкли. Һәм, заман таләпләре югарылыгында тору өчен, язучылардан тырышлыкны элеккегә караганда икеләтә, өчләтә арттыру таләп ителә. Конъюнктурчылыкка, халтурага, актуальлек калканы артына яшеренеп, зәгыйфь әсәрләр бастырып чыгаруга чик куелырга тиеш.*

*Моннан 10 ел элек булган хәл белән чагыштырганда, әдәби тәнкыйтьнең, татар совет әдәбият фәненең бүгенге торышы күп яхшы, билгеле. Моны без барыбыз да беләбез, күреп торабыз. Өченче съезддан соң гына да күренекле әдип, шагыйрьләребез иҗаты турында зур-зур монографияләр язылды, борынгы татар әдәбиятын һәм татар совет әдәбиятын өйрәнүгә багышланган китаплар чыкты, әдәбиятыбызның аерым чорлары турындагы фәнни хезмәтләр дә күбәя тора. Аеруча куандырганы шул: әдәбият мәсьәләләре буенча язылган хезмәтләрнең ышандыру көче, фәннилек дәрәҗәсе артты, галимнәребез моңарчы тикшерелмәгән зур, кыен темаларга кыюрак алыналар. Бездә хәзер әзерлекле әдәбият галимнәре үсеп җитте.*

*Шулай да, тынычланырга иртәрәк әле. Җитди һәм зур уңышлары белән бергә, әдәбият фәнебезнең, әдәби тәнкыйтьнең йомшак, кимчелекле яклары да шактый. Соңгы еллар әдәбиятының төп үзенчәлекләре тирәнтен тикшерелми, үсеш тенденцияләре тиешенчә гомумиләштерелми. Әдәбият белемебез бөтенләй диярлек эшләнмәгән, фәнни-теоретик мәсьәләләргә багышланган хезмәтләр дә бик аз языла.*

*Күрәсез, әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә тикшерүчесен, өйрәнүчесен көтеп ятучы темалар, хәл ителмәгән проблемалар байтак икән.*

*СССР язучыларының IV съездында совет әдәбиятының бүгенге торышына төпле бәя бирелер, әдәбият һәм сәнгать әһелләре алдында торган мөһим бурычлар күзгатылыр. Безнең әдәбиятыбыз киләчәккә таба кыю атлый. Ә килер еллар тагын да гүзәлрәк, тагын да яктырак. Киләчәк еллар безгә тагын да зуррак уңышлар вәгъдә итә.*

—◆—

*Габдрахман Минский*

# ЯШЕНЛЕ ЯҢГЫР

*(Повестьтан өзек[1])*

Идел буе авылларына кыен көннәр килде. Күп кенә семьялар ач калды. Сукса тимер өзәрлек ирләр, эшсезлек кулларын кискәч, рәт чыкмасмы дип Суганов промыселларына юл тоттылар, көймә күтәрү доклары тирәсендә кара эш эзләп интектеләр. Эшче көченнән дә арзан, эшче көченнән дә кадерсез нәрсә калмады.

Эш эзләп килүчеләрнең саны артканнан артты. Промысел казармалары тирәләрендә, яр буендагы балык эшкәртү, тозлау чаннары яннарында эшсез каңгырып йөрүчеләр берничә йөзгә житкәч, промысел хуҗасы Тимофей Мелентьевич Суганов аккоштай баркасында үзе килеп житте.

Хуҗа белән бергә өмет килүен дә көткән балыкчылар барысы аякка калыкты, кайсы русчалатып бүрхен салып, кайсы татарча кулын күкрәгенә куеп, кайсы казакъча бил бөгеп, баш иеп хуҗаны сәламләде. Суганов аларның сәламенә игътибар итмәслек кайгыдагы кеше кыяфәтен сакларга тырышты.

— Беләм, беләм хәлегезне! — диде ул чарасыз басып торучыларга. — Ишеттем! Эшсез калгансыз. Семьяларыгыз ач утыра. Әйбәт түгел инде анысы! Әйбәт түгел! Ә мин нишли алам? Я, әйтегез, нишли алам мин? — Промысел хуҗасы, җавап көткән сыман бераз сүзсез торгач, үзенең дә алар кебек чарасызлыгын аңлаткан булып, кулларын җәйде:

— Эш сөйгән шундый алтын куллар үзләре килгән бит каршыбызга. Ә эш юк! Сезгә булган запрет миңа кагылмыймыни? Эш юк, туганнар!.. Вот беда! Миңа үпкәләмәгез! Бондарьларга үпкәләгез! Әйе, әйе! Бондарьларга үпкәләгез! Эш ташлыйлар, имеш! Забастовка! Менә нәтиҗә — бондарный завод эшсез. Бастовать итәләр, имеш. Ә кемгә китереп суга ул бастовка? Сезгә! Сезнең семьяларыгызга! Завод эшләми. Завод эшләмәгәч, таралар чыгарылмый, ә балыкны аквариумда саклап булмый аны, тозларга, мичкәләргә төяргә, рынокка озатырга кирәк. Ә алар эш ташлый! Имеш, яшәү шартын яхшыртуны сорыйлар. Күрдегезме инде хәзер яшәү шартыгызның ничек «яхшыруын»?

— Дөрес әйтә! — дип кычкырды төркем арасыннан берәү.

Суганов моны тиз ишетте:

— Ә мин сезгә тагы шундый бер дөреслекне дә әйтәм: миндә эш юк! Күрәсез бит, әнә, бер чабак та юк промыселда!

Калын, басынкы тавыш ишетелде:

— Безгә нишләргә хәзер?

---

[1] Г. Минскийның бу повесте тулысы белән Татарстан китап нәшриятында «Яшенле яңгыр» исемле җыентыкта басылып чыга.

Суганов, бик кыен сорау алдында калган кешедәй, иңбашларын күтәрде, кесәсеннән яулык чыгарып, маңгаендагы булмаган тирен сөртте.

— Полный аптыраш! Нинди киңәш бирергә дә белмим. Кулымнан килгән бердәнбер чарам — ул да булса, бала-чагаларыгыз ачтан шешенмәү өчен ярдәм итү. Анысы да кадәри хәл!

Төркем гөрләп, шаулап алды:

— Рәхмәт инде!

— Алла риза булсын!

— Спасибо, Мелентьеч!

— Дай бог Вам здоровья!

Суганов үз янында басып торган управляющиенә, барысы да ишетерлек итеп, кычкырып әмер бирде:

— Өченче лапастагы воблаларны бүлеп өләш үзләренә! Запрег беткәч түләрләр, түли алмасалар — алла хакына булыр.

Эшсезләр тагын шаулап гөрләде. Хуплау тавышлары ишетелде: «Рәхмәт!», «Спасибо!», «Аман бул!».

Суганов, ташып барган эчке канәгатьләнүен сиздермәскә тырышып, төркем эчендәге әлеге тавыш ияләрен күзәтте, менә аларның берсе төркемне ера-ера алга ук килә, бәлки монысына аерым хөрмәт күрсәтү кирәктер? Кирәк икән, күрсәтәбез аны.

Төркем арасыннан, кешеләрне этә-төртә, көрәк сакаллы берәү алга чыкты. Бу Комузәк балыкчысы Прохор Гордеев иде. Суганов бу кешене, башкалар арасында сүзе үтүчән, бик абруйлы балыкчы буларак, яхшы белә. Хәтта ул аңа «көймәсе комга терәлгән» чакларында бурычка акча да биргәли иде.

Гордеев промысел хуҗасы алдына килеп баскач, картузын алып, рус гадәтенчә, биленә тикле иелеп сәламләде:

— Яхшы кеше син, Мелентьеч! Ярдәмең өчен рәхмәт. Алла үзегезгә саулык-сәламәтлек бирсен. Шуны да әйтим дигән идем, бәлки, сез анда, калада, мин әйтәм, сөйләшеп карар идегез. Заводны эшләтү турында димәкче идем. Неужели моның бер юлы да юк?! Безгә дә бит инде, үзегез күрәсез әнә, эшсез ач утырып булмый.

Төркем эчендә тавышлар кабынды:

— Дөрес!

— Правильно!

— Булмый!

— Беләм анысын, булмый! — дип кушылды Суганов. Ул үзе дә шул хакта сүз башлануын көтте, тик ул моны балыкчыларның үз араларыннан берсе башлавын өмет итте, һәм менә өмет иткәне үз аягы белән килеп чыкты. Хәзер инде аны — үз аягы белән килеп чыккан шундый кулай кешене — ычкындырмаска һәм оста файдаланырга кирәк иде. Суганов шуңа омтылды.

— Акыллы тәкъдим әйттең бит әле син, Гордеев! — диде ул, бердән кабынган дәрт белән. — Сөйләшеп карау кирәк, әлбәттә. Минемчә, сөйләшүне сез үзегез уңышлырак башкара алыр идегез. Менә сез, Гордеев!

Төркем жанланды. Промысел хуҗасы бик күпләрнең йөзендә хуплау, килешү билгеләре күрде. Бу аны тагы дәртләндерде һәм, бүгенге газетада патша гаскәрләренең чигенүе турында укыган мәкалә кылт итеп исенә төшеп, шул газетада язганча итеп сөйләп китте:

— Кемнәр алар забастовщиклар? Алар отечествобыз өчен барган сугышта дошман файдасына уйнаучылар! Әгәр бу көннәрдә безнең гаскәрләр бер-бер артлы шәһәрләребезне калдырып чигенәләр икән, моңа забастовщиклар гаепле. Алар, әнә, сезне дә ач калдырдылар. Алар сезнең дә дошманнарыгыз. Неужели сез шуңа түзеп тора аласыз?! Неужели авылларыгыз бондарный заводны ходка җибәрү өчен эшче көче аерып бирә алмас иде?

Эшсезләр шаулашып телгә килделәр:
— Бирәбез!
— Барыбыз да чыга!
— Эш кенә булсын!
— Тоттырырлар сиңа, көтеп тор!
— Шаулашмагыз!

Тавышлар үсә барды, хәзер инде кемнең ни әйтүен аңлап булмаслык бер гөрелте купты. Ә Суганов менә хәзер, төркем тынып җиткәч, сүзне ничек отышлырак башлап китү турында уйлады. Шул чагында халык арасыннан өстенә кыршылып беткән шинель кигән берәү чыгып басты. Суганов аның бер аягы агач булуын һәм түшендә лентасы уңа башлаган Георгий тәресен күрде. Бу гарип солдатны промысел хуҗасы бик тиз күреп алды.

— Менә ул безнең каһарман туганнарыбызның берсе! Отечество өчен ул сугышта аягын калдырса, монда — тылда заводка чыгып эшләргә аның алтын кулы бар!

— Чү, тукта әле, господин Суганов!.. Мин үзем әйтием әле, — диде агач аяк.

— Әйт, ишетсеннәр алар да! — диде Суганов, кулын төркемгә таба сузып. — Әйт сүзеңне, туганым!

— Туганым да туганым. Ә мин менә синдәй бай туганымның булуын нишләптер хәтерли алмыйм.

Кемнәрнеңдер көлешкән тавышлары ишетелде.

Сугановка уңайсыз булып китте, әмма ул моны сиздермәскә тәләп, тегеләр белән бергә көлгән булды:

— Шутник син, герой!

— Юк, мин шуткасыз әйтим дигән идем. Заводта эшли алмамдыр шул. Күрәсез менә кыяфәтне. Каекка койрык тотып утырырлык кына хәлдә калдым мин хәзер. Башкача кодрәт калмады. Син менә әйт, туганым булсаң, миңа нишләргә?

— Сөйләшербез... Сөйләшербез!.. — диде көтелмәгән мондый бәйләнчекнең килеп чыгуыннан кәефе кырылган Суганов. — Монда бит бер синең кайгы түгел, әнә күпме эшсез калган ачлар...

Аннары ул янындагы управляющийга кычкырып әйтте:

— Давай өләш балыкларны үзләренә!

Управляющий, хуҗа хәйләсен тиз абайлап, агач аякның сүзен кисәргә ашыкты:

— Әйдәгез, егетләр, кемгә балык!

Барысы да управляющий артыннан иярде.

Хуҗа алдында, бер ялгызы басып, агач аяклы солдат калды.

Суганов күзләре белән ашардай булып, ачуланып карады аңа:

— Нәрсә авыз ачып торасың? Бар! Биргәнне ал! Эчеңне тишмәс!

Агач аяк тешен кысып әйтте:

— «Эт күңеле бер сөяк!» димәкче буласың инде син, ә?!

Суганов моны ишетсә дә, ишетмәгәнгә салынып атлап китте.

Өченче лапас тирәсендә балык өләшү башланды. Күпләрнең кулларында кибеп корып беткән вак вобла, тарашка тезгешләре күренде. Тезгештәге балыклар тоз шурыннан агарып катсалар да, кат-кат кайнатып чыгарсаң, теш арасына кыстырырга ярарлык иде. Бу бозык мал, кайчандыр бракка чыгарылып, сатыла алмыйча калгач, промысел хуҗасының балансында үле капитал хәлендә урын биләп ята иде. Яңа эшкәртелгән балыкларны куярга урын җитмәгән чакларда, управляющий бу үтмәс малны чүплек базына аударып, урын бушату тәкъдимен хуҗага ничә әйтеп караса да, Суганов мондый «туздыруларга» ризалык бирмәде. Дөрес эшләгән икән! Әнә, ярап та куйды. Әле нинди чакта диген. Халыкның кара көнгә калып ярдәм сорап килгән, шундый бер ихтыяҗлы чагында ярап куйды һәм промысел хуҗасына акчадан да

кыйммәтләрәк халык рәхмәтен китерде. Әшне акыл белән йөртергә кирәк икән. Суганов бу минутларда үзеннән бик канәгать иде.

Балыкчылар да хуҗа рәхименнән риза иделәр. Алар, Гордеевны чолгап алган килеш, киңәш биреп, акыл өйрәтеп, сөйләшеп-килешеп кайту өчен юлга кыстадылар. Киңәшә торгач, завод хуҗалары алдында вәгъдәләр тагы да ышанычлырак, сүзләр тагы да үтемлерәк булсын дип, Гордеевка юлдашка ике кеше дә билгеләделәр. Аларның берсе атаклы җылымчы Серкәбай казакъ, икенчесе, балыкчы исеменнән башка берние, кәегы түгел, хәтта сыңар ишкәге дә булмаган сухопайчы батрак Әҗем иде.

Суганов, шәһәргә кайтасы булгач, вәкилләрне заводка кадәр үз баркасында илтте. Завод Идел буенда урнашканга күрә, бу бик уңай да иде.

Башкалар, промысел пристане ярына җыелып, вәкилләргә хәерле юл, уңышлы килешү һәм башка шуның ише изге теләкләр теләп озатып калдылар.

Суганов, вәкилләрне завод платформасында төшереп калдыргач һәм, уңыш теләгәндәй итеп, бер-ике сүз әйткәч, мотористына «полный ход!» кушып, завод хуҗасы — иске танышы Габидулла Башкинга ашыкты.

Завод мәйданы эчне пошырыр дәрәҗәдә хәрәкәтсез калган иде. Өч балыкчының завод җиренә аяк басуга беренче күргәннәре әнә шул авыр тынлык булды. Кызылга буялган калай түбәле завод корпусларының ачылып ташланган ишекләре яңа корбаннарны йотарга көткән әкият дию̈ләренең авызларын хәтерләтәләр. Кая карама ярты-йорты өзелеп калган эш, кыршаулары чыгып, таралып яткан кисмәкләр, кыршауга киселгән юкә кабыклары, суы ислӛнгән чаннар, мүк баскан тагараклар, чыпта бүрттерү лаканнары. Бер җан иясе дә күренми. Әйтерсең, бар кеше дә бу зур биналарны, хәвеф якынлашуын сизеп, ташлап качкан. Кыскасы, өч балыкчы күңелендә нинди дә булса өмет чаткысын кабызырлык күренеш әле хәзергә юк иде монда.

Гордеев:

— Эх, булмаса булган икән, даваегыз, башта берәрне көйрәтеп алыйк, — дигәч, барысы да биек чаннар күләгәсенә чүгәләшеп, кесәләреннән тәмәке янчыклары чыгардылар һәм кәҗә сыйрагы төрделәр.

* * *

Заводчы Габидулла Башкинның өйләре шәһәрнең берничә җирендә иде, ләкин хуҗа үзе өчен Иделгә якын урында салдырган асты таш, өсте агач өйнең өске катында торды, аскы катында бакалея кибете ачып, уртанчы улы Галләмшаны сәүдәгә өйрәтергә, әгәр малай алышбирешкә сәләтле булып чыкса, коммерческий училищеда укытып, коммерсант ясарга ниятләде.

Суганов башта кибеткә кагылды.

— Әтиең өйдәме? — дип сорады ул булачак коммерсанттан.

— Өйдә.

— Нишли?

— Өйлә ашын ашыйлар.

Суганов урамнан әйләнеп ишегалдына, аннан икенче катка — кояшлы, якты верандага күтәрелде.

Биредә, кояш нурларына тулы якты чарлакта, заводчы үзенең управляющие Салтыков белән ашап-эчеп утыра иде. Хуҗаның күлмәк изүе соңгы төймәсенә хәтле ычкындырылган, җиңнәре терсәккә кадәр сызганылган, көн саен кырдырып ялтыраткан кабактай шома баш түбәсендә килешеп чигүле такыя утыра. Ул үзенең яраткан гадәте буенча кулыннан бер дә төшмәгән тастымалын йомарлаганы хәлендә әледән-әле тирен сөртә, моны ул шул хәтле яратып, бирелеп эшли, тастымаллы

кулы кызарып бүртенгән муенны урап чыгып, изүдән эчкә кереп, кендегенә кадәр бар жирен ышкып чыга. Шулай тирләп-пешеп ашап утырганда килеп кергән Сугановны күргәч, Габидулла мондый көтелмәгән кунакка гажәпләнмәкче дә иде, әмма соңгы көн вакыйгаларын хәтерләүгә, иске таныш хәл белергә кергәндер дип уйлады.

— Хлеб-соль! — диде промысел хужасы ашап утыручыларга.

— Әйдә. Мактап йөрисең икән, Мелентьеч!

— Әлегә, Габидулла Газимзянович, мактарлык эш күренми, — диде промысел хужасы.

— Һай... төкерсәнә! — диде заводчы, кулындагы тастымалын атып бәреп. — Ике-өч көнлек, күп булса бер атналык бит аларның гайрәте. Аннары шинә ул. Тагы бер-ике көн ач утырсыннар әле... Үзләре ялынып килерләр.

— Киләләр! — дип куәтләде хужасының сүзләрен управляющий һәм мәкерле елмайды, — килмәсләр иде, Мелентьеч, не куда идти, сезнеңчә әйтсәк.

— Сез алайса, туганкайлар, алма пеш, авызыма төш дип көтеп утырасыз икән?!

— Нишләргә кушасың? Барып баш ияргәме? Булмас! — Габидулланың тавышы кискен яңгырады. Аннары ул бердән тынды. — Ну, ярый, әйдә әле, утыр әле башта. Ухалап алыйкчы бер. Белуга ухасы! Зәйтүн белән. Маслина дисез сез. Теленне йотарсың, чисный слово! Ә менә монысын күрәсезме? Монысы чеснок суы!

Башкин кулындагы эчъла зат чынлап та игътибарга лаек иде. Вак күзәнәкле ефәк сеткага кидерелгән озынча шешәнең бизәкле этикетында кояшка ташланырга әзер торган арыслан сурәте, ә шешә муенындагы кәгазь тасмада өч йолдыз күренә иде.

— Шахбазов коньягы! Бакудан. Управляющий сые.

— Коньякны син берне түгел, ә менне куярсың. Соңыннан. Хәзер, даваегыз, заводыгызга ашыгыгыз. Анда сезне вәкилләр көтә?

— Вәкилләр?

— Әйе. Минем промысел эшчеләре вәкил жибәрделәр үзенә. Сөйләш тә заводыңны ходка сал.

Башкин барысын онытты: уха шулпасын да, Шахбазов коньягын да, һәм, шулай коньяк шешәсен кулында тотканы хәлендә, үзе дә белмәстән, урыныннан торды.

— Нәрсә сөйлисең син, Мелентьеч?!

— Вот шулай, туганкай! Ашык заводыңа. Сине анда көтәләр.

— Көтәләр?!

— Ну инде, ей богу...

— Хәзер, хәзер!

Габидулла, нәрсәгә тотынырга белмичә, ишекле-түрле узып, әрлебирле каранып, куяр урын тапмаган кешедәй, кулындагы коньягын кесәсенә тыкты да киенә башлады.

— Әйбәт дус булуыңа күптән ышанадыр идем мин, Мелентьеч. Друг узнается в беде, дип белеп әйткән сезнең халык! Әгәр бу эшләр барып чыгып, забастовщикларның борыннарына чиертә торган булсак, беләсеңме мин нишләрмен сиңа! Во первых, үлымә газетада сине мактап язарга кушармын, үлым редактор бит минем! Ә аннан городская дума-га да ерак түгел. Киләсе язда сайлаулар!

Суганов күзләрендә очкыннар кабынды.

— Ул көннәрне күрергә язса икән!..

— Ә нишләп күрмәскә? Кемнең кулында, шуның авызында.

Габидулла Салтыковны ашыктырды:

— Бар, жиктер атны. Живо!

* * *

Вәкилләр икенче кәҗә сыйрагын тартып бетерә язганда, капкада Салтыков күренде. Ул берни белмәгән кеше сыман, завод идарәсенә таба атлады. Вәкилләр аны тиз күрделәр, һәм теге дә күрсен өчен тамак кырыштылар. Шуннан соң гына Салтыков аларны күргән булды һәм яннарына килде. Вәкилләр аны баш иеп сәламләп каршыладылар.

— Ни кирәк иде? — дип сорады управляющий.

— Хуҗа кирәк иде! — диде Гордеев.

Капкада Габидулла күренде. Салтыков хәйран кешедәй сокланып әйтте:

— Я, хода, әйбәт күңелле кешеләр ахры сез, әнә хуҗа! Бирәм дигән колына — чыгарып куйган юлына.

Вәкилләр урыннарыннан тордылар, өс-башларын төзәттеләр. Башкин, болар янына якынлашкан саен, үткен күзләре белән һәрберсен тикшереп чыгарга да өлгерде. Өчәүнең берсе рус, икенчесе казакъ, өченчесе шул тирә авыллары нугае булуын заводчы тиз таныды.

— Я, нихәлләр бар?! — дип эндәште ул.

Сөйләшүне үзе алып барачагын аңлатып алгарак чыгып торган Гордеев җавап бирде:

— Спасибо хәл сорашуыгызга, гаспадин хозяин!

Мондый әдәпле мөгамәләне ошатуын белдереп, Габидулла елмайды:

— Ярый, спасибагызны ишеттек. Инде йомышыгызны ишетик, ни дип килдегез?

Гордеев та ачыла төште:

— Хуҗа каршына ни дип киләләр?! Әлбәттә, эш сорап...

Башкин кашларын күтәреп гаҗәпләнгән булды.

— Эш сорап?! Берәүләр эш ташлап йөргәндә, икенчеләр эш сорап... Кызык бу!

Гордеевка бу сүзләр ошамады:

— «Берәүләр» нишли торганнардыр — ихтыярлары. Без эш сорап килдек, аласызмы, кире борасызмы, дело хозяйское!

Габидулла кырыс холкын күрсәтә башлаган русның җавабыннан сагаеп үзе дә аның кебек итеп житдиләнде:

— Сорап килгәнне кире бору авыр инде аңысы. Ходай андый эшне хуплап бетермәс. Ничә кеше чыга аласыз?

— Ничә кеше кирәк?

— Кимендә өч йөз!

— Табабыз!

— Ышанам. Таба торганга охшагансың шул син.

— Югалткан чак та була.

— Җавабын да тиз табасыз үзегез.

— Кайчан чыгыйк?

— Хыт иртәгә. Казарма әзер. Урын иркен. Әнә теге ике баракны күрәсезме? Уң яктагысы семьялылар өчен. Хатын-кызларыгызны да алып килә аласыз. Эш табылыр. Тагын нинди соравыгыз бар?

— Ничек түләрсез?

— Поденный! Көнлекләп.

— Күпмедән?

— Кырык тиен. Аең унике монет. Килештекме?!

Гордеев, җавап эзләгән төсле, иптәшләренә карады, тегеләр «үзең беләсең» дигәндәй сүзсез басып тордылар.

— Килештек!

— Килешсәк, шул: иртәнге жидедә эштә булырга! Нәрсә эшләргә кирәген менә управляющий әйтер.

— Эштән кайчан туктыйбыз?

— Кичке жидедә.

— Уники сәгать була түгелме?
— Ялгышмадың.
Гордеев дәшмичәрәк торды. Аннары әйтте:
— Ун сәгать тә житкән.
— Сезгә житкән, ә миңа житми! Ун сәгать даулап, эш ташлап, ач утыралар әнә! Һай, күнелем сизә — кире кайтмагайлары. Кыскасы, озын-озак уйламагыз. Риза булсагыз сразы әйтегез. Югыйсә, тегеләр әйләнеп кайтса, хәлегез хөртиләнер.
Хужаның бу сүзләре Гордеевны өркетеп җибәрде. Ул бер кадәр каушады да булса кирәк, һәм, җавап эзләгән сыман, борылып иптәшләренә карады, ләкин бу юлы да чырайларында, ичмасам, аз гына ризасызлык чагылуын да күрмәгәч, ачуы килде. Торалар шунда сарыклар төсле басып. Картның бердән ачуы купты һәм ул Башкинның күзенә туры карап кырт кисте:
— Ярый!
Габидулла үзен тыныч тотарга тырышты:
— Ярый дисез икән, без дә ярый дибез. Иртәдән эшли башлагыз! Ике-өч көннән, әгәр тырышып эшләсәгез, аванс биреп тә булыр. Икмәген-тозын үз кибетебездән бурычка алырсыз.
Бу юлы Гордеев кына түгел, Серкәбай белән Эҗем дә авыз эченнән «рәхмәт!», «спасибо!» диештеләр. Башкинга ошады бу. Димәк, болар ихлас күнелдән риза булып килүчеләр, ә аңа эшчеләрнең шундые кирәк.
Завод хужасының чырае ачылып китте, нинди булса да бер яхшылык эшләүче кыяфәтендә күренәсе килде аның. Аһа, көмеш портсигардан папирос өләшергә үзләренә. Габидулла, кесәсенә тыгылуына, кулын алырга да алмаска да белмичә, шулай бер секунд гаҗәпләнеп басып торды. Кем куйган кесәгә аны? Боларга насыйп ризык булды микәнни?
— Хезмәт сөйгән кешеләр дип күнелем дөрес сизгән. Шуна күрә буш кул белән килмәдем. Өчәү бит әле сез? Менә монда да өч йолдыз, — диде ул кесәсендәге коньякны чыгарып, — борын башына бирәрдән! Тот, тамада! Гордеевмы әле син? Акыллы башка охшагансың! Не жалко!
Көтелмәгәнчә күнелле килеп чыкты бу. Хужаның бу тикле үз кеше булуын күргән Гордеев бөтенләй ачылды. Рәхмәт артыннан рәхмәт яудырды аңа.
Башкинга да күнелле иде. Дөрес, коньякны Гордеевның кулына тоттырганда, күнеленең кайсыдыр бер кырые сулкылдап алды алуын, әмма хужа моны тиз басты. Шундый зур эш башлаганда нәрсә ул бер шешә коньяк! Әйдә, сәдакасы булсын!

* * *

Идел буе балыкчыларының заводчы Башкин белән килешү хәбәре Бирге бистә кешеләренең теленнән төшмәде. Кайберәүләр бу эшне хуплап, безгә дә шулай эшләргә кирәк, диделәр.
Икенче берәүләргә мондый «килешү» ошап бетмәде.
Әле шушы көннәрдә генә уен кибетендә укылган листовканы тыңлаганнар, колакларына кереп калган сүзләрне хәтерләп, бу килешүнең кара халыкны алдауга корылган хәйлә икәнен әйтеп бәхәсләштеләр. Тик бу бәхәсләрдә Мохтар тамаданың катнашмавы күпләрнең эчләрен пошырды, югыйсә, атаклы балыкчының киңәше бик кирәк иде хәзер. Ник чыкмый ул җәмәгать янына? Ник килеп берсүз әйтми?
Икенде чагы иде. Мохтар агай өенә Габдерәшит килеп керде.
— Хәлләр ничек, Мохтархай?!
«Күреп торасың бит. Нәрсәсен сорыйсың?» дигән сыман Мохтар агай чырай күрсәтмәде.
Габдерәшит аның хәзерге кичерешен тиз аңлады.
— Күренмисең. Өйдән дә чыкмыйсың, шуңа әйтүем.

— Син чынлап та хәл белергә килдеңме, әллә башка бер-бер хәл бармы?

Балыкчыдагы үҗәтлек Габдерәшиттә дә бар иде, һәм ул нәкъ Мохтар агайның үзенчә кырыс итеп әйтте:

— Мин үзем килмәдем. Минс җибәрделәр.

— Җибәрсәләр, боргаланмый-сыргаланмый гына сөйләш.

Габдерәшит көч-хәл белән чыдап әйтте:

— Комүзәхнекеләр заводка эшкә чыгалар ди. Сине дә Башкинга барып сөйләшеп карамасмы икән диләр. Гласный бит. Күлләрдә генә балык тотарга булса да рөхсәт алып бирсен иде. Син бу эшкә ничек карыйсың, тамада?!

Мохтар агай кырт кисте:

— Берничек тә! Мин адбакат түгел.

— Зәйнетдин мулла да шуны мәгъкуль күргән, — диде Габдерәшит.

— Мәгъкуль күрсә, үзе барсын!

Бу хакта артык сүз көрәштерүгә урын калмавын анлатып, Мохтар агай урыныннан торды.

— Бондарьлар бастовать итеп ач калдырдылармы? Калдырдылар! Кеше коткысына алданып йөрмәгез! Минем сүзем шул булыр: безнең дин мондый эшне хак күрми. Сабыр иткән — морадына җиткән! Сабыр итәргә кирәк.

Габдерәшит тагын әйтеп карады:

— Корсак дигәнең сабыр итми икән ул. Икмәк сорый...

— Икмәк кирәксә, алладан сора! — дип кычкырды тамада.

Урам чатында җыелган эшсезләр Габдерәшитне дүрт күз белән көтеп алдылар. Ул әле килеп тә җитмәс борын, арадан берсе түземсезлек белән сорады:

— Я, ничек? Күндеме?

— Күндерерсең!

— Нәрсә ди?

Габдерәшит балыкчының җавабын аның үзе булып кабатлады:

— Икмәк кирәксә, алладан сорагыз!

Нургали агай күренде. Карт бондарь ашыккан да, каһәрләнгән төсле дә атлап килә иде. Сирәк хәлләрдә генә булганча борчулы үзе. Кешеләр моны аның күгәргән иреннәреннән күрделәр. Ул җитә-җитүгә Габдерәшиткә ташланды.

— Син нәрсә! Башкинның маклеры булдыңмыни?! Маклер булсаң, ат базарына бар!

— Син үзең бар анда! — диде үртәүле тавыш белән Габдерәшит. — Беркөн дә бит сине азгын атка охшатып бик дөрес эшләгәннәр...

Нургали беркөнге Мохтар белән булган бәхәсне һәм карт балыкчының сүзләрен хәтерләп эчтән хурланды.

— Кеше ни генә эшләмәс! — диде ул. — Син дә бит әнә аңламаган башыңа Башкин тозагына кабарга йөрисең икән...

— Йөреп мин нишләгән?!

— Кара аны! — диде кисәтүле тавыш белән Нургали. — Башкин алдына барып забастовканы өзәргә җыенуыгызны аңлыйсызмы сез, юкмы?

— Монда бит, Нургали агай, сүз бастовка турында бармый, икмәк турында бара, — диде арадан берәү.

— Әйе! -- дип эләктереп алды икенчесе һәм сорап та куйды: — Икмәкне кем бирер?

Нургали бу сорау иясенә таба борылды:

— Икмәкне кем бирер дисеңме? Әйтеп җибәргән ич әнә тамада: алладан сорарга кушкан. Көтеп тор... авызыңны ачып, күккә карап... икмәк яуганын...

Габдерәшит күкерттәй кабынды:

— Аллага тимәгез! Аллага тимәгез!! Җаным корбан китсә китер, аллага сүз тидертмәм.

Төркемдәге башка берәүләр Габдерәшитнең алланы яклап кычкырган сүзләреннән кабына башладылар. Ләкин Нургали курка торганнардан түгел иде. Киресенчә, Габдерәшитнең кызарынып-бүртенеп черелдәгән тавышка җикеренүе бондарьның ачуын гына кабартты.

— Әтәчләнмә! — диде ул, — Кузьма ишетмәсен. «Менә нинди герой икән» дип солдатка озатыр үзенне...

Бу сүз тегеләй дә куркак Габдерәшитне бик тиз басылырга мәҗбүр итте. Дөрес, ул бу бәхәстә Нургалине җавапсыз калдырырга да теләмәде. Ни булса да әйтү кирәк иде аңа хәзер, әмма чәнечкеле үткен сүз таба алмавына борчылды. Нәкъ шулай җайсыз хәлгә кала барган чагында, мәчет манарасыннан Садыйк мәзиннең икенде намазына кычкырып азан әйтүе ишетелде. Бар җирдә дә һәртөрле эш-хәрәкәт, сөйләшүләр, шәригать кушканча, бердән өзелде. Шул беркадәр Габдерәшитнең хәлен җиңеләйтте. Ул, баскан җирендә чүгәләп, азан тыңлады.

Азан әйтелеп бетеп дога кылынгач, Нургали, өзелеп калган бәхәсне түгәрәкләгәндәй итеп, болай диде:

— Кирәкми мондый эшләр, егетләр! Яхшыга илтмәячәк алар... Әйткәнебез булсын, Башкин заводына беркем эшкә чыкмаячак. Аңлыйсызмы — беркем!

Шул ук кичне Зәйнетдин мулла ашык-пошык ястү намазыннан кайтты да, чалма-чапанын алыштырып киенгәч, зур көзге алдына килеп басты. Кыяфәт әйбәт иде: әнә, көзгедән казакъ баена охшый төшкән түгәрәк йөзле, шешмә кабаклы, имәндәй базык гәүдәле, тоташтырып түгәрәк кырылган чем кара сакал-мыеклы Зәйнетдин мулла карап тора. Өстә мәхмәл якалы яңа пальто, башта каракүл бүрек, пальто якасы эченнән күренеп торган жилетне бизәп алтын сәгать чылбыры сузылган, кулда нәкышле көмеш башлы трость. Үз кыяфәтеннән бик риза иде ул хәзер. Юк, бу кыяфәтне Бирге бистәдәй шайтан оясында яшәүче гади татар мулласы дип булмый, бу кыяфәттә европалы сыны бар...

Үз-үзеннән риза булгач, Зәйнетдин мулла, сөенче алырга ашыккан кешедәй, кызу-кызу атлап чыгып китте.

Башка вакытларда халык арасында булып кыланган һәм шуңа оста гына ирешә дә алган бу кеше хәзер исә ят күзләргә күренергә теләмәде, трамвайның алгы баскычыннан менеп, ишек белән урталай бүленгән алгы ягында — беренче классында урнашты. Монда билет бәяләре ике тиенгә кыйммәт булганга тыныч та, аулак та иде. Бу вагонда уйлары белән ялгызы калгач, булачак очрашуга әзерләнде ул. Мондый хәлне һич кенә дә игътибарсыз калдырырга ярамый. Тизрәк барып җитәргә дә шул турыда хәбәр итәргә ашыкты ул.

Трамвай аны аптека чатына китереп төшерде. Моннан шәһәр башлана иде. Чатта фонарьларын яктыртып тезелешеп торган извозчикларның берсенә менеп утыргач, кузла башындагы абзыйга атын куарга кушты.

— Кая илтәбез?

— Пятый бакалга.

Кызыл фонарьлы йортлары белән яманаты таралган урам исемен ишеткән абзый киная ясады:

— Гулять сугарга дисең икән алайса.

— Нинди «гулять» булсын, дурак. Башкин йортына, — диде мулла.

— Но-о, хайван! — диде абзый.

Җиһазлы, иркен, якты кабинет түрендәге өстәл артында утырган полковник килүчеләрне ачык чырай белән каршылады.

— Рәхим итегез, рәхим итегез, хөрмәтле Габидулла Газимзянович, — диде ул алдан атлап кергән заводчыга, аннары авыз кырыйларында елмаю чагылдырып Зәйнетдин муллага карады. Күргән-белгән кешесе булмаса да, иске танышсай елмаеп сәламләшкәч, ефәк тышлы диванга күрсәтте.

Бу губернатор Никанор Андреевич Соколов иде.

Габидулла мондый нәзакатлеккә нәзакатлек белән җавап бирсп бөгелә-сыгыла рәхмәтен изһар кылгач, йомшак келәм өстеннән тавышсыз атлап, күрсәтелгән урынга узды. Зәйнетдин мулла да, ана каздай, Габидуллага ияреп диван кырыена килеп утырды.

Губернатор кунакларга сигара тартмасын сузды. Кунаклар утырган җирләреннән күтәрелә төшеп тәшәккер иттеләр һәм андый әйбер белән шөгыльләнмәүләрен аңлаткан сыман елмаештылар. Губернатор сигараның бер очын кайчы белән кисеп авызына капкач, шырпы яндырып озак кына кабызды. Габидулланың күзләре аның хатын-кызныкыдай кабарынкы кулык, чәнчи бармагындагы йөзегенең шырпы ялкынын чагылдырып җемелдәгән бриллиант кашын күрде. Сокландырды бу мут заводчыны.

Губернаторның кыяфәте чынлап та сокландыргыч иде. Мәһабәт гәүдәсенә күрк өстәгән кителе түшендә берничә орден тәреләре, ә иңбашлары укалы погоннар белән бизәлгән иде. Мыек очлары патшаныкына охшатып очландырып борылган, янынаан духи катыш сигара исе аңкып торган, түгәрәк сакаллы, алтмышка житеп килүенә дә карамастан, яшь күренергә тырышкан һәм шуңа ирешә дә алган кеше иде.

Менә ул сигарасының сыек яшел төтенен сузып өрде дә завод хуҗасына мөрәҗәгать итте:

— Тыңлыйм сезне, хөрмәтле Габидулла әфәнде.

— Галиҗәнаб Никанор Андреевич, — дип башлады заводчы сүзне, — бу кеше безнең итагатьле дин әһелләребездән Зәйнетдин мулла була. Мин аны сезнең хозурыгызга алып килдем. Аңарда безем өчен игътибарга лаек хәбәр вә фикерләр бар. Ул безем бик ышанычлы һәм укымышлы мулламыз.

Губернатор, сез әйтмәсәгез дә аның әйбәт кеше икәнен күреп торам дигәнне аңлатып, баш иде һәм Зәйнетдин муллага карады.

Зәйнетдин мулла, юлда килгәндә Габидулла белән план корганча итеп, губернаторга балыкчы Мохтар турында сөйләргә керешә:

— Әйе, әйе, — дип эләктереп ала торды Габидулла аның сүзләрен, — «Икмәкне алладан сорагыз, сабыр итү кирәк!» дигән бит ул! Ә ул кешенең сүзе безнең бистәдә, ваше превосходительство, алтыннан да кыйммәт.

— Сез татарлар арасында да яхшы күңелле кешеләр барлыгы турында ишетеп белә идем мин, — диде губернатор.

— Бик дөрес, галиҗәнаб Никанор Андреевич! Мөселман баласы динне бер дә бозмас ул, ә безнең дин ярамаган эшләргә запрет куя.

— Бик дөрес эшли! — диде губернатор, — безнең бурыч әнә шуны кара халыкка аңлатып биру. Мондый вакытта Мохтар кебекләрне урнәккә алырга кирәк. Молодец, Мохтар! Истинный магометанин!

— Бик дөрес әйтәсез, галиҗәнаб Никанор Андреевич! Шуңа күрә менә муллабызның башында бер бик мәгънәле фикер туган икән, әгәр рөхсәт итсәгез.

— Фикер?! Я әле, сөйләп күрсәтегезче, нинди фикер булды икән, — губернатор бердән елмайды, — берәр крамола түгелдер, надеюсь?

— Аллам сакласын! Бәндәгез государственный чалавик, галиҗәнаб Никанор Андреевич.

Губернатор ничек бердән шаяруга күчкән булса, шундый ук кинәтлектә янадан житди хәленә кайтты.

— Сөйләгез, господин мулла, бик теләп тыңлыйм сезне.

Зәйнетдин мулла урыныннан торды һәм, солдатларча үрә катып баскач, әлеге фикерен сөйли башлады:

— Балыкчы Мохтарның изгелегенә изгелек белән җавап бирү лазым безгә, ваше превосходительство!

Никанор Андреевич бу сүзләрдә тирән мәгънә абайлавын белдерде:

— Шулай, шулай! Аңлыйм сезне! Сөйләгез, сөйләгез!

— Ул бит забастовщиклар вәкилен «кеше коткысына алданып йөрмәгез!» дип борып чыгарган. Динебезнен иң зур тәрәкләреннән сабырлыкны телгә алган. Тегеләр икмәк дигәч, икмәкне алладан сорарга кушкан!.. Моны бит мин — указлы мулла түгел, ә надан бер балыкчы әйткән!

Габидулла тагы эләктереп алды:

— Бу бит заслуга, галиҗәнаб Никанор Андреевич!

Губернатор мондый фикерне тулысынча хуплавын аңлатып урыныннан торды һәм, өстәле артыннан чыгып, болар янына килде:

— Заслуга, заслуга, хөрмәтле Габидулла Газимзянович! Сез аңа минем рәхмәтемне җиткерегез...

— Рәхмәт кенә җитми, галиҗәнаб Никанор Андреевич, — диде Габидулла, губернаторны аягүрә каршылап.

— Ә сез бик алай ашыгыч йомгак ясамагыз, господин Башкин.

Бу юлы инде Габидулла губернаторның тел төбендә нәрсә ятуын белергә ашыгып түземсезлек белән көтеп торды.

— Әгәр дә инде, хөрмәтле әфәнделәр, — диде губернатор, — Мохтар кебек атаклы берәү чернь[1] коткысына бирелмичә сабыр итә икән, әлбәттә, үзе әйткән морадына җитәргә тиеш! Мин моны шулай аңлыйм.

Габидулла гаҗәпләнеп тә, шатланып та бетерә алмады. Губернатор ул уйлаганнан да тирәнрәк уйлый лабаса!

— Моның белән без, господин мулла, — диде губернатор, — берьюлы ике куян тотабыз.

Тегеләр икесе дә киңәяне төшенә алмыйча тордылар.

— Сабыр итүнең нинди кодрәтле көч, алладан сорауның нинди изге эш булуын тагын бер кат күрсәтәбез. Монысы — бер! Кара халыкны коткыга бирелүдән саклыйбыз. Монысы — ике!

Шушы сөйләшүдән соң, «кара халыкны коткыга бирелүдән саклау»ны ничек оештыру турында яңадан-яңа акыллы һәм кызыклы фикерләр туды.

* * *

Җомга көн иде.

Мәктәптән балаларга: «Әтиләрегез, абыйларыгыз җомга намазына килсеннәр. Мулла хөтбә сөйләячәк», дип әйтеп кайтардылар. Моның белән генә чикләнмичә, кайбер «бинамаз җаннар»га аерым хәбәр иттерү өчен мәчет сакчысы Габдулла диване да чыгарып җибәрделәр. Шуңа күрә бистәдәге җиде мәчетнең иң зурысы — Камышлы мәчетнең бар җире, югары сәндерәләренә кадәр җомга намазына килүчеләр белән тулып калды.

Намаз укылып, муллага оючылар уңга, сулга «әссәламегаләйкем, ярхәмәкәллә»ны әйтеп дога кылгач, мулла михрабтан мөнбәргә күчте.

Хөтбә үтемле, тәэсирле яңгырасын өчен, күп кенә гыйбрәтле сүзләр китерелде. Мәкамы белән үз мәхәлләсендә генә түгел, ә тирә-якта да даны таралган Зәйнетдин мулланың бүгенге хөтбәсе мәчет әһле картларыны эретеп җибәрде. Ул башта ислам дине кушмаган, шәригать тыйган эшләргә тукталды, андый эшләрнең мөселман баласы өчен олуг гөнаһ булуын әйтте, бакый дөньяны онытып, фани дөнья кәефенә бирелүдән сакланырга, түземле һәм сабыр булырга өндәде.

[1] Кара халык.

— Шайтан васвасасенә бирелүдән сакланыгыз, җәмәгать! Иблис ләгыйнь әйткән: мин, дигән, адәм баласын һәмишә бозык юлга өстерәрмен. Ярлыны байга, явызны ходайга каршы куярмын. Колны хуҗага каршы котыртырмын, дигән. Шундый бозык юлга басып азып китүдән сак булыгыз, җәмәгать! Ходай тәгалә вә табаракә хәзрәтләре «сакланганны саклармын» дигән. Ходай каршында баебыз да, ярлыбыз да, эшчебез дә, хуҗабыз да бертигез. Барыбыз да ходай коллары! Габидулла әфәнде заводы эшчеләренең, шайтан васвасасенә бирелеп, эш ташлауларын якларга теләүче коткычылар безнең мәхәлләдә дә бар дигән хәбәрләр йөри. Габидулла әфәндеме ул, я булмаса Суганов әфәндеме, диннәре башка булса да, гамәлләре бер: ходай кушканны эшләү, чөнки алар да ходай колы. Безнең ризыгыбыз ходай кулында. Мохтар карт: «Икмәк кирәксә, алладан сорагыз!» дип әйткән икән — бик дөрес әйткән! Мондый дөреслекне Мохтар карт күңеленә ходай үзе салган. Димәк ки башкасын да көтәргә кирәк ходайдан. Сабыр иткән — морадына җиткән! «Әссабыр рәхман, биссабыр шайтан!» ди коръән. Без дә сабыр холыклы Мохтар картның морадына житүен ходайдан сорап бер дога кылаек, җәмәгать!

Барысы да дога кылу өчен кулларын күтәргән хәлдә түшәмгә карап «амин!» көттеләр.

Мәхәлләнең ике атаклы кешесе — бондарь Нургали белән балыкчы Мохтар, күп еллар инде, мәчеттә гел бергә, бер алгы сафта булдылар. Менә хәзер дә янәшә утырганнары хәлдә кулларын догага күтәргәннәр.

Нургали агай элек-электән намазны башкаларга ияреп укыды, дөресе — үтәде. Әлхам, көлһевалла кебек вак сүрәләрдән башка берни белмәгәч, аннары, иртә-кич эштә булгач, биш вакыт намазны калдырса да, әмма, җомга намазын бер дә калдырмады. Бу намаз карт бондарьга бала чагыннан ук ниндидер бер изге бәйрәм тантанасыдай күренде һәм ул шуңа гадәтләнеп китте. Җомга намазын калдыру түгел, киресенчә, көтеп ала торган булды ул аны.

Хәзрәтнең сузып әйткән «амин»ы ишетелде. Мәчет әһле «амин»ны күңелләреннән кабатлап дога кылдылар.

— Амин, Мохтар, амин! — диде Нургали ярым тавыш белән күршесенә. — Бу доганың кабул булуын бик теләр идем мин...

Мохтар дәшмәде. Ана Нургали бу догага ышанмыйча көлеп карый төсле сизелде. Мондый көфер уеннан үзе дә өркеп, авыз эченнән тәүбәсен әйтте.

Бистә эчендә күпләрне таң калдырган хәбәр таралды. Әгәр кем дә кем кызыл кар яуган дисә, бу тикле көтелмәгәнчә булмас иде.

— Зәйнетдин мулланың догасы кабул булган! Мохтар агайга ходайның рәхмәте ингән!

Бу хәбәрне ишеткән карты-яше, хатын-кызы шау килде. Хәтта бу хәбәрне ишеткән Нургали агай үзе, ышанырга-ышанмаска да белмичә, аптырап калды.

— Мохтар агайга Иделгә чыгарга рөхсәт килгән. Рөхсәтне губернатор биргән, ә губернаторның күңеленә ходай тәгалә үзе салган, ди.

— Я, хода, кодрәтең киң синең!

— Сабыр итәргә, алладан сорарга кирәк!

— Алладан сорау өчен элек сәдакасын биреп савабын алырга кирәк.

— Камышлы мәчет мулласын «изге җан иясе», «әүлия» дип сөйлиләр иде, дөрес икән!

Барысы да Камышлы мәчет мулласына сәдака бирергә, догасын алырга ашыкты.

Икенче көн иртәсендә чыккан газеталар мондый «изге эшләр» турында хәбәрне бөтен шәһәргә, ә кичкә таба Идел буе авылларына таратып өлгерде.

Шәһәрнең татар байларын берләштергән Милли идарә органы «Аваз» һәм кадетлар газетасы «Голос отечества» битләрендә эчтәлекләре белән берсе икенчесенә охшаган мәкаләләр басылды. «Аваз»дагы «Дога кабул булды» исемле мәкаләдә балыкчы Мохтар сабырлыгына багышлап җомга намазында Зәйнетдин мулла кылган доганың кабул булуы язылса, «Голос отечества» битендәге «Суганов әфәндened изге нияте» исемле мәкаләдә забастовщиклар коткысына бирелеп ач калганнарга промысел хуҗасының ярдәм кулын сузып, бушлай балык өләшүе язылган иде.

Мәкаләләр икесе дә бер мәгънәдәге фикер белән очланган: «Инсанны байга-ярлыга аерып, милләтне икегә бүлеп, хезмәтчене хуҗага каршы куеп дошманлык тудырган большевиклар яхшы белсеннәр, эш алар уйлаганча бай белән ярлыда түгел! Эш — түземлелектә, сабырлыкта, золымны игелек белән җиңүдә. Күрәсез әнә, бай хуҗа Суганов әфәнде дә, ярлы балыкчы Мохтар әфәнде дә, бер дин кешеләре булмасалар да, ходай юлыннан язмаганнар, изге эш күрсәткәннәр. Изге эшне изгелек белән кайтарырмын дигән алла. Мохтар карт кебек сабыр вә түземле булыгыз!

Афәрин сезгә, Мохтар!

Газета укучыларымыз хәерле юл тели сезгә!!»

Шул көннең кичендә, Җамал апа өендә, кечкенә җыен чакырылды. Бу җыенга, комитет күрсәтүе буенча, Андрей бары ике кешене — Касыйм белән Петяны — чакыртты. Бер чара турында гына һәм бик кыска сөйләшү кирәк иде.

Касыйм беренче булып килеп керүенә Андрейның чыраеннан, җыерылган кашлары, тырпайган мыегыннан ук аның никадәр борчулы булуын күреп өлгерде.

Петя да килеп җитте.

Андрей ике егеткә аларны ни өчен чакыртуын әйтте:

— Бүгенге газеталарда басылган провокацияне фаш итәргә кирәк. Комитет карары шундый! Бу карарны үтәүне безнең группага тапшырдылар. Конкретно менә сиңа, Касыйм! — Андрей Касыймга карады, аннары Петяга төбәлде: — И сиңа! Кыскасы, өчебезгә! Ничек, кайда фаш итәргә, дисезме? Газета битендә! — Андрей тегеләрнең йөзенә чыккан гаҗәпләнү билгесен күргәч, кабатлап әйтте. — Әйе, әйе, газета, бары тик газета битендә! Андрей тагы Касыймга борылды: — Беләсеңме, Касыйм, кайсы газета битендә? «Аваз»да!

Ялгыш ишеттемме әллә? дигән төсле Касыйм бер сүз әйтә алмыйча торды. Андрей елмайды, моның белән ул Касыймдагы көчәя барган киеренкелекне куарга теләде.

— Я, наборщик, менә син ничек карыйсың?

Касыйм Андрей әйткәннәргә күнегә алмыйча аптырады:

— Бик кыен эш бит бу!

— Хәтта, мин әйтер идем, — диде Андрей, — кыенның да аръягына чыккан хәвефле эш...

— Чөйне чөй белән бәреп чыгару була бит әле бу! — диде Петя да бу фикерне хуп күреп.

Андрей Петя сүзләрен тотып алды:

— Менә, менә! Чөйне чөй белән! Аңладыңмы инде хәзер? «Аңладым» дисең икән, менә сиңа газетага урнаштырылырга тиешле мәкалә. Аны Петя бүген үк Хәйдәргә биреп тәрҗемә иттерсен. Горькийны «тәрҗемә» иткәнчә эшләсен, берәр куплет, ягъни җыр-фәлән уйлап чыгарса бик тә әйбәт булачак. Комитетта ул егет белән безгә бик ныклап шөгыльләнергә кушалар. Дальше тыңлагыз! Хәйдәр мәкаләне язып әзерләгәч,

иртүк Аргы бистәгә Хәбиб Шәрәфкә илтер... Син, Касыйм, бернәрсә эшләмәскә, калганын Җамал эшләр. Ул синә Хәбиб әзерләгән наборны әбәткә килгәндә китерер. Верстка сездә әбәттән соң башлана бит әле? Менә шул верстка — эшнең иң тәвәккәле һәм хәвефлесе сиңа тапшырыла. Аңлашылдымы?

Ике егет үзләренең аңлаганнарын раслап ым кактылар.

* * *

Теге көнне Җамал квартирасында Хәйдәргә таныш кебек күренгән кеше Хәбиб Шәрәф иде. Тулы исем фамилиясе — Хәбибулла Шәрәфетдинов. Ике-өч ел элек ул татар телендә чыккан «Дулкын» газетасының редакторы булып эшләде. Фамилиясенең әдип-мөхәррирләргә хас булганча кыскаруы да шул редакторлык эшчәнлегенә бәйләнгән. Белеме белән педагог, гаҗәп гадел күңелле, Герцен, Чернышевский әсәрләрен яратып укыган, үз халкын гел үсештә күрү хыялында янган бу озын буйлы ябык кеше социал-демократлар хәрәкәтеннән читтә кала алмады. Дөрес, ул яшерен группаларда катнашмады, әмма редакторлык иткән газетасында шул хәрәкәткә теләктәш фикерле мәкаләләр язып торды. Тик бу озакка бармады. Бердән көчәеп котырган Столыпин реакциясе «Дулкын» газетасын пыран-заран китерде. Газетаны яптылар, нәшире Сөләйман Шакировны сөргенгә озаттылар. Бәхетле очрак Хәбиб Шәрәфкә җил-давыл тидертмәде. Шуннан соң аңа үз кешеләр күз алдыннан югалыбрак торуны мәслихәт күрделәр һәм кыен көннәрендә матди ярдәм дә күрсәттеләр. Бу хәл аны типография наборщигы Касыйм, ә Касыйм аркылы шәһәр большевиклары белән туганнардай якынлаштырды.

Шулай итеп, Хәбиб Шәрәф Аргы бистә мәктәбенә укытучы булып килде. Килгәндә ул буш кул белән килмәде. «Дулкын» типографиясен туздырган вакытта яшереп калган бераз хәреф һәм бәләкәй кул машинасы да китерде. Аргы бистә мәктәбенең утын подвалында яшерен типография туды.

Хәбиб Хәйдәрне шул подвалга алып төште.

— Караңгы икән монда. Абынып егылмыйк.

— Егылмабыз. Бир кулыңны. Хәзер якты ясыйбыз, — диде Хәбиб һәм барып тәрәзәгә корылган сәләмәләрне алды. Әчкә салкын яктылык сирпелде.

— Я, ничек?

— Күреп була. Үзебезне күрмәсләр бит?

— Күрмәсләр.

Хәйдәр, аягындагы сандал олтырагы астыннан алып, Хәбибкә дәфтәр бите язма бирде.

Хәбиб Шәрәф егетнең мондый тапкырлыгына башын чайкап гаҗәпләнде.

— Тапкансың үзең кая яшерергә!

Хәйдәрнең күңеле үсеп китте. Ул тагы да житдирәк төс алды һәм бер сүз белән генә җавап бирде:

— Конспирация!

Хәбиб елмайды. Хәйдәр моны күрмәде.

— Үзегез карарсыз инде, — диде Хәйдәр, китәргә җыенып, — анда бер шигырь кебегрәге дә булыр, килешмәгән җирен үзегез төзәтерсез.

Хәбиб киң итеп елмайды:

— Килешкәндер әле, бик килешкәндер! Я, бар, алайса, син алдан чык!..

\

«Аваз» газетасы басылган Мирзоян типографиясендә әбәт вакыты керүгә пәрәмәч тулы кастрюлен күтәреп Җамал солдатка килеп житте.

Наборщиклар солдатка апаны чолгап алдылар. Һәркайсының кулында кабарып пешкән пәрәмәчләр. Акчасы булганы акчага, булмаганы көтәргә ала.

Касыйм ашыкмый. Аңа Җамалның ялгыз калуын көтәргә кирәк, һәм көткән чак килеп тә житә. Касыйм пәрәмәч сатучы янына килә. Бер минут. Җамал кулындагы төргәк, пәрәмәч белән бергә, Касыйм кулына күчә.

Әбәт бетә. Иртәгә чыгасы газетага верстка башлана. Материалларны биткә салалар. Верстканы Касыйм ясый. Башта ул, гадәт кушканча, наборны чәчелмәсен өчен юеш чүпрәк белән чылата. Бу аңа материалларның күләмнәрен күздән кичерү өчен дә кирәк. Менә шундыйларның берсе. Моны Хәбиб «типографиясендә» әзерләгән набор белән алыштырып булачак. Тик кайчан алыштырырга? Версткадамы, әллә соныннанмы?

Версткадан соң битләрне редактор үзе карый. Димәк, бу эшне редактор оттисканы карап чыгып кул куйгач кына башкару хәвефсез. Аннары басу машинасына. Печатьник Федя үзе болай әйбәт кенә кеше дә бит, ләкин бу эштә берәүгә дә ышанырга ярамый. Касыйм үзе верстка алып бара, үзе шул турыда уйлый... Менә беренче битнең версткасы бетте... Икенче бит тә жыелып бәйләнде, материал өченче биткә керергә тиеш. Өченче бит тә тәгәлләнде...

Верстка бетте. Оттискаларны, корректор карап чыккач, редакторга жибәрделәр. Барысы да әзер, күп булса ярты сәгатьтән набор үз урынына кереп утырачак. Редактор укып чыккан битләр кайта тордылар. Кагыйдә буларак, басу машинасына иң элек беренче белән дүртенче битләрнең полосалары бирелә. Бу Касыйм башкарачак эшне беркадәр жиңеләйтте. Менә ул кулына без алды да калган ике полоса наборын соңгы тапкыр карап чыккан булып өстәл янына килде. Федя машинаны көйли башлады. Иң киеренке чак туды. Касыйм өченче полосаның наборларын каккалаган-суккалаган булып, алыштырыласы материалны чыгарып алганда гына башы өстендә: — Нишлисең? — дигән тавыш ишетелде. Йөрәге жу итеп китте. «Элэктенме» дигән төсле елмаеп карап торган күрше наборщик бер шиктән икенче шиккә салды аны. Ник елмая ул? Күреп тордымы икәнни? Касыйм да елмайды һәм үзе тегеннән сораган булды:

— «Нишлисең» дисеңме? Күрмисеңмени, утын ярам?

Күрше кәефләнеп көлде:

— Молодец, жавапны таба алдың! Кайтмыйсыңмы? дип сорамакчы идем.

Касыймның күз аллары яктырып китте.

— Менә тагы ике битне машинага бирәсе бар, — диде ул һәм тагы үз эшенә чумган булды...

* * *

Хәйдәрнең кайтып кергән чагы иде, Искәндәр килеп житте.

— Хәйдәр кахам[1] әтием чакыра!

— Нигә чакыра?

— Әйтмәде.

Мәрьямдә кинәт өмет чаткысы кабынды:

— Чакыргач бар, тиккә чакырмас кеше.

Яшь хатынның уйлары яктырып китте. Белмәссең, бәлки Мохтар агасы Хәйдәрне балыкка алып чыгарга чакыргандыр. Шулай була күрсен иде! Беркемгә килмәгән бәхет бит бу. Мохтарга алла үзе иидергән

[1] Кахам — абыем.

бит ул бәхетне. Хәйдәрне чакырткан икән, монысы да алла кодрәте белән эшләнгән эштер әле...

— Бар, җаным, кайткач юынырсың. Бар, белеп кайт, ник чакырды икән?

Хәйдәр мазутка буялып беткән сырмасын иңбашына элде дә, берсүз әйтмичә, чыгып китте. Аның теләр-теләмәс чыгып китүе Мәрьямне борчыды, югыйсә, бервакытта да болай булмый иде. Соңгы көннәрдә әллә нишләп бик йомыкланып китте шул бу кеше.

Хәйдәр сәлам биреп кергәндә, Мохтар агай лапас тирәсендә ау кирәк-яраклары белән әвәрә килә иде. Егетне күрүенә, сәламен дә алмыйча, кычкырды.

— Әзерлән! Балыкка чыгабыз!

— Мин чыга алмыйм, — диде Хәйдәр.

Ялгыш ишетәммe? дигән төсле, Мохтар агай эшеннән бүленде:

— Ничек дисең?

— Чыга алмыйм дим.

— Запреттан куркасыңмы? Миңа запрет юк!

— Ишеттек.

— Ни ишеттең?

— Синнән запретны алу турында губернаторга күктән приказ иңгән ди.

Балыкчының кашлары җимерелде. Егетнең җавабы ошамады аңа. Кара син, нәрсә дигән була бит! Яхшылыкны белми торган гадәтең дә бармыни әле синең? Хәйдәргә күтәрелеп тә карамады ул. Әле тегесен, әле монысын эшләгән булды, бер керде, бер чыкты. Хәйдәр дә беркадәр вакыт, шулай басып торган хәлендә, көтеп-көтеп, тегенең сөйләшү түгел, күрәсе дә килмәвен сизгәч, борылып чыгып китте.

Мохтар агай балыкка үзе белән Искәндәрне алды. Төнге ау өчен яшьрәк иде ул, әйдә өйрәнсен! Берәү дә туганда барысын белеп тумаган. Үзе дә бит ул сигез-тугыз яшеннән ишкәк ишеп, бишәвәй тартып, ничә батып, ничә чыгып үсте. Әгәр бу бала да, атасына охшарга теләсә икән, шулай үссен. Яшьтән авырлык күрсәң, картлыгыңда җиңел була.

Хәйдәр Мәрьямгә дөресен әйтмәде, ялганлады:

— Болай гына чакырткан.

Мәрьям ышанмады:

— Болай гына чакырталармыни?..

Хәйдәр төксерәк итеп әйтте:

— Я, ярый. Следователь булма дидем бит инде бер!

Мәрьямнең хәтере калды. Бергә тора башлаганнан бирле Хәйдәрнең болай кырыс сөйләшкәне юк иде әле. Чыннан да әллә нишләгән бу кеше.

Кичке ашны, үпкәләшкән кешеләрдәй, сүзсез генә ашадылар.

Мәрьям түзмәде.

— Хәйдәр, син миннән нәрсәнедер яшерәсең.

— Яшермим, билләһи яшермим!

— Яшерәсең.

— Ә синең бик беләсең килә инде, әй?!

— Күңелем тынычланыр иде.

— Балыкка чыгарга чакырган.

Мәрьям өчен бик куанычлы хәбәр иде бу.

— Үзем дә шулайдыр дип уйлаган идем. Яшергән була, имеш. Кайчан чыгасың?

— Чыкмыйм дидем.

Мәрьям әле дә булса куанычын баса алмыйча назланды:

— Шаяртмасана, Хәйдәр!

— Чыкмыйм, наный, чыкмыйм! — Хәйдәрнең тавышында ачу ишет-

кән Мәрьямнең тынычлыгы югала барды. Хәзер инде үзенең якты өметләре ишелүен күргән бу яшь хатын ярсырга җитеп сорады:
— Нәрсә ашарсың?
— Сине! — диде Хәйдәр бар ачуына.
Мәрьям еларга җитеште. Рәнҗергә дә, үпкәләргә дә белмәде ул үзенең бу минутларда баладай гамьсез күренгән Хәйдәренә.
— Мин бит көлеп сорамыйм синнән. Әнә базарга барып кара син, бер балык тапмассың... Шуны уйлар идең, ичмасам...
— Хәзер кайтам! — диде Хәйдәр һәм иңбашына сырмасын элеп чыгып китте.
Хәйдәр урамга чыкты. Ул чыгуга Яга башындагы йорт капкасыннан да чыктылар. Моны ул чыгучыларның үзләрен күреп түгел, ә кулларында чайкалган фонарь яктысыннан белде. Димәк, Мохтар агай балыкка берүзе тәвәккәлли.
Фонарь яктысы ераклаша, сыеклаша торгач, күренмәс булды.
Хәйдәр, урам чатына җитеп, уен кибетенә борылмакчы гына иде, таныш тавыш ишетеп туктады.
Бу Касыйм иде.
— Очратуым яхшы булды, — диде ул, — типографиядән киләм. Мә, хикәяңне укый аласың. Андрейга бик ошады.
— Кит инде?
— Оста язган, ди.
Хәйдәр куанып бетә алмады:
— Дөрес әйтәсеңме?
— Ышанмасаң, башкаларга укып кара, — диде Касыйм.
— Укыйм, бүген үк. Тик мин аны үзем язуымны әйтмичә укыйм.
— Анда барыбер синең исем әйтелмәгән.
— Кем дигән соң?
— Укыгач күрерсең.

Печән кибетендәгеләр Хәйдәрне көтеп алдылар.
— Әйдә, гомерең озын булыр.
— Әле генә телгә алган идек үзеңне.
— Укырга бирәр кызыклы затың юкмы?
Хәйдәр кесәсеннән газета чыгарды:
— Газета укыйбызмы?
— Кызык түгел бит ул!
— Укып карыйк әле. Кызыкмы, түгелме — белербез, — диде Хәйдәр.
— Хикәяме?
— Бу чын хикәя, егетләр! — диде Хәйдәр. — Лампаның филтәсен чыгара төшегез.
Кибет эче яктырып китте.
Барысы да Хәйдәрне уртага алып иңләшеп утыргач, тынып калдылар. Хәйдәр газетаны ачты:
— Кая әле?! Әһә, менә! «Хәйлә җәтмәсе». Фельетон.
— Фаэтон дисеңме?
— Фельетон!
— Анысы ни дигән сүз?
Бу сүзнең мәгънәсен Хәйдәр үзе дә белмәгәч аптырап калды, аннары ачулангандай итеп әйтте:
— Тик кенә тыңлап утыр дигән сүз.
Мондый җаваптан гөрләшеп көлделәр.
— Аңладыңмы инде хәзер?! — диде Хәйдәр үзе дә елмаеп һәм укый башлады:
«Бу дөньяда күп-күп кызык хәлләр күрәлем. Ул хәлләр турында, язу таныганыбыз укып, наданыбыз ишетеп беләбез. Әмма әле без укып та, ишетеп тә белмәгән хикмәтле хәлләр дә бар икән дөньяда, ягъни

Бирге бистәдә. Мәсәлән, монарчы без жәтмәнен балык тоту өчен корылуын белсәк тә, балыкчының үзен эләктерү өчен корылуын белмидер идек. «Балыкчының үзен» дип без бер дә ялгышмый, ягъни мәсәлән, акыл белән әйттек. Ышануы кыен шул! Ничек инде, дияр кеше, жәтмәгә балык урынына балыкчы үзе эләксен? Тузга язмаган сүз бу дияр! Вә ләхи бездән көлүчеләр дә табылыр. Алдан әйтеп куябыз: андый бәндәләр көлмичәрәк сабыр итсәләр икән. Сабыр төбе сары алтын ди безнең халык. Ахырынача укып чыгыйк. Шул чагында кемнең кемнән көлүе ачыкланыр...»

— Кызык бу! — диде тыңлаучыларның берсе.

— Бүлдермә!! — диде ана икенчесе.

— Тавыш!!! — дип кисәтте өченчесе.

Хәйдәр дәвам итте:

«...Сез, хөрмәтле абзыйлар, газетабызның узган санындагы «Дога кабул булды» намендә бер әкиятне укыгансыздыр? Бу санда исә без сезгә доганың ничек кабул булу хикмәтен аңлатырга телибез. Ул дога заводчы Габидулла Башкин, промысел хуҗасы Суганов һәм аларның указлы ялчысы Зәйнетдин мулланың хикмәтле, икенче төрле әйтсәк, хәйләле «кодрәте» белән кабул булды. Бу әфәнделәр, алла исеме белән алдап, хәйлә жәтмәсен кордылар. Ул жәтмәгә Мохтар агай кебек тәҗрибәле балыкчы гына түгел, ә Суганов промыслосы эшчеләре дә косяклары белән эләгергә тора икән. Кисәтеп куюыбыз булсын: сез дә ул алданучыларга ияреп үз аягыгыз белән хәйлә жәтмәсенә килеп керә күрмәгез!»

Газета укылып бетте. Тыңлаучылар сүзсез тордылар.

— Я, кызыкмы? — дип сорады Хәйдәр.

— Бетте дәмени?

— Бетте!

— Самый кызык җирендә!

Хәйдәр үзе дә бу кызык язылган фельетонның соңына карады: «Ике дус». Ну әйбәт тә төзәткән, дип уйлап алды ул.

«Аваз» газетасында «хәвефле һәм зарарлы» фельетон басылу хәбәре жандарм идарәсенә килеп җиткәндә, газета шәһәр абунәчеләренә таралып өлгерсә дә, авылларга җибәреләсе саннар китеп бетмәгән иде әле.

Шул ук сәгатендә «зарарлы» газеталарны җыеп алдылар, ә Габидулла Башкинны ашыгыч рәвештә жандармерия идарәсенә чакырттылар.

Мондый көтелмәгән хәлдән аптырап калган Габидулла, чакыруны алгач, тәмам коелып төште. Аның улы редакторлык иткән газетада шундый хәл килеп чыксынчы! Ничек кенә булды соң бу? Әллә аның улын котыртканнармы? Социалистлар белән дуслашмаганмы? Ул үз улының шуның шуше авантюраларга ябышкак холыклы булуын яхшы белә, ләкин ул аның бу хәл өчен типография эшчеләре арасында яшен уйнатуын күргәч, бу фикереннән тиз кайтты. Жандарм башлыгына ничек аңлатырга моны?! Ахыр чиктә, аптырагач, газета белән турыдан-туры үзенең шөгыльләнмәвен әйтеп котылырмын дип уйлаган иде, әмма жандарм башлыгы Сагайдачный тагы да ныграк бәйләнде.

— Улыңа тылда отечество өчен файдасы булыр дип ак билет [1] алып бирдек, ә ул крамола басып ята. Моны ничек аңларга?

— Улым ышанычлы минем, ваше превосходительство.

— Ничек инде мондый эшләрдән соң — «ышанычлы»?

— Бу эш анардан башка эшләнгән.

Жандарм башлыгының күзе шар булды:

---

[1] Солдатка ярамаучыларга элек заманда ак билет бирганнәр. Хәллерәкләр мондый билетны акча төртеп тә алганнар.

— Ка-ак?!

— Әйе, әйе! Моны, беләсегез килсә, ваше превосходительство, мәтәштергәннәр, сезнеңчә әйтсәк, подсунули.

— Кем?

Бик кырт янгыраган бу сорауга Габидулла иңбашларын күтәреп куйды, янәсе, белсен иде ул аның кем булуын...

— Менә нәрсә, — диде жандарм башлыгы, — бүген сәгать дүрткә типография эшчеләрегезнең исемлеген канцеляриягә тапшырсыннар. Ә сезнең мондый ваемсызлыгыгызны, хөрмәтле Габидулла Газимзянович, югары властька житкермичә калу ярамас. Ай-һай, сезнең «Аваз»ыгызны да «Дулкын» язмышы көтмәгәе...

Заводчының тәне эсселе-суыклы булып китте. Чынлап та, бу вакыйганы әгәр губернатор белеп алса?! Алла сакласын, министрга барып житсә! Газетаң түгел, семьяң белән дә саубуллаш аннары. Әйе, әйе, «Дулкын»ның нәшире киткән юл белән туп-туры Себергә аннары. Габидулла кайгыга калды. Чыннан да житкерер микәнни губернаторга?!. Житкерер. Жандарм башлыгы бит ул. Дөрес, монарчы бик тату, хәтта дус яшәп тә килделәр алар. Сукса тимер өзәрлек улына чирле дигән булып ак билет алып бирүдә дә ярдәме зур булды аның. Хәле читенләшкән бу минутларында Габидулла шул дуслыкка таянып карарга ниятләде.

— Ваше превосходительство, Сергей Сергеевич, алла хакына соравым булсын, куерта күрмәгез инде, зинһар! Әллә ни булмастыр, иншалла! Әнә бит газетаның яртыдан күбесен тотып кала алдык. Сезнең сизгерлегегез аркасында, әлбәттә. Калган кадәресе күберәгенчә шәһәр байларына, сәүдәгәрләргә тарала, ә инде бик азы кара халыкка барып житә икән, алары газета укымый, укыса да берни аңламый, тәмәке төрергә алдыра ул халык безнең газетаны.

Габидулланы тыңлап бетергәч, Сагайдачный башын чайкый-чайкый көлде, аннары бердән житдиләнде.

— Сез, Габидулла Газимзянович бер нәрсәне онытасыз. Мин жандарм башлыгы, ә большевик түгел.

— Юк, бер дә онытмадым, ваше превосходительство! Барысы да сез галиҗәнаб ихтыярында. Сезнең кодрәтегез зур да, көчле дә! Сергей Сергеевич, гомердә онытмас идем, анттыр әгәр. Булган икән булган, моннан ары булмас! Ике арада калсын. Гозереннән тормас идек.

Жандарм башлыгы эчкерсез көлгән булды:

— Ике арада дисез, ә?! — Аннары ул тагы житди сөйләшүгә күчте. — Мин сораган исемлекне китереп житкерегез әле башта.

Габидулла подполковник кушканны бик тиз үтәде. Билгеләнгән сәгатеннән алдарак жандармерия идарәсе канцеляриясенә сургучлы конверт китереп тапшырдылар. Конверт эчендә жандарм башлыгы сораган исемлек белән бергә Николай патша рәсеме төшерелгән тастымал зурлыгы ике иллелек, ә тышына «Его превосходительству подполковнику С. С. Сагайдачному, в собственные руки» дип язылган иде.

* * *

Мохтар агай төннең-төн буе, керфек какмыйча, балык тотты. Каегының бар жире балыкка тулып, берилле запасы калды. Нигә зуррак булмаган бу каек! Каек түгел, баржаң да житмәс хәзер бу байлыкны төяргә. Балыкларның зурлары һәм кыйммәтлеләрен тезгечләп суга жибәргәч, каек запасы бераз күтәрелде, ләкин барыбер әллә ни төярлек урын калмады. Менә кайда ул сабыр төбе! Бирәм дисә, бирә икән бу ходай сабыр иткән колына! Ах, тагы бер каек, ике... өч каек булсачы! Үзенең болай бик ач күзләнүеннән беркадәр оялды да ул. Ләкин монын ише кичерешләр мәгънәсез булып күренде аңа. Ул аларны бар

көченә куды. Ходай биргәнне алуның ояты була димени! Эх, хәзер менә шаланда[1] булсын иде, шаланда! Чү, менә болай эшләп тә була бит: тиз генә кайтып, сатасын сатып, тозлыйсын — тозларга да тагы килергә. Әйе, әйе, тагы килергә. Тиз!

— Искәндәр, күтәр, улым, җилкәнне, кайтабыз!

Искәндәр мачтаны утыртты, җилкәнне корды. Бәхет дигәннең бер килсә килеп кенә тора бит ул: җилкәнне өреп җил исте, ә юл уңаена искән җил балыкчы өчен үзе бер бәхет! Аннары җиле дә әлеп алып селкеп сала торганы түгел, иртәнге саба җиле.

Идел өсте тымызык. Тирә-як тын. Рәхәт. Балыкчы күңеле дә рәхәт.

Капчыкланып өрелгән җилкән көченә, аккоштай тирбәлмичә йөзеп, салмак кына каек бара. Койрыкка Мохтар агай үзе утырган. Искәндәр, — йокысыз узган төн мингерәтте күрәсең үзен, — мачтага сөялеп утырган да калгып-калгып ала. Ата, мыек астыннан гына елмаеп, улының бу хәлен күзәтә. Кәефе шәп, беркайчан булмаганча шәп кәефе аның бу бәхетле иртәдә. Сөйләшәсе, сөйләшеп куанасы килә аның. Шатлыгын уртаклашып, Искәндәренә берәр җылы сүз дәшәсе килә аның.

— Улым, кайткач йокларсың. Казан өе тәрәзәләрен томалап караңгыларсың да йокларсың. Кая әле, улым, булмаса берәр белгән җырыңны җырлачы.

Искәндәр уянып китте. Әтисенең эндәшүе түгел, җырларга кушуы уятты аны һәм... гаҗәпләндерде.

— Син бит, әти, җырлаганны яратмыйсың. Җырласам, «поп булып акырма!» дип тиргисең.

Мохтар агай җәелеп елмайды. Улының сүз көрәштерүе дә үчектерми хәзер аны.

— Һәр эшнең, улым, урыны бар. Җырны да безнең халык я башына кайгы төшкәндә, я бәхеткә очраганда җырлый.

— Минем шул, әти, бәхеткә очраганда җырлый торганы юк.

Кара, ничек зурларча җавап бирде бу бала.

— Нигә юк?

— Очрап күрмәгәч.

Ата кеше, каш астыннан елмаеп, улына карады:

— Нинди җыр беләсең соң?

— Кайгылыны.

Кара син, кая таба сукалый бу! Нинди кайгысы бар моның? Кайгының ни булуын беләме соң бу тургай?

Мохтар агай ризалык биргән төсле итеп әйтте:

— Җырлап күрсәт әле!

Искәндәр, җырлыйсы җырның көен хәтерләргә теләп, бераз вакыт Идел ярына карап торгач, моңлы тавышка җыр сузды:

Мәчет манаралары,
Манара аралары.
Безгә генә калган икән
Авыр заманалары.

— Кешедән ишеткәнне җырлыйсың, улым!

— Башкасын ишетмәгәч!

Бу юлы инде улының мондый җавабы балыкчыны уйлар диңгезенә атты.

Замана авырлыгын күрергә дә, татырга да өлгермәгән, хәтта аның ни икәнен дә белеп җиткермәгән Искәндәрнең шул хәтле эчке сагыш белән биргән бу җавабы әти кешене аптырашта калдырды.

«Башкасын ишетмәгәч».

[1] Шаланда — күп сыйдырышлы зур балык көймәсе.

Искәндәр, жыр моңына уянган хисләренә бирелгәннән-бирелә барып, жырлады да жырлады...

Каек Яга суына керде.

Яга буе кер чайкарга төшкән хатын-кыз, су керүче бала-чага, көймә сумалалаучы балыкчылар һәм, өстәрәк, вал башында тезелеп утырган эшсезләр белән тулы иде.

Менә хәзер, күп булса дүрт-биш минуттан, Яга буендагылар, бигрәк тә әнә теге вал башындагылар, Мохтар агагызны күреп алырлар. Күреп тә алырлар — хәйран да калырлар. Күрерсез менә, әгәр Яга өсте Мохтар агагызга дәшеп кычкырган, сорашкан тавышларга тулып калмаса. Әйе, әйе, менә хәзер, күп булса дүрт-биш минуттан...

Мохтар агай жаны-тәне белән шуны алдан күреп бара, тик горурлык саклап күрмәмешкә салыша, алар ягына карамый да, янәсе, сез күренәсезмени хәзер аның күзенә!

Ә үзе көтә. Тегеләрнең күреп алуларын көтә. Менә хәзер, хәзер, күп булса ике-өч минуттан...

Вал башындагылар Мохтар агай каегын күреп алдылар. Кайсыдыр: «Кайта!» дип бер генә сүз ташлавы булды, барысының да күзе балыкчы каегына төбәлде. Берәү дә берсүз әйтмәде. Барысы да балык тулы каекның суны ерып барган борынына карап тордылар. Әгәр бу чакта аларның таштан койгандай катып калган кыяфәтләренә, кояшта янып, жилдә ярылып каралган, сакал-мыек баскан кырыс йөзләренә күз салыр булсаң, ниндидер бер эчке нәфрәт катыш борчылу чагылуын күреп тә булыр иде.

Ләкин атаклы балыкчы ул борчылуларны күрерлек хәлдә түгел хәзер. Каегының аккош канаты сыман өрелгән жилкәнен генә күреп бара ул һәм... көтә.

Хәзер, менә хәзер, күп булса бер-ике минуттан.

Каек бара да бара. Яшел мәчет мәхәлләсен узып Симез мәчет турысына да килеп житте, үз мәхәлләләренә дә озак калмады. Ә-нә Камышлы мәчет манарасы, манара башындагы көмеш ай ялтырап күренә.

Ник дәшмиләр тегеләр? Күрмиләрме әллә? Күрмичә буламы икән? Күргәнгә дәшмиләр! Әйе, әйе! Эчләре яна аларның. Көнләшеп дәшмиләр. Дошманлык та юк түгелдер әле. Борын-борыннан ата-бабадан килә бит ул дошманлык, мәхәллә белән мәхәллә арасындагы татусызлык. Аннары дошманлык дигәнең шулай дәшми калу белән генә чикләнә дип уйлыйсыңмы?! Кая ул!.. Мохтар агай үзе дә, егет чагында, кечке бастангырларда[1], ике мәхәллә егетләренең канга батып сугышуларында катнашканы, берничә тапкыр башын-күзен ярдырып кайтканы бар. Әнә Искәндәр утыра. Шул баланың үзе ничәмә-ничә кыйнап, ничәмә-ничә кыйналып кайтканы бар. Күрәчәге алда әле аның, егет булып житсен әле.

Чү, кайсыдыр дәшеп кычкырды түгелме? Мохтар агайның уйлары бердән таралды, тик ул ни кычкыруларын ишетә алмыйча калды. Кайсысы булды икән? Чү, әнә гөрләшеп көлештеләр түгелме? Әйе, әйе.

— Кемнән көләләр алар, Искәндәр?

— Бездән, — диде бала.

— Бездән?

Менә моңысын атаклы балыкчы берничек тә аңлый алмады һәм аңлый алмас та иде. Ничек көләргә кирәк аның хәзерге хәленнән? Кеше бәхетеннән көлеп буламы? Хәер, көнчелек корты кузгалса ниләр генә эшләтмәс ул адәм баласын.

Әнә тагы нидер әйттеләр. Тагы гөр килеп көлгән тавышлар ишетелде. Берсе шул хәтле шаркылдады, кер чайкаучы хатын-кызлар, нәрсә булды ул тикле дигәндәй, эшләреннән туктап карап тордылар.

---

[1] Бастангыр — кечке туй.

Мохтар агай мыек астан елмайды:

— Көнлиләр! Безнең бәхеттән көн...

Ләкин, сүзен әйтеп бетерә алмады ул, вал башыннан:

— Егетләр, әнә шул үзе инде хәйлә җәтмәсенә эләгүче! — дип кычкырдылар.

Икенче тавыш эләктереп алды:

— Үзе генә дә түгел... Каегы-маегы, баласы-чагасы белән эләккән!

— Ха-ха-ха...

Бу юлы Мохтар балыкчы аермачык ишетсә дә аңлый алмыйча азапланды. Нидән көләләр алар? Әллә исерекләрме? Я, ярар, исереккә сәлам бирмә, бирсә, — алма дигән китап.

Алар үз ярларына килеп җиттеләр. Искәндәр җилкәнне төшергәч, Мохтар агайга яр буе ачылып китте. Ул тагы гаҗәпләнде. Яр буенда, кер чайкаучы бер хатынны исәпләмәгәндә, башка беркем дә юк. Кызык.

Каек, йөге авырлыгыннан артыгынча тирән утырганга, яр читенә үк килә алмады. Искәндәр каекның чылбыр бавын алып суга сикерде дә ярга чыгып бауны үз казыкларына бәйләде. Мохтар агай тезгешне өстерәп чыкты. Тезгештә сазаннар һәм ике зур осетр бар иде. Сайга төртелгән балыклар шаулап-дулап суны болгандыра-болгандыра котырындылар. Эх, бу тамашаны читтән күреп торучы булсын иде хәзер! Хәйдәр күрсен иде моны! Ашыкма, күрерсең әле, егет!

Тезгештәге балыклар бер кеше күтәрерлек кенә түгел. Ата белән бала тезгешне ишкәккә асып берсе бер очын, икенчесе икенче очын иңбашларына алгач, бер адымга атлап өйләренә таба ашыктылар. Алда Искәндәр, артта үзе, уртада — әле тегеләй, әле болай бөтәрләнеп-тузгылып торган сазаннар белән ике зур осетр. Ә каекта?! Каекта бихисап балык. Җаның нинди һәм күпме тели!

Минем бу якты көнемне күрмәскә тырышасыз, бәхетемне күпсенәсез. Күпсенегез! Шуннан башкага җитми дә бит сезнең көчегез. Ә Мохтарның җитә! Кулында барның көче бар, көче барның — эше бар! Мохтарның кулында сездә булмаган көч бар хәзер! Менә күрерсез... Күрергә теләмәсәгез дә күрерсез. Мохтар агагыз белер ул моны ничек эшләргә. Башлап менә сиңа, Хәйдәр! Кичә ышанмаган идең бит әле. Менә бүген үз күзең белән күр инде, алайса. Кулыңа үзе кергән байлыкны кире кактың, җүләр! Ә Мохтар агаең ул ачу саклый торган кеше түгел.

— Бар, улым, менә шушы сазанны Хәйдәр кахаңа кертеп чык. Әтием җибәрде диген. Кара аны, акча бирсә, алып куйма! Сәдака булсын.

Искәндәр зур тере сазанны күтәреп килеп кергәндә, Хәйдәр ишек алдындагы сәкедә кичке аш ашый иде.

— Әти сиңа сазан җибәрде, — диде бала, кулын өзәрлек авыр йөктән тизрәк котылырга теләп.

— Мин балык сорамадым әтиеннән!

Бала дәшмичә торды.

— Күпме бирсен диде?

— Бер тиен дә.

— Һай-һай, Мохтархай йомартланган!.. Тиген икән алайса, ә?

— Әйе.

— Ни дип әйтте?

— Сәдака булсын диде.

Хәйдәрнең чигә тамырлары күксел кәнеп бүртте:

— Ялынкан этиең! Сәдаканы муллага бирәләр аны. Күбрәк итеп! Бер сазан аз ул!.. Югыйсә, догасы кабул булмас.

— Алыгыз инде, — диде кулы талган Искәндәр. — Кая куйыйм?

— Беркая да! Кире алып кит! «Хәйдәр кахам: миңа сәдака кирәкми, дога кыла белмим» дип әйтте диген. Бар!

Бала капкага таба борылды.

— Тукта! — диде Хәйдәр бердән хәтерләп һәм сикереп торып өйгә кереп чыкты.

— Монау гәзитне әтиеңә укырсын. Өченче биттә.

Искәндәр газетаны изүе эченә тыкты да, кулындагы авыр йөгеннән котыла алмавына турсаеп, чыгып китте.

Мохтар агай ишегалдында балык исенә җыелган күрше мәчеләрен куа-куа, тезгештәге кызыл балыкның иң зурысын Зәйнетдин муллага әзерләп тора иде. Искәндәр кайтып керде. Әтисе улы кулындагы сазанны күрде.

— Өйдә юкмы?

— Алмады.

— Алмады?!

— Әйе дим бит инде.

— Кем алмады?

— Хәйдәр кахам дидем бит инде.

— Нишләп?

— Сәдакасын муллага бирсен. Мин дога кыла белмим, ди.

Мохтар агайны чәнчеп алды бу сүзләр, ул мыскыллы елмаерга теләде, әмма елмаю килеп чыкмады, ирен кырыйлары тартышып кыйшайдылар аның.

— Һәй, хайван! Мин аңардан дога кылуын сорадыммыни?! — Анары Искәндәрне ачуланды: — Аңлата белмәгәнсең. Бар илт кире!

Бала еламсырады:

— Алмый дидем бит инде.

Кинәт Искәндәр изүе эченнән газета чыгарды да әтисенә сузды.

— Ни зат ул?

— Газет. Хәйдәр кахам бирде. «Әтиеңә укырсын», — диде.

Балыкчының җен ачуы кузгалды:

— Башына капласын газетын!.. Әллә мине дә бастовщик булыр дип уйлаганмы?!

Искәндәр газетаны сәке кырыена куйды да урамдагы дус малайлары янына ашыкты.

Бердән нәрсәдер абайлаган Мохтар тамада баланы капка төбеннән борды:

— Кая киттең әле син?

Искәндәр борылып кайтты.

— Укы!

Искәндәр газетаны ачты. Өченче биттән Хәйдәр әйткәнне эзләде.

— Менә!

— Нәрсә язган?

Искәндәр көйләп һәм иҗекләп фельетонны укырга кереште.

«Хәй... хәйлә җәт... җәтмәсенә эләккән ба... ба... балыкчы».

Мохтар агайның башы шаулагандай булды. Әллә ничек шунда, каядыр бер ишеткән төсле яңгырады бу сүзләр. Әйе, әйе, бая вал башындагылар кычкырган сүз түгелме соң бу?! Ә-ә, әнә нәрсәдән көлгәннәр икән алар. Балыкчы шулай уйларга да өлгермәде, үз исемен ишетүгә сискәнеп китте. Уйлары бердән чуалды, карчыгы Фатиханың «Сине язганнар түгелме?» дип соравы башына суккандай булды аның. Барысы да буталды балыкчының башында. Искәндәр газетаны укыган саен, бая вал башындагыларның гөрләшеп көлгән тавышлары көчәя төсле иде. Чу, Искәндәр үзе дә көлә түгелме? Әйе, әйе, әнә карчыгы Фатиха да көлә. Әйе, әйе! Вал башындагыларга кушылып теге, кер чайкаучы хатын-кызлар да, су керүче бала-чага да көлә.

Искәндәр укый:

«...Ул җәтмәгә Мохтар агай кебек...»

Һәм баягы тавыш кабат ишетелгәндәй була:

«...үзе генә түгел, каегы-маегы, баласы-чагасы белән эләккән...»

Балыкчының маңгаена салкын тир бәреп чыкты, тамагына төер тыгылды. Карчыгы белән улына күтәрелеп карарга да кыймады. Гарьлек буды аны һәм ул, артык бу хәлгә түзә алмыйча, урыныннан күтәрелде дә өйгә кереп китте.

Мондый чакта юаткан булып сүз әйтүнең файдасызлыгын Фатихаттәй дә, Искәндәр дә яхшы белә. Алар берсүз әйтмәделәр.

Шул керүдән Мохтар агай көндезен түгел, кичке ашка да чыкмады. Амбардай иркен һәм караңгы өенең сәкесендә озак уйланып ятты.

Икенче көн иртәсендә дә Мохтар агай гадәтенчә ишегалдында күренмәде.

Искәндәр берничә кат ишеккә килеп:

— Әти, балыкларны нишләтәбез? — дип сораса да, җавап булмады, ә үзенең генә каек янына барасы килмәде. Бер чыгып караган иде, усал малайлар «Хәйлә җәтмәсе» дип кычкыргач, кире борылып керде. Мондый вакытта сүз көрәштереп талашырга да, йодрыклашып кыйнашырга да ярамый. Мондый чакта иң дөресе исең китмәгән булып күренү, югыйсә хәзер кушамат тагып куюлары бар. Тагы дөресе, мондый чакта, бу күңелсез хәлләр онытыла төшкәнче, күзгә-башка күренми тору әйбәт. Искәндәр моны яхшы белә. Яхшы белгәнгә күрә дә, бая, беренче сигнал булуга, шыпырт кына өенә кереп качты.

Ишегалдында ялгызлыктан каңгырып нәрсәгә тотынырга да белмичә йөргәндә, капкада Нургали агай күренде.

— Әй, кайсыгыз бар бу йортта?! — дип дәште ул.

Тавышка лапас астыннан Искәндәр чыкты.

— Әтиең кайда?! — дип сорады карт бондарь.

Искәндәр әйтергәме-әйтмәскәме дигән кебегрәк икеләнеп торгач:

— Яткан, — диде.

Нургали балыкчы башына төшкән «Хәйлә җәтмәсе» вакыйгасын яхшы белә иде. Бу аны да борчыды һәм шул борчылуы алып килде дә үзен Мохтар йортына.

— Бар әйт, чыксын, сүзем бар!

Искәндәр болдырга кереп китте һәм озак та тормастан әйләнеп тә чыкты.

— Я, чыгамы?

— Чыкмый! — диде бала.

Нургали ачуланып сорады:

— Нәрсә ди?

— Йөрмәсеннәр, ди.

Карт бондарьның кашлары җыерылды. Ул болдыр ишегенә таба, балыкчы ишетерлек итеп кычкырды:

— Минә аңарга йөрмәскә кирәк иде... сакаллы башы белән. Юкбарга алданып!

Мохтар агай моны ишетте. Чәнчеп, әрнетеп алдылар бу сүзләр үзен.

Нәкъ бер тәүлек узгач, кич җитеп, караңгы төшеп, бистә урамнары, Яга буйлары бушап калгач, Мохтар агай ишегалдына чыкты. Сары җиз комганга ушаттан су тутырып, бәрәңге бакчасы артына китеп, юынды. Шул арада карчыгы аш җылытты. Мохтар агай ашны тамчысын да калдырмый ашады, аннары карчыгы карбыз бирде, анысын да ашады. Аш-су белән эш беткәч, башына киез эшләпәсен киеп, иненә сырган бишмәтен элде дә тавышсыз-тынсыз гына чыгып китте.

Ул коймалар буйлап Ягага таба атлады. Аннан яр буена төште. Кичәдән бирле миен бораулаган уйлары һәм шуна катыш тагы менә хәзер туган бер ямьсез сизенү тынычсызлый барды үзен. Әйе, бу бик начар һәм таныш ис иде. Ниһаять, каегы янына килеп җиткәндә бу ис күңелен болгандырып укшыта башлады.

Мохтар агай, алдына-артына карамастан, тиз генә каегының чылбыр бавын казыктан ычкындырды да тиздән суга кереп каегына таба атла-

ды. Иөге авыр каек бу бер тәүлектә ярыйсы ук утырган иде. Тирләп-пешеп көчәнә-көчәнә каекны кузгаткач, сикереп менеп ишкәккә утырды.

Шулай итеп, кеше-фәлән күрмәгән төнге караңгылыкта, Мохтар агай каегы тулы исләнгән балыкны кире Иделгә аударып кайтты.

Кем дә күрмәде. Балыкчының җилкәсеннән тау төште.

Бу төнне Мохтар агайның күзенә йокы кермәде. Уйланып ятты ул, озак уйланып ятты, таңга кадәр. Мең төрле уй әйләнде бу төнне тамаданың башында...

Башкин заводында яңа киләчәк эшчеләрне каршылау ыгы-зыгысы купты. Бар эш ашыгыч башкарылды. Иң әүвәле чүп-чар баскан баракларның идәннәрен, су сибеп, тиз кулга себереп чыктылар. Җилләтү өчен тәрәзәләрен ачтылар. Башкин кибетендә үтми яткан криндел, тозлы балык, махорка, чәй, шикәр һәм башка шуның ише көндәлек кирәк әйберләрне завод ларегына китереп аудардылар. Әйдә, рәхәтләнсеннәр! Забастовкада катнашкан эшчеләрдән кайберләре моны күреп хафага калды. Безнең ипине тартып алачаклар бит ул яңа килүчеләр. Әллә эш узмый торып кире заводка кайтыргамы икән дип икеләнүчеләр күренде. Шуның ишеләргә юл куймау өчен, забастовка комитеты члennары һәм аларга ияреп олы яшьтәге эшчеләр завод йортына ашыктылар.

Завод йортында аларны йөзенә җиңүчеләр горурлыгы чыккан Салтыков каршы алды:

— Ә-ә, бастовщиклар, килдегезмени?! Әлбәттә инде уңганлыктан түгел, тунганлыктан, ә?! Менә шулай була ул, братильниклар! Ә безгә пока эшчеләр кирәкми. Кирәкми и шабаш! Нигә дисәгез, нужда юк. Ишеткәнсездер?..

— Ишеткәнгә күрә килдек тә,— диде бондарь Нургали.

— Соңга калдыгыз! Корсак дигәнне онытып, бик акыллы башланып эш итсәң, шулай була ул! Безгә сезнең ише эшчеләр кирәкми. Сезнең өчен бездә эш юк. Булмас та!

Нургали агай түзмәде:

— Ну, син! Теленә салынма, яме?! Без синнән эш сорап килмәдек!

Салтыков гаҗәпләнде:

— Бәй, эш сорап килмәсәгез, ни дип килдегез?! Бездә бит завод, туманный[1] түгел.

— Мин сина туманныеңны шундый күрсәтермен...— Нургали агай тагы нидер әйтмәкче иде дә, ләкин әйтмәде,— хуҗа кайда?

Салтыков бердән әтәчләнде:

— Габидулла әфәндене сезнең белән сөйләшергә вакыты булмас!

— Аныкы булмаса, безнең бар!— диде Нургали.

Управляющий кырт кисте:

— Ә безнең юк!— Кабатлап кычкырды,— юк!! Була да алмый!! Үзегез беләсез, без эш кешеләре, эш ташлап йөрүчеләр түгел.

Нургали агай сабыр, әмма шундый бер эчке кисәтү белән әйтте:

— Э-х... кем генә диярго сине?! Алайса ишет, Сал-тыков, безнең дә син калай әтәч белән озын-озын сөйләп торыр вакытыбыз юк. Сүз кыска: әгәр өенә коры штан төбе белән кайтырга теләсәң, биш минуттан хуҗаң монда булсын.

Эшчеләрнең яшьрәкләре хахылдап көлеп җибәрделәр.

Салтыковның ачудан муен тамырлары бүртте. Үз бүлмәсеннән Габидулла чыкты. Ничек кенә булмасын, хуҗа — хуҗа инде, аны күргән эшчеләр көлүдән шып тукталылар. Габидуллага ошады бу. Димәк, куркалар. Куркыгыз! Куркытырмын мин сезне!!

Габидулла басып торучыларны берәм-берәм күздән кичерде. Күзе карт бондарьга житеп тукталы.

[1] Ул елларда кинотеатрга шулай әйтелә иде.

— Нихэл, Нургали абзый?! — дигэн булды ул, — бу хэтле хахылдагач хэлегез бик мөшкел түгел күрэсең?

Нургали агай тыныч тотты үзен:

— Безнең хэлне белэсең, Габидулла. Табып белмэгэн — югалтып күрмэгэн...

— Алай-ай, — дип сузды хужа. — Анысы эйбэт икэн. Югыйсэ мэйтэм, көймэгез комга терэлдеме? Ходай эше — белмэссең!

— Синең бу эшенне ходай белсэ, түбэннэн орыр иде, — диде Нургали.

— Нинди эшне?! — Габидулланың тавышы тыныч һэм йомшак яңгырады. Эмма каядыр эчтэ ачу кабына башлаган иде инде.

— Эйтегез, хөрмэтлем, нинди эшне?

— Халыкны алдавыңны!

Башкин жинелчэ елмайды:

— Мин ялгыш ишетмэгэнмендер бит?

— Кыланма! — диде Нургали, заводчының күзенэ туры карап. — Ач балыкчыларны алдый алсаң да, безне алдый алмассың.

Башкин бу сөйлэшүлэрнең төбен инде хэзер генэ аңлаган булып кыланды:

— Э-э, сез эле шуны эйтэсезмени?! — Ул беркадэр вакыт бик борчулулы кыяфэттэ сүзсез уйланып торган булды, — алай икэн... Халыкны алдыйм икэн, э?! Э мин тагы үземчэ халыкка ярдэм кулын сузам дип торам...

Башкин шушы эйткэннэренэ телэктэшчелэр эзлэп каршында басып торучыларны берэм-берэм күздэн кичереп чыкты. Кемнэдер тотып алырга, кемгэдер таянырга телэде, эмма аларның кырыс йөзлэрен күргэч беркадэр каушый төште, лэкин ул моны сиздермэскэ тырышты.

Шул чакны кисэтүле яңгыраган бер тавыш ишетелде:

— Син, хозяин, көчле белэн көрэшмэ!

Барысы да тавыш ишетелгэн якка борылды.

Башкалар танымаса да, Нургали Андрейны бер күрүдэ таныды.

Габидулла Андрейны моңарчы очратып күрмэгэнгэ, таный алмады. Нинди кеше ул? Каян килеп чыккан?

— Сез кем буласыз? Што-то мин сезне белмим, уважаемый! — диде завод хужасы.

— Зато без сезне яхшы белэбез! — диде Андрей һэм өстэп куйды: — «Уважаемый».

Габидулла бу билгесезнең үртэвенэ каршы шундый ук бер жавап эзлэп торды. Андрей моны тиз абайлады:

— Дэшмэү килешү билгесе дилэрме эле?

Габидулла бердэн тавышын күтэрде:

— Сез нинди килешү өмет итеп килдегез?

Жавапны Нургали агай бирде:

— Киресенчэ! Без, үзебезнең килешмэвебезне белдереп, шуны эйтергэ дип килдек: син заводка бездэн гайре эшчелэр алма!

— Мин сезнең минем эшемэ тыгылырга телэвегезне аңламыйм, Нургали абзый! — диде хужа, шелтэле тавыш белэн.

— Юк-к, бу безнең эш! — диде Нургали агай, «безнең» сүзенэ басым ясап.

Габидулла танымаган кеше — Андрей тагы сүзгэ кушылды.

— Эшчелэр эше! Бары тик эшчелэр эше!

— Карагыз эле, сез кем?! Ни дип котыртасыз сез кешелэрне, э?! Адвокатмы? Маклермы?! Барышникмы эллэ?

Андрей тыныч кына эйтте:

— Ай-һай, Башкин эфэнде! Кеше таный алмыйсың икэн! Күреп торасыз ич — мин эшче!

— Эшче икэнсез — эшегездэ булыгыз, — диде Габидулла, — минем

заводым митинг урыны түгел! Кирәк икән, әнә, Александр бакчасына барып митинговать итегез! Ату полициягә хәбәр итәм!

— Син безне полиция белән куркытма! — диде Нургали агай. — Безнең соңгы сүзебез шул: или таләпләребезне үтисез дә, без эшкә чыгабыз, или...

Габидулла картның авызыннан тартып алды:

— «Или» нәрсә?!

Нургали агай елмайды:

— Илинең иләрлеге күп аның, Габидулла! Бер или башласаң, кибәге күп чыга аның.

— Менә бит сез нинди кире беткән халык! Без монда эшче хәле, эшче бәхете өчен тырышабыз, ә сез...

Андрей заводчыны бүлде:

— Сез, Башкин әфәнде, эшче бәхете өчен тырышуны эшчеләрнең үзләренә калдырыгыз.

Габидулланың түземлеге югалганнан югала барды:

— Сез печән өстенә менеп яткан эт! Үзегез дә ашамыйсыз, башкаларга да ашарга бирмисез!

— Бездә корсак кайгысы гына түгел, Габидулла! — диде Нургали агай, — яшәү кайгысы да. Ашарга дисәң, аны, сыер да күши.

Артык түзәрлеге калмаган Габидулла, кискен бер фикергә килүен аңлаткан сыман кырт борылды да, ашыгып кабинетына кереп китте.

— Күрдегезме инде? Күрсәгез, таралыгыз. Күзгә күя булып йөрмәгез! — диде Салтыков. — Аңлашылгандыр?

— Аңлашыласы алда әле, — диде Нургали.

— Һай, Нургали агай, карап торам да мин сиңа...

Салтыков, ни өчендер, әллә куркып, әллә инде уңайсызланып, сүзен әйтеп бетермичә, бүленеп калды.

— Әйт сүзеңне! — диде Нургали.

— Әйтмим инде. Ничә әйтсәң дә, олы яшьтәге кеше бит сез.

Нургали агай управляющийның янына ук килеп басты:

— Син әйтмәсәң, мин әйтием инде, алайса. Кара аны, сыерга ияр килешмәгән кебек, сиңа да бу эшләр килешеп бетми, сатылып йөрмә.

Нәтиҗәсез ызгыштан бернигә ирешә алмаган эшчеләр завод йортына чыктылар. Монда шул арада килеп җиткән башка эшчеләр дә җыелган иде. Нургали агай Андрей белән киңәшләшеп, завод пристане тирәсенә үз кешеләрдән пикет куюны кирәк таптылар.

Тиздән яңа эшчеләр килеп тә җитәрләр. Башкин Фадеевның «Потехин»ын арендовать иткән. Пароход килеп туктауга яңа килүчеләрне хуҗалардан элек каршыларга, забастовканы өзмәүләренә ирешергә кирәк иде.

Нургали агай борчылып әйтте:

— Тыңламады бит... тамаданы әйтәм. Чакырдым, килмәде. Иске дуслар бит алар. Икесе дә атаклы балыкчы. Гордеев бәлки аны тизрәк тыңлаган булыр иде.

Пикет өчен яшьрәк һәм гайрәтле эшчеләр билгеләнде. «Потехин»ны завод пристанена җитеп туктаганчы ук юлда каршылау фикере туды. Мондый тәвәккәл эш Андрейга охшады, ләкин өлгереп буламы моңа? Кем эшли алыр иде бу эшне?! Хәйдәр эшли алыр иде...

Андрей ялгышмады. Әйе, эшләсә бары Хәйдәр генә эшли алыр иде бу эшне. Аның бу пароход командасы белән үзенә күрә бер дуслыгы, якынлыгы бар бит...

«Потехин» шәһәр белән Комүзәк арасында пассажирлар ташучы бер палубалы пароход. Аның хуҗасы Фадеев Бирге бистәнең руслар яшәгән очындагы ике катлы зәңгәр йортта тора. Байлыгы әллә ни зурдан түгел, шул бер пароход тотарлык булса кирәк, ә менә бала-чагага килгәндә, бистәдә генә булмыйча, бөтен шәһәрендә аның кебек балага бай

әти табылырмы икән? Җиде егете бар аның! Хезмәт сөйгән, эш белгән ата үз балаларын черек байбәтчәләрдәй гамьсез үстермәде, йөгәнне яшьтән үк нык тотты. Иң элек ул аларны укытты. Берсе артлы берсе диңгезчеләр мәктәбен тәмамлап, кайсы лоцман, кайсы боцман, я капитан ярдәмчесе булып Россиянең төрле елгаларына таралдылар. Әти кеше эшсез торырга күнекмәгән холыклы булгач, «Кавказ и Меркурий» җәмгыятеннән вексельләр биреп, «Потехин» пароходын сатып алды да, үзе капитанлык итеп, төпчеге Сашаны лоцманлыкка өйрәтте. Яшь лоцман шәһәр белән Комүзәк арасында пассажирлар ташыды, Иделне бакеннар ярдәмендә «укырга» өйрәнде, ә аннары, яше белән бергә тәҗрибәсе дә арта башлагач, капитан күперчегендә әтисен алмаштырды.

Хәйдәр әнә шул Саша белән малай чактан бергә уйнап үсте. Аларның әчкерсез якынлыгы җәй саен үткәрелгән йодрык сугышларыннан башланды. Икесе дә кыю, аяктан аумаслык таза һәм кыйнашырга хәтсез оста иделәр.

Йодрык сугышы, кагыйдә буларак, көн авышкан кичке сәгатьләрдә башлана. Бистәнен татар ягы белән рус ягы балалары тау астына чыгып «Давай, давай!» кычкырып сугыш кызыштыралар. Сугыш башланып китә. Кыза төшкәч малайларның зурраклары кушыла. Аннары егетләр, ниһаять, эштән кайтып ашык-пошык тамак ялгап, сугыш мәйданына чапкан сакаллы абзыйлар да кушылгач, тау асты мәхшәр оясына охшап кала. Якшәмбе көннәрендә бу йодрык сугышларына шәһәрнең ерак почмакларыннан килеп баш-күз тиштереп кайтучы һәвәскәрләр аеруча күп була. Дөрес, кайбер көннәрдә атлы казаклар эләккән берсенең аркасын камчы белән яра-яра сугышны туздырган булалар, әмма бу болай гына, асылда исә йодрык сугышының бер бистәдә яшәп, бер эштә эшләп, бер нужа чигеп көн иткән рус белән татар арасында милли дошманлык сөремен саклауда әйтеп бетергесез көче бар. Ләкин, ни генә булмасын, андый кара көч дуслык-туганлык кебек якты көчкә тиңләшә аламы соң! Шунысы кызык: кичләрен саф-саф басып, йөзгә-йөз торып сугышкан рус һәм татар кешеләре, икенче көн иртәсендә эшкә барышлый, бер язмыш иләредәй очрашып хәл белешәләр, бер янчыктан тәмәке төрәләр, әгәр инде Саша белән Хәйдәр очрый калса, әйтерсең лә зур бер баталия алып барган генераллардай, кичәге сугышка йомгак ясыйлар, бер-берсен җәлләп, имгәтерлек сугудан тотылып калуларын сөйләп мактаналар, куаналар. Әнә шул Фадеев малае Саша вакытында Хәйдәрне үз пароходларына матрослыкка чакырды. Хәйдәр бераз вакыт эшләп тә йөрде. Ул чагында «Потехин» Бакуга, Махач-Калага баручыларны рейдта торучы диңгез пароходына илтеп кую бурычын үти иде. Чөнки зур-зур диңгез пароходлары Идел елгасына, бигрәк тә су кайткан чакта, керә алмыйлар иде. Хәйдәр шул диңгезгә йөрү көннәрендә матрос булып эшләде. Пароход командасы тырыш матросны бик яратты, якын итте, вахта хезмәтен пөхтә үтәве өчен хөрмәтләде, әмма егетнең бер кимчелеге ачылды: диңгезгә ярамас булып чыкты. Аеруча диңгезнең җилле-давыллы чакларын бик авыр кичерде ул, башын күтәрә алмаслык хәлдә укшып ятты, ә зур дулкыннарда аңын җуярлык хәлгә килгәч, аңа бу эштән китәргә киңәш бирделәр.

Хәйдәрнең «Потехин» белән булган танышлыгы әнә шулай иде.

* * *

Габидулла забастовкачылар белән булып алган сүз көрәштерүдән җекләнеп кабинетына кергәч тә тиз генә басыла алмады. Койрыгы кысылган мәчедәй үрле-түрле йөренә торгач, стенадагы телефон аппаратына килеп ябышты.

— Центральный?! 3—55 не бирегез!

— Готово! — диде центральныйдагы кыз.

Габидулла боргычны кабат борды.

— Огурцов әфәндеме?! Исәнмесез! Ваше благородие, сезгә бер йомыш төште бит әле. Нинди йомыш дисезме? Мин бүген заводыма яңа эшчеләр көтәм. Шуны белеп алган забастовщиклар露 котки салалар. Араларында коткычы да бар. Шул котырта, явыз. Әйе, әйе. Зинһар өчен җибәрә күрегез, ваше благородие! Усалларын, кыюларын! Хозяин магарычтан калмас диегез үзләренә. Ә сезнең яхшылыгыгызны онытмам. Ярый, рәхмәт сезгә, туганкай!

Габидулла телефон трубкасын эләргә өлгермәде, завод ишегалдыннан «киләләр!», «киләләр!» дип кычкырган тавышлар ишетелде. Габидулла тәрәзәгә атылды. Эшчеләр барысы да пристаньга таба ашыгалар иде.

«Потехин» якынлашты. Хәзер инде пароход борынында басып шәһәр күзәткән ярлы-ябагайны ачык күреп була иде.

Менә пароход морҗасыннан ак пар бөркелде, һәм шундук үкертеп кычкырткан тавыш ишетелде. Бу «Потехин» капитанының «килеп җиттем, әзер торыгыз» дигәне иде.

Салтыков һәм аңа ияреп завод идарәсеннән чыккан берничә конторщик пристаньга таба йөгерделәр.

Моны күргән Андрейның күңеле тыныч түгел иде. Ул үзеннән бер биш адым читтәрәк басып торган Нургали агай янына килде.

— Бу мәхлук эшне бозмасын иде...

Нургали агай да тынычсыз иде:

— Муенын борып кына атасы!

— Атабыз аны!

Андрей, таныш тавышны ишетеп артына борылуга, Петяны күрде.

— Хәйдәр дә монда,— диде Петя.

— Петя,— диде Андрей кискен бер кызулыкта,— әнә теге ике аяклы бәланы күрәсеңме? Пароходны каршылаганчы «яшереп» торасы иде үзен.

— Киттем!

— Чү, сабыр! — диде Андрей егетнең кулыннан тотып,— кара аны, муенын борырга дигәч тә...

— Аңлашыла! — диде Петя һәм китеп тә барды.

Пароход завод пристаненә килеп җитте. Палубадагы матрос пароход бортын бәрелүдән саклаган түгәрәкләрне төшергәч, чалкы ыргытты. Әнә ишек авызында Гордеев баскан, калганнар барысы бергә укмашып, аның артына тыгылганнар.

— Кая киләсез, дуслар? — дип кычкырды Нургали агай.

Гордеев җавап бирде:

— Башкин заводына! Эшкә!

— Ялгышасыз, дуслар, болай итеп...

Гордеев сүзсез калды. Күренеп тора, ул нинди ялгышу турында сүз баруын аңламый.

— Нинди хәйләгә җәтмәсенә эләккәнегезне беләсезме?

Пароходтагылар тынычсызланып үзара сөйләшә башладылар.

Нургали агай ихлас күңелдән әйтте:

— Сезне бит, туганнар, Суганов белән Башкин корган хәйлә җәтмәсенә каптыралар хәзер.

Пароход пристаньга килеп орынды. Югарыдагы күперчектән капитанның «На месте!»се ишетелде.

Матрослар басма суздылар.

Габидулла үз кабинетында читлектәге коштай арлы-бирле бәрелде. Әле урам якка, әле завод капкасына караган тәрәзәгә килде. Менә-менә капкадан килеп керергә тиешле городовойларны көтте, аннары завод пристаненә караган яң тәрәзәгә килде һәм... аптырап калды.

3*

Басма сузылса да, пароходтан чыгучы күренмәде. Чү! Каршылаучылар үзләре пароходка керә түгелме? Габидулла күзләре белән Салтыковны эзләде. Кая ул юньсез! Нишләп хәрәкәт итми ул? Ни өчен килүчеләрне үзе каршыламый?

Тәрәзәдән атылып чыгар хәлгә җитте Габидулла һәм, шулай тузынган килеш, ишекне аягы белән тибеп ачты да, контора өстәлләренә бәрелә-сугыла, абына-сөртенә, пристаньга йөгерде.

Басма сузылуга этешә-төртешә пароходка керүчеләр арасында Хәйдәр белән Петя да бара иде.

Андрей Хәйдәрне ашыктырды.

— Тиз! Тиз! Аңлыйсыңмы? Туры капитан күперчегенә мен. Мен дә әйт: «Поддержи!» диген.

Хәйдәр белән Петя, күперчеккә сузылган баскыч басмаларыннан биш атлыйсын бер атлап капитан янына ашыктылар. Андрей, Нургали һәм Мортаза пароходтагыларга хәлне аңлатырга керештеләр.

Ике егетнең шак-шок басып югары катка үзе янына менүләрен күргән яшь капитан, Хәйдәрне танып алгач, башта әллә ни уйламады. Я иске танышы итеп килә торгандыр, яисә йомышы төшкәндер. Әнә янында икенче берәү дә бар, бәлки шуңа эш эзли торганнардыр?..

Капитан Хәйдәрне дусларча ачык чырай белән каршылады.

— А... Гейдар, нихәл, годок?!

— Сашка, друг, знаешь что? — Хәйдәр ялварып диярлек әйтте: — Бер минут калма син монда! Понял?! Хәзер үк ычкын моннан! Югыйсә эшнә бозасың!

— Постой... Яхшылап кына аңлатчы, — диде капитан.

— Соңыннан барысын да аңларсың. Хәзер, давай, бер минут торма! Тиз! Бир командаңны!

Капитан тәмам аптырады:

— Нәрсә син?

Хәйдәр ачуланып та, борчылып та, тынычсызланып та әйтте:

— Ну инде!.. «Нәрсә», «Нәрсә». Әйтәләр бит сиңа — соңыннан, дип. Давай, кузгал тизрәк!

Сүзгә Петя кушылды:

— Саша, әгәр син китергән кешеләр заводта калсалар, бондарьларның забастовкалары өзелә. Аңлыйсыңмы?!

— А я причем?! — дип гаҗәпләнә башлаган капитанны Хәйдәр бүлде:

— Эш причемда түгел! Син поддержи бондарьларны!

Астан Андрейның тавышы көчле яңгырады:

— Әй, капитан, үз ана телебездә сорыйм мин сездән, отчаливай!

Яшь капитан, рупорын авызына алып, матросларга команда бирә башлады:

— Убрать трап! Отдай носовой!.. — Машина бүлеге белән сөйләшү трубасына авызын куйды: — Правый вперед!..

— Есть «правый вперед!» дигән җавап ишетелде астан.

Пароход тәгәрмәчләре шапылдап әйләнде.

— Полный!

Җан-фәрманга чабып килгән Габидулла минутның ниндидер бер өлешендә соңлады. Гадәттә, мондый хәлләрдә, кыю пассажирлар сикереп төшеп тә пароходка эләгә алалар, әмма Габидулла шүрләде.

Яр буендагы эшчеләрнең усалраклары завод хуҗасын үчекләп тордылар:

— Давай!

— Сикер!

— Һоп!

Калганнар хахылдашып көлделәр. Хурлануыннан нишләргә белмәгән Габидулла, кулларын болгый-болгый, кычкырды.

— Әй, капитан! Стой! диләр сиңа, стой!..

Ләкин аның сүзләре яр читендәгеләрнең шатлык тавышлары эчендә батып калды.

Хәйдәр ихлас күңелдән елмаеп капитан дустына карады:

— Молодец, друг! Әнә, ишетәсеңме, бар кеше рәхмәт яудыра үзеңә.

Габидулла хурлануыннан еларга җитешеп этәчләнде.

— Стой! Стой...

Шул чагында кемнеңдер: «Полиция!» дигән тавышы ишетелде.

«Полиция» сүзен ишетүгә, Габидулла ялт борылып артына карады. Завод капкасыннан берсеннән-берсе таза дүрт кылычлы кереп килә иде.

Габидулла аларны күргәч, бар ачуына:

— Как-к-ого черта опаздали! — дип сүгенә башлаган иде, «Потехин»ның үкереп кычкырган тавышыннан бүленгән завод хуҗасы, бу хурлыкка артык түзә алмыйча, барысын бергә ата-бабасы белән сүгә-сүгә, конторасына кереп китте.

* * *

«Потехин» пароходы белән булып узган вакыйга, шуның өстенә тагы управляющий Салтыковның табышмаклы хәлдә югалуы шәһәр полициясен кискен чаралар күрергә мәҗбүр итте.

Шул ук көнне департамент канцеляриясендә бу вакыйгаларга карата язылган циркулярда алтынчы участок башлыгы Огурцовка шелтә бирелеп, киләчәктә шуның ише хәлләрнең кабатланмавы өчен тиешле чаралар күрү таләп ителде. Циркулярның күчермәләре шәһәрнең барлык полиция участокларына да таратылды. Ә жандармерия идарәсе башлыгы подполковник Сагайдачный кабинетында якын арада тормышка ашыру өчен өч чара билгеләнде. Беренче чара: кем ул Андрей? Шушы сорауга төгәл һәм ачык җавап табарга. Икенчесе: көймә күтәрүчеләр һәм балыкчылар арасында берничә провокатор сырыштырырга. Өченчесе: «үзенең хатлары һәм төрле бәетләре белән кара халыкка хәвефле йогынты ясаган» Хәйдәрне фронтка озату белән өркетеп карарга, теле ачылмасмы? Әгәр ачылырдай булса, акча төртергә.

Шул ук көннең эңгер-меңгерендә Андрей группасы Җамал солдатка өенә «җыен»га чакырылды. Касыйм капка төбендәге утыргычта калды. Бирәдән урамның ике ягы да ачык күренә. Әгәр берәр шикле кеше килеп чыга калса, Касыйм башы өстендә генә торган тимер чыбыкны тартырга тиеш. Бу өй эченә үткәрелгән кыңгырау чыбыгы иде.

Андрей забастовканың уңышлы дәвам итүе турында йомгак ясады. Кәефе күтәренке иде аның.

— Хәзер инде, — диде ул, — безгә Башкинның эшчеләр куйган таләпләрне кабул итүенә ирешергә кирәк. Әгәр хуҗа шуна риза булса — ә аның өчен хәзер шуннан гайре чара юк — башка завод эшчеләренең дә бу көрәшкә кушылуларын көт тә тор. Ә бу безгә бик кирәк! Чөнки тиздән берничә заводка хәрби заказ бирәчәкләр. Аннары шушы көннәрдә фронттан бер эшелон яралылар киләчәк. Боларның барысы да халыкта ризасызлык тудырмый калмас, ә безгә ул ризасызлыкларны файдалана белергә. Комитетның заданиесе шундый.

Звонок тавышы ишетелде. Андрей тынып калды. Барысы да күтәреп тордылар. Җамал апа керде:

— Касыйм бер шикле кешенең узып китүен хәбәр итә. Андрей урыныннан торды:

— Хәзер безгә арткы урамга чыга торган аралыктан берәм-берәм таю ягын карарга кирәк, иптәшләр.

Барысы да урыннарыннан кузгалдылар...

— — ✦ — —

*Хисам Камалов*

# ЛИРИКА

## Туган җирем

Әй, яфраклар коела, әй, яфраклар
Агачыннан төшә аерылып,
Китә алмый газаплана алар
Туган ботакларга сарылып.
И, яфраклар...
Кәүсәсеннән инде аерылгач,
Бер көче дә калмый, бер яме,
Тик чүп бары...
Туган җирем, синнән
Аерылмаган чакта, мин әле
Әйбәт кенә: көч тә, дәрт тә миндә.
Ә аерылсам, бетәм, корышам:
Юкка барысы, берни майтаралмыйм
Юкка янам, юкка тырышам.
Эвакуацияләнгән
Бала кебек
Мин елмаймас булып боегам,
Гомерлеккә туган әниемнән
Үги кулга калган күк булам.
Туган җирем, синнән аерылсам!!
Бакыр йөгертелгән ул яфраклар.
Моңсулана карап шуларга.
Көндез куркытылган ярканатлар кебек
Белми алар
Кая кунарга!

## Парча

Сүзләр бетте.
Аңлаталмадым шул,
Күкрәктәге чын хис — ут кына!
Үзем куркам,
Янымдагы чибәр
Хисләремне өерә упкынга.
Гүя барам мин яр кырыеннан,
Упкын суыра — чак-чак атлыймын,
Аңлатырга ихлас күңелемне
Бер чара да һаман тапмыймын.
Һәм кулларын алам кулларыма,
Пульсын тоям аның күңелдә.
Ә йөрәкләр деп-деп тибеп гүя
Сөйләшәләр
Морзе телендә...

## Җыелышта

Мине теткән чакта бар иптәшләр
Аерылды ике лагерьга:
Бер ишләре чыкты көч ягына,
Бер ишләре хаклык ягына.
Хаклык миндә, ә көч түрәдә бит!
Ә көч күбрәк тарта кешене.
Алдын уйлап кайсы исәп йөртә —
Иртәгеге көнен эшенең.
Бер яраткан ышанычлы дустым
Ничек шулай миңа сугалды?
Шул минутта тагы нәрсәләргә
Ышанычым минем югалды?!
Тик югалтып кына калмадым ла,
Тирәнрәк белдем тагын дим...
Югалтулар үкенечле! Әмма
Югалтудан күбрәк алдым мин!

## Бер арбада

Бер арбада утырып барган чакта,
Сикәлтәгә төшсә тәгәрмәч,
Күрәсең син күршеңдәге кешене
Маңгайга маңгайлар бәрелгәч.
Син таныйсың аны һәм ул сине.
Тормыш атын гел ашыктыра,
Тормыш сикәлтәсе әллә кемнәр
Белән бәрелештерә
һәм таныштыра.
Бер чак төшкәч тормыш салуына,
Өзгән чакта хәлем бәгырьне,
Синең белән таныштым мин, дустым,
Шуңа ахры син бик кадерле!

## Куркытылган абый

Тege чакта абый куркытылган!
Шуннан бирле бик нык курка ул.
Бер кәгазьгә кул куясы булса,
Калтырана бер дә юкка ул.
Ә үзе бит начар кеше түгел,
Әмма үзен хаклы саный бик:
«Дөньяны бер
Рәшәткә аша күргән
Бармак аша карый алмый»,— дип.
Юлда һәр бау — елан күренә аңа,
һәр борылышта нидер сагалый...
Томырылып алга барган чакта
Як-ягына бер дә карамый,
Туры килә шул абыйга бәрелеп,
Чигенергә, сабыр итәргә,
Әллә ничә инстанциядән,
Боерык яки звонок көтәргә!

Куркытылган абый белән эшләү
Ай-ай авыр инде, түз генә!
Пенсиягә кайчан китәр диеп
Без көтәбез гажиз күз белән!

## Киткәндә

Суда йөзә нефть, май таплары,
Йомычкасы йөзә, агачы,
Тар гына бер яшел тасма әле
Причал белән бортның арасы.
Менә инде трапны алалар да!
Пароход кычкырта,
Каласыз:
Туган яклар, канат чыгарган җир,
Һаман ераклаша барасыз.
Өзгәләнә бәгырь, телгәләнә,
Аерылудан хәтәр җиксисең,
Каютага кереп,
Өстәлгә капланып,
Бер тавышсыз гына үксисең.

## Ул—туган ил

Юллар безнең булган төрле-төрле,
Кыен булды минем язмышым.
Синең кояш яңа чыгып килә,
Минем инде кояш баешым.
Тормыш аңлавыбыз төрле-төрле
Бер-берен нән котыла алмассың,
Ни күрсәк тә икәү бергәләшеп
Тартабыз без тормыш арбасын.
Нәрсә бәйли, нәрсә җигә безне?
Нәрсә илтә алга, максатка?
Ул — туган ил, безнең якты Рәсәй!..
Юл кыен да безгә, ансат та!

## Әзләнүче авызыннан

Кайчак кайгы пәрәвезе каплый
Якты көнне, матур өметен.
Сабын куыгы кебек өмет шартлый,
Башын ия кайчак егетен.
Бар нәрсәгә күнегеп була, ләкин
Җиңелүгә булмый күнегеп.
Калсам да мин ватык машинадай
Юл читендә авып, йөгенеп,
Ярсып тырышам, үземдә көч табам,
Нервыларым
Постромкадай бетсен өзелеп.
Авыр яраларга күнегеп була,
Җиңелүгә булмый күнегеп.

## Сандал

Минем йөрәк сандал шикелле,
Шуна куеп барсын сугалар:
Бер гаепсез дусны теткәндә,
Йөрәк инде сандал була ла!
Кайчак шундый кыза ачулар,
Бөтен нәрсә байдән ычкына,

Бер-берсенә дуслар «ябыша»...
Йөрәгемнән чәчри очкыннар.
Ачу — нигә? Ачу — пычак ул.
Ярар инде, җитәр, туктагыз.
Йөрәгемне сандал иттереп
Бер-берегезне салып сукмагыз!

## Син гафу ит

Синең белән минем мөнәсәбәт
Гел унга биш була еш кына:
Яхшылыгын мина ун булганда,
Ә минеке сина — биш кенә.

Мин сина гел, гел бурычлы калам,
Кайчан түләп, дим, бетерермен.
Яхшылыкка яхшылык белән түләп,
Кайчан нульгә нуль иттерермен.

Унмаганга әллә, туры килми
Юлларының һич мина тахыры.
Яхшылыгыңа яхшылыгым белән
Түләп бетерә алмам ахыры!
Син гафу ит!

## Тигезсезләр

Башта яшьнең аермасы да шул
Беленмәгән — сөю тигезли
бар нәрсәне: яшьне, ямьсезлекне
Тойгылар да була нигезле.

Торган саен ныграк пәйда була
Тигезсезлек хистә, фикердә.
Гомер ел да гүя субүләрдәй
Аера аларны
һаман икегә.

Яшь хатыны картны анламый башлый,
Өмет итеп сөю шәрабен.
Карт нишләргә белми...
Бурлак кебек
Көчкә сөйри сөю корабын!

## Сәбәп тап

Кешеләрне сөйсәк кенә, кеше
Булып саналырга хаклы без.
Ә сөймәсәк, мин дә кеше, диеп
Дәгъваларга һич юк хакыбыз.
Нинди бәхет кешеләрне сөю!
Игелек итү хет бер кешегә!

Кеше кешегә ярдәм итсә генә,
Кирәклеген үзенең төшенә.
Бер әчкерсез сөю яктың белән
Якты өстә кеше күзенә.
Кешеләргә игелек итү өчен
Сәбәп тап син һаман үзеңә!

*Сафа Сабиров*

# КАПИТАННАР

*Хикәя*

## I

Зәйтүнә бүген дә иртүк уянды.

Гаҗәп хәл, элек, эшкә йөрергә кирәк булганда, ул йокыдан уяна алмый йөдәп бетә, соңга калмыйм дип йөгерә-йөгерә бара иде. Ә хәзер, ялга чыккач, уч иткәндәй, йокысы качты: вакытын кая куярга белми аптырый башлады.

Кышкы айларда, затонда торганда, аны Илбарис уята иде. Илбарис башта үзе уяна, үзе чәен әзерли, тын гына ашап-эчкәч, өстенә-башына киенә һәм шуннан соң гына Зәйтүнәне уята. Бик ашыккан чакларда да ул, чыгып китәр алдыннан ишек янында тукталып кала һәм, сүзсез генә саубуллашкандай, сизелер-сизелмәс елмаеп, бер мәл Зәйтүнәгә карап тора. Аннары, кире кайтып, саклык белән генә аның одеялын рәтли, ак мендәр өстендә чәчелеп яткан кара чәчләрен сыйпап куя. Ә Зәйтүнә, инде уянган булса да, әле һаман йоклагандай, күзләрен ачмыйча, юри дәшмичә иркәләнеп ята һәм Илбарис чыгып киткәч кенә атылып торып, ашыга-ашыга киенә башлый иде.

Ә менә бүген янында Илбарис та юк, эшкә ашыгасы да түгел, барыбер иртүк уянды. Өй эче әллә ничек шыксыз күренде аңа. Өченче көн дә, кичә дә шулай булган иде. Ел буена көтеп алган ял көннәре шулай өй саклап күңелсез үтәр микәнни?..

Бер уйларга тотынсаң, башка нилар генә килми. Хәтта хәтерләве уңайсыз булган вакыйгалар, инде онытылган кешеләр искә төшеп йөдәтә. Әнә Илбарис белән бергә эшләүче капитан Әсәдуллин да әллә кайдан гына искә төште дә һич тә күз алдыннан китми. Һаман бер читтән көлемсерәп карап тора, һаман каядыр чакыра һәм күңелне җилкендерә.

Коридорда телефон шалтырады. Зәйтүнә өстенә кыска җиңле зәңгәр халатын гына киеп чыкса, Илбарис икән. Телефоннан аның:

— Зәйтүнгөлем, синме бу?.. Иделдән сәлам сиңа! — дип кычкырган шат тавышы ишетелде.— Причалдан шалтыратуым, әле генә килеп туктадык... Тиздән монда митинг булачак, бөтен начальство килә бугай: безнең теплоходка күчмә вымпел тапшырачаклар... Югыйсә, йөгереп кенә кайтып килгән булыр идем... Ишетәсеңме, кайтып килгән дә булыр идем, мин әйтәм...— Илбарис тагын нидер әйтмәкче иде бугай, әмма ниектер тыелып калды һәм, әйтер сүзен таба алмаган кеше кебек, тамагын гына кырып куйды.

Зәйтүнәнең кинәт кәефе китте.

— Я, әйтеп бетер инде... Авызыңа су алдыңмы әллә? Балык кебек телсез калдың...— дип ирен җиңелчә шелтәли башлады.— Их, үзеңне дә әйтер идем, ничә көннәр күрми торган хатыныңа сагындым дип бер сүз әйтсәң, телең калыр дип куркасыңмы?

Илбарисның еш кына шулай тыелып кала торган гадәте бар. Зәйтүнә аны шуның өчен өнәп бетерми дә. Кайчакларда, үзе дә абайламастан, аңа тәксе сүзләр дә әйтеп ычкындыра. Менә хәзер дә ачуын тыя алмыйча:

— Я, авызыңдагы суны йот та, әйтәсе сүзеңне әйтеп бетер,— дип ихтыярсыз тагын бер мәртәбә төрпе генә чәнчеп алды. Аның күз алдына тагын Әсәдуллин килеп басты, һәм ул үзе дә көтмәгәндә, кисәк кенә күңеленә килгән уен шатланып тезеп китте: — Илбарис, беләсеңме нәрсә?.. Синең белән бергә мин дә китәргә булдым... Әйе, әйе, мин дә синең белән рейска китәм дим... Мин хәзер ялга чыктым бит. Өйдә бер ялгызым бикләнеп ятканчы, дөнья күреп кайтырмын, ичмасам. Хәзер тиз генә җыенам да юлга чыгам.

— Килеп җитә алмавың бар... Аннары күңелсез дә булыр үзеңә, ник килгәнеңә генә үкенерсең. Без пассажирлар йөртмибез ич,— диде Илбарис, аны дүңдермәкче булып.

Әмма Зәйтүнә авыз ачарга да бирмәде:

— Юкны сөйләп тә торма... Барам булгач барам инде, менә шул! Хәзер чыгам да чабам. Бер аягым монда, икенчесе — пристаньда...

Һәм Зәйтүнә шулай эшләде дә. Аннан-моннан тиз генә җыенып, кечкенә чемоданын кулына алды да, шат күңел белән, яр буйлап турыдан гына җил-җил атлап пристаньга ашыкты.

Иске пароход һәм баржалар тулы кысынкы затоннан елга буена чыккач, аның күңеле тагын да ачылып китте. Кая карама, чиксез киңлек. Кояш нурына чумган Идел әллә кайларга җәелгән. Түбәндә, яр итәгендә меңнәрчә көмеш тамчылар җемелдәтеп ярга вак дулкын кага, яшел болында төрле кошлар сайрый. Зәйтүнәнең дә күңеле җырлый...

Аның элемтә техникумында укыган вакытта ук әле Илбаристан күчеп җырлый торган бер җыры бар иде. Яр буена чыгып киң Иделне күргәч, ул тагын шул җырын авыз эченнән генә көйли башлады:

> Идел бит ул тирән бит ул,
> Тирән бит ул, киң бит ул.
> Сөйгән ярың кыю булмаса,
> Яшь йөрәккә кыен икән ул...

Пристаньга җитәрәк, вокзал мәйданында ыгы-зыгы йөреп торган халык арасыннан бер елгачы Зәйтүнәгә ничектер таныш кебек күренде. Рәтләбрәк караса, Әсәдуллин икән.

Зәйтүнә почмактагы киоск артына тукталып, ридикюль көзгесенә карый-карый, кулъяулыгы белән тиз генә күз төпләрен сөртте, маңгаена салынып төшкән чәч бөдрәләрен киң читле салам эшләпәсе астына кыстырып куйды. Һәм шунда ук: «Күр инде мин юләрне, ничек кыланам!» дип үзенә-үзе гаҗәпләнде һәм кем беләндер көлә-көлә сөйләшеп килүче Әсәдуллинга каршы чыкты.

Сумала кебек кап-кара чәчле, хәйләкәр елмаеп карауч зур калку күзле, төз генә гәүдәле бу яшьтәш егет былтыр затонда кышлаганда Зәйтүнә тирәсендә байтак бөтерелгән һәм кыз күңелендә мәхәббәт чаткысы да кабызгандай булган иде. Ләкин ул чаткы ничектер дөрләп китми калды. Кызның күңеле гел элекке дусы Илбариста булды. Әнисе дә шул якны тартты. Сүз уңае килгән саен:

— Кайбер кызылавызлар кебек ләчтит сатарга оста булмаса да, гомер итү өчен бик төпле егет,— дип гел Илбарисны мактады һәм көннәрдән бер көнне кызын аңа кияүгә бик шатланып бирде.

Шулай да күркәм егет, зур теплоход капитаны Әсәдуллин Зәйтүнә күңеленнән бөтенләй юк булмады. Инде тормышка чыкканнан соң да, ул еш кына Зәйтүнәнең исенә төшкәли, очрашкан минутларда төрле уен-көлке, йөрәккә ятышлы сүзләре белән аның күңелен иркәли иде. Хәзер, Зәйтүнәне күргәч тә, гадәтенчә ачылып китте:

— Чү! Кемне күрәм мин?! Өнемме бу, төшемме? — диде ул, Зәйтүнәнең чемоданын алып.— Нинди җилләр монда алып чыкты сезне?..

Көтелмәгән бу очрашуга Зәйтүнә үзе дә бик шат иде.

— Дөресен генә әйткәндә, нинди җилләр алып килгәнен үзем дә белми калдым. Иделдә бер йөреп кайтасым килде.— Зәйтүнә кояш нурларыннан җемелдәп салмак кына чайкалган киң елгага карап алды.— Кешеләр әнә Иделгә юри дә киләләр бит әле, ял вакытларын пароходта үткәрәләр. Өйдә бикләнеп ятканчы, нигә, мин әйтәм, миңа да бер дөнья күреп кайтмаска...

— Бик тә шәп, Зәйтүнә, бик әйбәт иткәнсез... Башкалар ничектер, белмим... Мин үзем сезнең килүгә бик шатмын.— Соңгы сүзләренә басым ясагандай, Әсәдуллин буш кулы белән Зәйтүнәнең терсәгенә чак кына кагылып та алды.— Җитмәсә тагын, нинди шатлыклы көнгә туры килдегез... Бүген бездә зур бәйрәм бит. Күрәсезме, «Урал»ны ничек бизәдек!..

Причалда ялгызы гына торган йөк ташучы «Урал» теплоходы чынлап та әле генә заводтан чыгарылгандай өр-яңа һәм соклангыч матур иде. Каюта тәрәзәләре, трапларның тоткалары кояшта җемелди. Акка буялган биек мачтасы очында кызыл флаг, аннан бераз гына түбәндәрәк күчмә вымпел җилферди. Палубасында бәйрәмчә киенгән бер төркем яшьләр. Кызыл почмакның ачык тәрәзәсеннән музыка тавышы ишетелә. Ә трюмнарына транспортерлар буенча кар кебек ак тоз агып тора иде.

Яр буена килеп җиткәч, Әсәдуллин калку күзләрен зур итеп ачып бер мәл сокланып карап торганнан соң, үзенә бер горурлык белән сөйләп китте;

— «Урал»ны әйтәм, чын баһадир бит!.. Үзебез дә молодец, сынатмадык, шәп эшләдек. Идарә начальнигы безне социалистик ярыш флагманы дип мактады. Күрәсезме, бөтен команда нинди шат... Ә минем өчен бүген икеләтә бәйрәм.... Әйе, әйе, чынлап әйтәм, икеләтә бәйрәм...

Зәйтүнә аның тел төбе кая тартканын аңламыйча:

— Ничек инде икеләтә бәйрәм? — дип кызыксынып сорады.— Икенчесе ни була инде аның?..

— Әйе, Зәйтүнә, миңа бүген ике бәйрәм берьюлы килде. Берсе бөтен команда белән уртак бәйрәм — навигация планын Иделдә беренче булып үтәү шатлыгы. Ә икенчесе... икенчесе синең килүең... сине күрү шатлыгы...

Аларның транспортерлар яныннан сөйләшә-сөйләшә төшеп килүләрен теплоход палубасындагы яшьләр дә күрделәр. Арадан бер усал теллесе хәйран калган кыяфәт белән пырхылдап көлеп җибәрде:

— Туганкайларым, күрегез әле безнең көязне, нинди чибәрне эләктергән... Менә бу балыкчы... Әйтсәң дә ярый, ичмасам...

— Син нәрсә, төнлә туган җан, күзеңне кан басты мәллә?.. Күрмисеңмени, безнең беренче штурман хатыны бит ул,— дип, кемдер аны шундук бүлде һәм каюталар ягына борылып хәбәр итте: — Илбарис Рамазанович, сезгә кунак килә, каршылагыз...

Зәйтүнә белән Әсәдуллин причалдан палубага күтәрелгәндә ачык коридордан ак кителен төймәли-төймәли Илбарис үзе килеп чыкты.

— Әһә, килеп тә җиттеңме? — диде ул, сыгылмалы такта траптан менеп килгән Зәйтүнәне каршылап.— Үзең бер дә чикерткәдән ким түгел инде, бик тиз килеп җиткәнсең.

— Анысы да монысы, Илбарис дус, син башта миңа рәхмәт әйт. Әгәр мин очрап туктатмасам, Зәйтүнәңнең безгә килү башында да юк иде,— дип, Әсәдуллин да шаяртып алды һәм кулындагы чемоданны Илбариска бирде.

Шул чак причалга бер матрос белән милиционер килеп туктады. Палубадагы кешеләр, үз күзләренә ышанмагандай, бер-берсенә аптыраулы карашып алдылар. Милиционер китергән киң җилкәле, базык гәүдәле ул матрос кем беләндер сугышкан булса кирәк, әле тынычланып та

өлгермәгән: ачык изүле күлмәгенең зәңгәр якасы ертылган, сул күзе өсте дә бераз сыдырылган иде. Аны озата килгән милиционер, кулы белән хәрбиләрчә фуражкасына җиңелчә генә кагылып исәнләшкәннән соң, Әсәдуллинны бер читкәрәк дәшеп алды да:

— Иптәш капитан, менә бу сезнең егет бугай. Буфет янында ниндидер матрослар белән тавыш куптарып сугышып йөри иде,— дип хәбәр итте.— Менә бит ничек... Үзе болай әллә ни исерек тә түгел шикелле. Без аны бүлектә тоткарлап тормадык инде, бүген генә кучмә вымпел алган коллективка тап төшерәсе килмәде... Чарасын үзегез күрегез...

Әкрен генә әйтелгән булса да, бу сүзләрне палубадагылар барысы да ишетте. Әсәдуллинның бөтен йөзе агарып китте, гаепле матроска калку күзләре белән көйдереп алырдай зәһәр караш ташлады. Әмма телдән ачуын сиздермәде, хәтта ачык йөз белән елмаеп та куйды.

— Рәхмәт сезгә, бик дөрес эшләгәнсез. Әлбәттә, чарасын күрербез. Үзем күрермен... Бүтән кабатланмаслык итәрмен,— дип, милиционерга вәгъдә бирде һәм ныклап аның кулын да кысты.

## II

Һәр көн шулай була: кич җитү белән, ачык палуба теплоходта иң җанлы урынга әйләнә һәм төн уртасына кадәр шау-гөр килеп тора. Вахтадан бушаган барлык яшьләр шунда җыелып төрле уеннар уйныйлар, кичке салкынча саф һавада күңел ачалар, ял итәләр.

«Урал»да бүген аеруча шатлыклы көн. Көндез пристаньда башланган бәйрәм кич җитәрәк тагын да җанланып китте. Илбарисны ашатып-эчертеп кичке вахтага озаткач, тиздән Зәйтүнә дә палубага чыкты һәм повар кыз Наташа янына барып утырды.

«Урал» хәзер юлда иде инде. Корыч корпусы белән киң елганы урталай ярып һәм үз артыннан йөгерек дулкыннар калдырып ул агымга каршы бара иде. Өске палубасында бәйрәмчә киенгән матрослар, машинистлар, рулевойлар һәм практикантлар җыелган. Арадан әле берсе, әле икенчесе мәзәк әйтеп халыкны көлдереп ала иде. Менә кичәне алып баручы, үзе дә бик җор кеше механик Федор Степанович, команда членнарыннан кемгәдер охшатып, әйтер сүзен онытkандай аптыраулы кыяфәт белән:

— Әйе, әйе, хәтерләдем... Хәзер теплоходыбызның атказанган солисты Харис Әсәдуллин җырлый,— дип белдерде.— Ул безгә «Дуслык елгасы» җырын башкара... Харис, шулай бит...

Шаярып әйтелгән бу сүзләрдән барысы да көлешеп алдылар. Әмма уртага чыгып баскан җырчы үзе хәтта елмаймады да. Ул никтер карңгы чырайлы, чак кына калку соргылт күзләренең карашы каядыр читкә юнәлгән иде. Зәйтүнә аны ирексездән кызганып куйды һәм янында утырган Наташаның колагына пышылдап кына:

— Карагыз әле, ни булган бу егеткә? — дип сорады.— Ә үзе сезнең капитаныгызга охшаган кебек.

Бу минутта Наташа ниндидер уйга чумып утырган булса кирәк, Зәйтүнә эндәшкәч, кинәт йокыдан уятылган кеше кебек, сискәнеп китте һәм әйләнә-тирәгә каушаулы карап алды.

— Бертуган абыйсы булгач, охшаса да гаҗәп түгел,— диде ул.— Әмма холыклары белән алар бер-берсенә аз гына да охшамаганнар. Абыйсы гел чит күрә аны... Бүген пристаньда кемнәр беләндер ызгышкан өчен хәтта бөтенләй теплоходтан төшереп калдырырга уk җыена бугай...

Пристаньда күргән вакытта Зәйтүнә игътибар белән карамаган икән. Тик менә хәзер Наташа әйткәч кенә, Зәйтүнә аның көндез причалда милиционер китергән егет икәнлеген төсмерләде. Абыйсының ачы ник

үз итмәвен белергә теләп, ул Наташага тагын сорау бирмәкче булган иде, ләкин шул арада баянчы уйный башлады һәм Харис күкрәген тутырып бер тирән сулыш алды да озын көйгә җырлап җибәрде:

Иделкәем минем, туган җирнең
Матурлыгын күрәм суында.
Иделкәем минем, җырым да син,
Ерак илтә торган юлым да...

Егетнең тавышы башта бераз кыюсызрак яңгыраса да, аннары бик тиз ныгыды һәм эчке бер моң белән кичке тын Идел өстендә дулкын-дулкын тирбәлеп таралды, үзе белән бергә тыңлаучыларны да ерак-еракларга алып китте:

Маякчы маяклар тезгән
Минем юл читләренә,
Кая гына юл тотсам да,
Ышанам җитәремә...

Аннан соң тагын берничә кеше җырлады, төрле мәзәк һәм декламация сөйләүчеләр дә, биючеләр дә табылды. Шаян җырлардан, күңелле мәзәкләрдән рәхәтләнеп көлделәр, моңлы җырларны тын да алмыйча тирән уйга талып тыңладылар.

Беренче җырдан күңеле тулган Зәйтүнә башкаларны әллә ни бирелеп тыңлый алмады. Колагында һаман Харис тавышы яңгырап торды. Ана карап алган саен күңеленнән ихтыярсыз: «Нәселләре белән шундый нечкә хисле булырлар икән... Ник соң алар үзара килешә алмыйлар, бер-берсен чит күрәләр?» дип уйлады.

Бераздан, биюләр башлангач, Зәйтүнә кызыл почмак тәрәзәсе каршына килеп басты һәм Федор Степанович белән әңгәмә башлап җибәрде. Озакламыйча алар янына Әсәдуллин да килде. Пөтхә итеп үтүкләнгән ап-ак кителе, кара чалбары аның төз гәүдәсенә килешеп тора, янәшә якын урнашкан калку күзләре биек фуражкасы астыннан ягымлы елмаеп карыйлар иде.

— Нигә болай читтә генә торасыз? — диде ул, ак тешләрен ялтыратып.— Әйдәгез, алгарак күчик. Күрик әле, ничек биилэр икән?

Федор Степанович көтмәгәндә кулларын җәеп җибәрде дә Әсәдуллинны шелтәли башлады:

— Их, Якуб Хисамович, карап торам-торам да аптырап калам... Без егет чакта туташ-ханымнарны биергә чакыра идек, ә син урын турында сөйләнеп вакыт уздырасың... Сина берәр ни булмагандыр, йөрәгеңә йон үсмәгәндер ич?..

— Әйе, әйе, Федор Степанович, әйтәсе дә түгел инде,— дип, Зәйтүнә дә шаяртып аны җөпләгән булды.— Хәзерге егетләрне белмәссең... Колакларына тукып тормасаң, үз акыллары җитми, күрәсең...

— Федор Степанович дөрес әйтә: гаеп миндә... Әлеге дә баягы, һаман шул сәбәп — кыюсызлык һәм булдыксызлык бәласе. Зәйтүнә, сез мине гафу итегез дә хатамны төзәтергә мөмкинлек бирегез,— диде Әсәдуллин һәм, яңа вальс яңгырый башлауга, Зәйтүнәне танцага алып чыкты.

Әсәдуллин затон клубында иң оста биючеләрдән санала һәм еш кына әллә нинди яңа танцаларны иң элек башлап бик күп кызларны шаккатыра һәм сокландыра иде. Алай ук оста булмаса да, Зәйтүнә дә танцага бик һәвәс һәм, кайбер шаян телләр әйтмешли, аяктан егылганчы биергә ярата иде. Оста биюче чибәр егет белән күңелле вальска бөтерелә башлауга, ул үзен йөгерек дулкыннар арасында йөзеп киткәндәй тойды, бөтен тәнендә рәхәт җиңеллек хис итте. Әсәдуллинның ашкынып бөтерелә-бөтерелә биегән шапкә:

— Башкалар ничектер, белмим, ә мин үзем сезнең килүегезгә чиксез шатмын,— дип колагына пышылдап әйткән кайнар сүзләре аның күңелен тагын да нечкәртә төштеләр.

һәм ул, һич тә ышанмаудан түгел, тик болай гына, матур комплименттан бераз уңайсызлануын сиздермәс өчен генә:

— Алай ук түгел лә инде... Шулай күләргә ярыймыни? — дип шаярткан булды.

— Юк, Зәйтүнә, син белмисең... Син гел минем исемдә. Синең турыда уйласам да йөрәгемә ял була, күңелләрем күтәрелеп китә...

Әсәдуллин еш кына шулай итә: башка кешеләр алдында Зәйтүнәгә сез дип дәшсә дә, икәү генә калган чакларда, ничектер абайламастан гына, «син»гә күчә һәм әңгәмәне бөтенләй икенчегә борып җибәрә иде. Менә хәзер дә ул бер мәл сүзсез генә биегәннән соң:

— Бөтен бәла да әнә шунда, синең миңа ышанмавыңда шул,— дип, өметсезлек белән көрсенеп куйды.— Әгәр ышансаң, без инде дөньяда иң бәхетле кешеләр булыр идек...

Сүзнең кинәт җитди якка борылуыннан Зәйтүнәгә бөркү булып китте. Кем белгән аны, бәлкем, чынлап та шулайдыр. Ышанмаган булып, үз бәхетен үзе кире какмыймы соң ул?..

Моннан соң алар инде сүзсез генә биеделәр.

## III

Төн уртасы җитәрәк халык таралды. Кызыл почмакта һәм палубада утлар сүндерелде. Бөтен теплоходны караңгы тынлык басты.

Каютага кергәч, Зәйтүнә, Илбарисның вахтадан төшкәнен дә көтмәстән, тиз генә чишенеп йокларга ятты. Ләкин аның күзенә йокы кермәде, борчулы уйларыннан арына алмыйча, зур ачылган күзләре белән караңгыга карап байтак ятты. Аннары бераз саф һава алырга теләп тәрәзә янына килеп басты. Ачык тәрәзәнең ак пәрдәсен сизелер-сизелмәс кенә тирбәтеп кергән төнге салкынча дымсу һава аның ачык муеныннан, битләреннән сыйпый, рәхәт җиңеллек бирә иде.

Зәйтүнә тәрәзә пәрдәсен яртылай этәреп, тышка карады. Дөньяны төн карасы баскан. Әйләнә-тирәдә серле тынлык. Кайдадыр түбәндә бөтен теплоходны дерелдәтеп машина гүләве ишетелә... Идел үзе дә изрәп йокыга талган кебек. Караңгы су өстендә анда-санда калкавыч маяклар гына төн пәрдәсе аша кайдандыр килеп чыгалар да артта калып тагын караңгылык эчендә югалалар.

Зәйтүнәнең тынгысыз уйлары, шул маяклар кебек, бер-бер артлы калкып чыгалар да артта калган көннәрен исенә төшерәләр. Соңгы айларда ул, гомумән, күп уйлана торган булып китте һәм уйланган саен күңелендә бушлык, ниндидер ризасызлык тууын сизә башлады.

Әле кайчан гына Зәйтүнә төшенкелекнең нәрсә икәнен дә белмәгән гамьсез, шаян кыз иде. Ул кечкенәдән үк бик шук һәм үткен телле булып үсте. Бигрәк тә ул күрше малае Илбаристан көләргә ярата иде. Дөньясын онытып, әллә ниләр ясап йөргән өчен аны Хыялбай дип атаучы да, үсә төшкәч, елга техникумына укырга озаткан чакта: «Бар, капитан Немо булып кайт», дип көлеп калучы да Зәйтүнә иде.

Биш елдан соң затонга кайткан Илбарисны уйламаганда-көтмәгәндә клубта очраткач, Зәйтүнә күзләренә ышанмыйча хәйран калып озак карап торды. Аптыравын яшерә алмыйча:

— Кызлар, күрегез әле, безнең Илбарис түгелме соң бу?! — дип бик гаҗәпләнде һәм шундук: — Күрегезче үзен, кай җире капитан Немодан ким моның?!. Бер караудан гашыйк итәрлек... Хәтәр, бик хәтәр... Син монда безнең барыбызның да башын әйләндереп бетермәгәең...

Бу сүзләрне ул болай шаяртып кына, егетне бераз каушатырга теләп кенә әйткән иде. Әмма уеннан уймак чыга диләр. Көлеп кенә әйткән сүзнең бик тиз чынга әйләнгәнен үзе дә сизми калды Зәйтүнә. Кайчандыр чандыр гына буйлы, оялчан яшүсмер бүген исә кин җилкәле, сабыр хәрәкәтле чибәр егет булып кайткан. Чак кына кысынкы зәңгәр

күзләре ягымлы карыйлар. Бергә уйнап, бергә укып үскәнгәме, бертуган кебек якын да, сөйкемле дә иде ул.

Алар спектакльне бергә карадылар, бергә кайтырга чыктылар. Урамда көзге салкын җил ыжгыра, янгыр катнаш җепшек кар ява иде. Алар салкын җилне дә, җепшек карны да сизмәделәр, аерылышып китә алмыйча, бер-берсен озатышып поселок урамнары буйлап бик озак йөрделәр... Шул кичне алар бер-берсенә гашыйк булдылар һәм озакламыйча өйләнешеп бергә тора да башладылар.

Әмма семья тормышы Зәйтүнә көткәнчә матур булып чыкмады. Зәйтүнәгә киң холыклы һәм артык күндәм Илбарис ничектер кызыксыз, эчпошыргыч булып тоела башлады. Һәм ул кайчандыр үзенә гыйшык тотып йөргән Әсәдуллинны еш кына исенә төшерә, аның белән очрашкан вакытларда ихтыярсыз кабынып китә: «Ирең әнә шундый үткен булсын икән», дип еш кына сокланып куя иде.

Баягынак палубада биегән вакытта Әсәдуллин әйткән сүзләр, утка бензин сипкән кебек, монарчы күңел төбендә пыскып яткан әнә шул чаткыны янә кабызып җибәрделәр. Һәм ул кайта-кайта һаман бер сорауны кабатлады: «Чынлап та бөтен гаеп үземдә микәнни, ышанмыйча үземне дә, аны да бәхетсез итәм микәнни?..»

Карангыда каютада бер ялгызы шулай күңелсез уйларга чумып утырганда, кинәт якында гына кемнеңдер аяк тавышы ишетелде һәм, су астыннан калкып чыккандай, ачык тәрәзә каршына Әсәдуллин килеп басты. Ул никтер каушаган күренә һәм әледән-әле як-ягына борчулы карана иде. Аны күргә, Зәйтүнә дә сискәнеп куйды һәм, үзе дә абайламастан, шелтәле тавыш белән:

— Якуб, сез ничек монда?! Болай соң нишләп йөрисез? — дип сорады.

Әсәдуллин хәзер эш киеменнән: җинел кара китель, ак фуражка кигән. Күзләре ничектер тынгысыз ялтырый. Көтелмәгән очрашудан ул да уңайсызланып калды бугай. Ни әйтергә белмичә, бер мәл сүзсез торганнан соң:

— М-менә вахтага чыгар алдыннан бер карап, барлап йөрүем иде,— дип пышылдады һәм тәрәзә аша үрелеп Зәйтүнәнең кулларыннан алды.— Зинһар, гафу ит, кичер мин акылсызны. Үзеңне очратырмын дип өметләнмәгән идем, вахтага менешли тәрәзәң турыннан үтәргә теләвем генә...

Әсәдуллин тынып калды һәм тиз генә тагын әйләнә-тирәгә борчулы каранып алды. Аның сулышы кысылган, йөрәге күкрәгеннән бәреп чыгардай дөп-дөп сикерә иде. Зәйтүнә:

— Якуб, шулай ярыймыни?.. Җибәрегез мине,— дип кулларын ычкындырырга омтылса да, үзе ихтыярсыз аңа сыенды.

Әсәдуллин исә берни ишетмәде дә, ишетергә дә теләмәде. Тәрәзәдән яртылай эчкәрәк керә төшеп, калтыранган куллары белән Зәйтүнәне ачык иңбашларыннан алды, кочагына кысып иреннәреннән суырып үпте һәм кайнар сулышы белән көйдереп алырдай итеп һаман үз сүзен кабатлады:

— Мин бер генә минут та сине уйламыйча тора алмыйм... Аңлыйсыңмы?.. Синсез тормышым тормыш түгел, дөньяның яме юк... Бөтен киләчәгем, бөтен бәхетем-шатлыгым — барысы да синең кулда... Зәйтүнәм, бәгырем, тик бер нәрсәне ачык беләсем килә: син дә мине үз күрәсеңме... сөясеңме?.. Әгәр юк икән, дөресен әйт... Мине болай газаплама.

Зәйтүнә үзе дә аңа елышты һәм ни эшләгәнен уйламастан:

— Ник юк булсын?!. Күрмисеңмени... мин дә сөям ич...— дип пышылдады.

Шул чак төнге тынлыкны бозып, кемнеңдер карлыккан тавыш белән:

— Әй, пароходта-а... Акрынайта төшегез, балык...— дип сузып кычкырганы ишетелде.

Көтелмәгән бу тавыштан икесе дә коелдылар да төштеләр һәм шундук тиз генә бер-берсеннән читкә тайпылыштылар. Беркавым тын да алмыйча торганнан соң, башлап Якуб телгә килде.

— Курыкма, берни дә юк... Балыкчылар кычкыралар, балык китергәннәр,— диде.— Ярар, син тыныч йокла. Ә мин хәзер рубкага менәм, сине уйлый-уйлый вахтада торырмын...

Зәйтүнә Әсәдуллинның тимер траптан җиңел атлап югарыга күтәрелгәнен тәрәзәдән карап калды, рубкага менеп җиткәч, аның командирларча коры гына:

— Илбарис Рамазанович, ишетмисезмени? Балыкчылар кычкыра бит, ник акрынайтмыйсыз? — дип эндәшкәнен ишетте.

— Көннәрдән бер көнне бу балык безнең тамакка тыгылмагае,— диде аңа Илбарис.

Аннары түбәндә винт гүләве басыла төште һәм теплоход йөрешен акрынайтты.

Тиздән уң як бортка моторы белән дөпелдәп баркас килеп тагылды. Кемдер алгы палубаны прожектор белән яктырткан иде, аңа шунда ук баркастан кычкырдылар:

— Юк, юк, кирәк түгел, яктыртмагыз, болай да яхшы күрәбез...

— Хәзер үк сүндер!.. Кем ул анда кушмаганны эшләп маташа,— дип югарыдан Әсәдуллин да ачуланды. Аннары ул артельчыны чакыртып меңгезде: — Әсәтернең эреләрен тозлама, холодильникка куй... Корбан балыгын бүгеннән үк трюмда тозга сал, киптерергә булыр... Сорап кара, кипкән воблалары юкмы? Әгәр булса, ике-өч капчык ал... Бар, озак маташма...

Аны бик тиз аңларга күнеккән өлгер артельчы:

— Була ул, Якуб Хисамович, нәкъ шулай итәрмен,— диде дә палубага йөгереп төшеп китте.

Инде башкалар да шунда җыелып өлгергәннәр иде. Караңгыда кешеләр берсен-берсе ашыктыра-ашыктыра, баркастан балык алып кайсы палубага, кайсы трюмдагы тоз өстенә бушата башладылар. Илбарис вахтадан төшкәч, Зәйтүнә дә:

— Әнә балыкчылар килгән бугай, без дә алмыйбызмы? — дип сүз кузгатып караган иде. Илбарис җавап бирмәде; өстәлдәге лампочканы кабызып, кителен салгач кына:

— Һи, исең киткән икән,— дип әйтеп куйды.— Менә иртәгә Саратовта йөзмә магазин чакыртырбыз. Шунда алырсың... Ярар, син йокла, минем иртәгә занятие үткәрәсем бар, бераз әзерләнim әле.

Зәйтүнә барыбер йокыга китә алмады. Чаршау арасыннан күреп ятты; Илбарисның чырае караңгы, нәрсәгәдер бик кәефе киткән иде. Түбәндә тимер палубага шап итеп балык бушаткан тавыш ишетелгән саен кашларын җимереп куя иде ул.

Озакламыйча кайдадыр караңгыда моторлы көймә якынлашып килгәне ишетелә башлады. Аны югарыда вахтада торучылар да күрделәр булса кирәк. Әсәдуллин мостиктан:

— Баркаста... Хәзер үк китегез... Без — сезне, сез — безне күрмәгән,— дип кычкырды һәм, балыкчылар баркасы аерылып калуга, түбәндә машина тагын бар куәтенә эшли башлады, моторлы көймә куып җитә алмыйча артта калды.

## IV

Зәйтүнә иртәгесен күтәренке, шат күңел белән уянды. Каюта эче кояш нурыннан балкып тора, каяндыр күңелле музыка ишетелә. Илбарис инде торып киенгән һәм, стаканнан чәй эчә-эчә, логарифм линейкасы белән нидер исәпләп утыра иде. Зәйтүнә яткан җиреннән генә үрелеп аның муенын кытыкламакчы булган иде, кинәт Әсәдуллинны хәтерләп,

кулын кире алды һәм йоклаган булып чаршау күләгәсендә тын гына ята бирде.

Тышкы яктан кемнендер ишек шакыганы һәм, эчкә башын тыгып, яңгыравык тавыш белән:

— Илбарис Рамазанович, барыбыз да җыелып беттек. Сезне көтәбез, — дип дәшкәне ишетелде.

Илбарис чыгып киткәч, Зәйтүнә тиз генә торып урын-җирен җыеп куйды, юеш чүпрәк белән өстәлне, савыт-саба шкафын, китап киштәләрен сөртеп алды; коридордан Әсәдуллинның кем беләндер сөйләшеп үткәнен ишетеп, үзалдына елмаеп куйды.

Вак-төяк эшләрдән арынганнан соң, ул өске палубага чыкты. Кояш нурына чумган киң елгага, юлда очраган кәрваннарга, текә ярларга карап барды. Кояш катырак кыздыра башлагач, күләгә урын эзләп кызыл почмак каршына килеп чыкты. Наташа да шунда ачык тәрәзәдән эчкә башын тыгып нидер тыңлап тора иде. Зәйтүнә янәшә килеп баскач, ул башын кагып кына исәнләште дә:

— Занятие бара, тынлыйк әле,— дип пышылдап искәртеп куйды.

Зәйтүнә тәрәзәдән эчкә карауга, Илбарис белән Әсәдуллинның икесен берьюлы күреп, уңайсызланып китте. Әмма аңа игътибар итүче булмады. Озынча зур өстәл тирәли тезелешеп утырган егетләр нидәндер дәррәү көлеп җибәрделәр. Шау-шу басыла төшкәч, Илбарис кулындагы акбүр белән кара тактага шакыды.

— Җитте, тынычланыгыз, сүз уңаеннан киңәшеп аласы бер нәрсә бар,— диде ул һәм телевизор өстендәге кәгазьне кулына алды.— Кичә мин үткән рейска отчет ясаганда Жигули буеннан алып кайткан теге баржаның йөген дә өстәп караган идем. Бик кызык хәл килеп чыга икән: баржа белән барганда тизлек гадәттәгедән егерме биш процентка кимесә дә, шул вакыт эчендә йөк ташу планын икеләтә диярлек арттырып үтәгәнбез. Күрәсезме нинди зур отыш?

Арадан берсе балаларча беркатлылык белән:

— Менә бәхет... Прогрессивканы каерабыз икән алайса!.. Шулай бит...— дип куйды.

Берсен-берсе бүлдереп шаулый башладылар:

— Тукта әле, авызыңны ермасана, бу сиңа уен түгел ич...

— Кара син аны, чынлап та шәп бит.

— Тагын шулай итәсе иде...

— Илбарис Рамазанович, үзебезгә бер баржа сорап карасак, барып чыгар иде микән?..

— Нигә чыкмасын!.. Минемчә, бик мөмкин.— Илбарис ишек янагына сөялеп торган Әсәдуллинга карап алды.— Әнә Якуб Хисамович та монда, әйдәгез, бергәләп уйлашыйк, киңәшик. Әгәр сорап карасак, кире какмаслар, сынап карар өчен генә булса да, бер баржа бирерләр иде...

Әсәдуллин өстәл тирәли утыручыларга күз йөртеп чыкканнан соң, бер мәл уйланып торды да:

— Дуслар, безгә әллә ниләр уйлап чыгарган булып дөньяны шаккатыруның кирәге юк,— диде.— Без сабый балалар түгел, төрле юк-барга исебез китмәсен. Безгә баржа йөртүнең кирәге юк, ул эш безгә исәпләнми, чөнки безгә андый күрсәткеч бирелмәгән... Аннары, мин әйтер идем, ул безгә артык комачау гына...

— Ничек инде артык комачау гына? — диде кемдер.

Әсәдуллин, бу сорауны ишетмәгәндәй, сабыр гына сүзен дәвам итте:

— Без монда барыбыз да үз кешеләр, яшерен-батырын түгел дигәндәй, турысын әйтергә мөмкин. Сез үзегез дә яхшы беләсез: хәзерге вакытта безнең «Урал» навигация планын Иделдә беренче булып тәмамлады, ягъни мәсәлән, ярыш флагманы булып бара. Әнә газеталарны карагыз, башка командаларны безгә тиңләшеп эшләргә, уралчылардан үрнәк алырга чакырып язалар. Аллага шөкер дигәндәй, акчасы да әй-

бәт кенә килә бит,— диде ул аннары, тавышын күтәрә төшеп.— Безгә, дуслар, моның кадерен белергә, сак булырга кирәк. Югыйсә, чатаклык килеп чыга калса, үзебезне генә түгел, идарәне дә, парткомны да уңайсыз хәлгә куюыбыз бар... Ә кайбер кайнар башлар шуны аңламыйлар, төрле юк-бар белән безнең башны әйләндерәләр...

Әсәдуллин тагын нидер әйтмәкче иде, кинәт якында гына гудок кычкыртканын ишетеп тәрәзәгә күз салды. Башкалар да тәрәзәләргә каерылып карадылар һәм киң елганы ярып килгән мәһабәт теплоходны күреп хәрәкәтсез калдылар. Сигнал бирешеп сул як бортлары белән аймылышканнан соң, теплоходтан гудок кычкыртып сәламли башладылар. Аннары мостигында торучы ак китель кигән капитан кулына жиз рупор алды да: «Ярыш флагманы — «Уралга» сәлам!» — дип кычкырды. Анар иярен пассажирлары да, команда членнары да уралчыларны күңелле тәбрикләп үттеләр.

Кызыл почмактагылар кул болгап җавап бирделәр һәм, теплоход үтеп киткәч, каефле елмаеп бер-берсенә карашып алдылар.

Әсәдуллин үзенә бер горурлык белән өстәл тирәли күз йөртеп чыкты, кем беләндер бәхәсләшкәндәй, тагын да җанланып сөйләп китте:

— Әнә күрдегезме ничек... Әле кайчан гына «Урал» һичкемгә билгесез бер теплоход иде, йөк ташу планын көч-хәл белән генә үти, аны санга санап телгә алучы да юк иде. Быел уйлап эшли башлагач, әнә кая барып чыктык. Моның кадерен белергә кирәк... Иптәш Рамазанов, сез дә, занятие вакытында, җыен тузга язмаган нәрсәләр белән вакытны әрәм итмәгез.

Бу минутта Зәйтүнәгә Илбарис бик кызганыч булып күренде. Әсәдуллин сүзләреннән соң хәзер барысы да аннан кычкырып көлә башларлар кебек тоелды... Хәер, әйдә көлә бирсеннәр, шул кирәк ул Хыялбайга. Сабак булыр, ичмасам... Әмма гаҗәп, көлүче дә, көләргә уйлаучы да күренми, барысының да йөзләре җитди, күз карашларында ризасызлык күренеп тора иде.

— Аннары, туганкаем, сез, беренче штурман буларак, белергә тиеш, ул баржаны безгә исәпләмәделәр бит аны.— Әсәдуллин, сүзеннән туктап, Илбариска ачулы карап алды.— Чөнки безнең теплоход үзе баржа, дөресрәге, үзйөрешле баржа, шунлыктан аңа баржа йөртү планлаштырылмаган, андый күрсәткеч тә бирелмәгән. Ә теге баржаны без аны очраклы рәвештә, буксир пароход юлда сафтан чыкканлыктан гына алып кайткан идек. План өчен ул безгә бернидә бирмәде, коры мунчала белән юыну гына булды бит ул...

Аның бу сүзләреннән Зәйтүнә ирексез пырхылдап көлеп җибәрде. Ләкин Илбарисның сәерсенеп каравын күргәч, ничектер уңайсызланып калды.

— Хәзер исәпләмәсәләр, киләчәктә исәпләрләр,— диде Илбарис, инде хатынны ягына карамыйча.— Һәрхәлдә, бу — зур резерв, аннан файдаланырга кирәк. Безнеке кебек куәтле теплоходлар барысы да баржалар йөртә башласа, өстәмә рәвештә күпме йөк ташып булыр иде!..

— Һи, һаман бер балык башы булыр икән.— Әсәдуллинның күзләре тагын да түгәрәкләнә төште.— Сез беренче штурман, белергә тиешсез: безнең теплоходның корпусында тиешле ныгытмалары юк, димәк, баржалар этттереп йөртергә җайланмаган. Корпусы ячелүен көт тә тор. Алай тиктомалдан кузгатылган эшнең азагы аянычлы була аның.

— Юк, тиктомалдан түгел. Беренчедән, безнең бәләкәй генә тәҗрибәбез бар: агым уңаена булса да, үткән рейста баржа алып кайттык — хәвеф-хәтәр булмады. Аннары мин кичә базада вакытта бу турыда капитан-наставник Космачевка да, институттан килгән инженерга да сөйләгән идем. Алар бик кызыксындылар һәм тиздән үзләре дә килеп карарга булдылар.

— Әйтәм ич, һаман шул башбаштаклык та мин беләмәнлек... Алдан

ук кисәтеп куям: төрле юк-бар белән маташырга безнең вакытыбыз да, мөмкинлегебез дә юк, без йөк ташырга, план үтәргә тиешбез. Я, әйтегез, шулай түгелмени?

Ләкин Әсәдуллинны хуплап сүз әйтүче булмады. Ул чыгып киткәндә, кешеләр караңгы чырай белән утырып калдылар.

## V

Белдерүләр тактасы янына бер төркем халык җыелган. Үтеп барышлый һәркем шунда туктый да, кысылып булса да алгарак үтеп, белдерүне укырга ашыга. Камбузга чәй алырга барышлый, Зәйтүнә дә кызыксынып туктаган иде, әмма ерып алга үтә алмады.

— Шауламагыз... Әгәр арттагыларга күренмәсә, хәзер үзем кычкырып укыйм,— диде алдагылардан берсе.— Приказ бу, капитан приказы. Тыңлагыз, менә ниләр язылган:

«Теплоход Владимировка пристаненда торган вакытта эчеп һәм сугышып йөргән өчен һәм шуның белән бөтен команда өстенә тап төшергән өчен практикант Әсәдуллин Харисны теплоходтан төшереп калдырырга приказ бирәм. Аның практикада үзен начар тотуы турында укыган техникумына хәбәр итәргә... Шул уңай белән бөтен команданы кисәтеп куям: киләчәктә порт һәм пристаньнарда торган вакытларда һәркем әйбәт йөрергә, алдынгы теплоходның абруен сакларга тиеш.

*«Урал» теплоходы капитаны*
*Я. Әсәдуллин».*

Приказны укучы почык борынлы егет моны башына сыйдыра алмыйча кинәт бик гаҗәпләнеп:

— Ничек, төшереп калдырыргамы? — диде.— Димәк, Харисны, бер туган энесен... Бик тә сәер инде, чынлап әгәр, адәм күрмәгән хәл...

Башкалар да, ни әйтергә белмичә, аптырап калдылар. Арттарак кемдер тыны кысылгандай «уф-ф» итеп тирән сулап куйды. Зәйтүнә борылып караса, якында гына Наташа тора икән. Аның ниткер төсе китеп, еларга җыенгандай юка иреннәре, борын канатлары дерелди иде.

— Юк, дөрес түгел бу,— диде ул әчке өзгәләнү белән.— Милиционер китергәнне барыгыз да күрдегез, исерек түгел иде бит.

— Анысын мин дә раслый алам, Харис бер грамм да эчмәгән иде,— диде боцман Соколов та, сүзгә кушылып.— Без аның белән бергә чыктык. Турысын әйтергә кирәк, мин үзем бер кружка сыра белән аны сыйламакчы да идем. Юк, кермәде бит, чаттагы киоскада китаплар карый калды... Тиз генә эшне бетереп чыксам, ни күзем белән күрим, ХарисКа ике исерек матрос бәйләнеп маташа... «Алдынгылар түгел, алдакчылар сез, взяточниклар»,— дип мыскыл итәләр. Берсе, исерегрәге, йодрыгын ходка җибәрә башлаган иде, Харис аңа берне кундырып алды...— Шул арада милиционер килеп чыкты... Менә шул, теге исерекләр үзләре бәйләнделәр, ә Харис бер грамм да эчмәгән иде... Нинди алдакчы, нинди взяточник?.. Анысын мин белә алмадым, хәзер дә белмим...

Иң артта механик Федор Степанович белән янәшә сүзсез генә Әсәдуллин да күзәтеп тора икән.

— Белмәгәч сөйләмиләр аны,— диде ул, боцманны төрпә генә бүлдереп.— Аек баштан сугышырга шыр тиле түгел бит Харис. Ни сөйләгәненне белеп сөйлә...

Кешеләр, бәхәсләшә-бәхәсләшә, тарала башладылар. Бу хәлне монарчы сүзсез генә күзәтеп торган Федор Степанович, үзалдына сөйләгәндәй:

— Бик сәер килеп чыга әле бу, бик сәер,— дип әйтеп куйды.— Әнә халык та риза түгел... Якуб Хисамович, Харисның үзе белән сөйләштеңме соң?.. Боцман сүзләренә караганда, исерек булмаган бит... Ачыкладыңмы шуны?..

— Болай да ачык мәсьәләне нәрсә ачыклыйсың аны... Аннары моның башка ягы да бар. Ул минем бертуган энем бит. Димәк, йомшаклык күрсәтсәм, туган-тумачалык, юл куючанлык килеп чыга. Башкалардан таләп итүе дә кыен булачак.

— Юк, Якуб Хисамович, ачыкларга, аңлашырга кирәк: гаепleme ул, түгелме? Юкса уңайсыз бит... Мондый очракта җиде кат үлчәргә, тик шуннан соң гына кисәргә кирәк.

Әсәдуллин бүтән берни дә әйтмәде. Иңбашларын гына җыерып алды да гадәтенчә җинел, ышанычлы адымнар белән рубкага менеп китте. Зәйтүнә аның артыннан ирексез сокланып карап калды. «Һәрхәлдә, капитан хаклы булса кирәк, беркемгә дә ташлама ясамый. Чын җитәкче шулай булырга тиештер, күрәсең...» — дип уйлады ул.

Кичкә таба Зәйтүнәне радиорубкага чакыртып алдылар. Барып күрсә, Илбарис белән Әсәдуллин да шунда иде. Кая карама, тәртипсезлек күзгә бәрелеп тора. Өстәл өстен, аппаратларны тузан каплаган, идәндә тәмәке төпчекләре аунап ята. Бер читтәрәк, бөтен гәүдәсен көзән җыергандай әледән-әле уфылдап һәм өзгәләнеп, радист утыра иде.

— Менә безнең радист-электригыбыз авырып китте әле,— диде Әсәдуллин, аңа күрсәтеп.— Бүген кичен Саратовка җиткәч, больницага салырга туры килер үзен... Зәйтүнә сез аның урынына калып торырсыз инде. Бу сезнең кулдан килә торган эш бит.

Башыңа төшкәч, башмакчы буласың диләр. Теләсә-теләмәсә дә, Зәйтүнәгә ризалык бирергә һәм вакытлы рәвештә радист урынында калып торырга туры килде.

## VI

Иртән кызыл почмакта Илбарис белән сүзгә килешкәч, Зәйтүнә Әсәдуллинның хәтере калгандыр дип борчылган иде. Юк, калмаган икән. Көндезге аштан соң Зәйтүнәләр каютасына ул үзе елмаеп килеп керде һәм, берни булмагандай, мәзәкләр сөйләп утырды. Илбарис белән бергә рейс отчетын карап чыкты. Ай азагына хәтле тагын күпме эшләп буласын исәпләделәр. Зәйтүнә аларга урталай киселгән зур гына кып-кызыл карбыз алып керде, икесенең алдына ике тәлинкә куйды.

— И, Зәйтүнә, нинди шәп карбызны кисеп харап иткәнсез,— диде Әсәдуллин.— Монысы бал әчетергә әйбәт булган бит...

— Нинди бал? Ничек әчетергә? — дип аптырап калды Зәйтүнә.

— Шуны да белмисезмени? Бик җиңел эшләнә ул. Савыт та, балшикәр дә кирәк түгел, барысы да карбызның үзендә. Пычак очы белән карбызның кабыгын тишеп эченә чүпрә салсаң, үзе шаулап әчи ул. Ни җитте кызыл аракыларың бер читтә торсын инде... Ләкин мин аны сезгә сер итеп кенә әйтәм, әгәр әчетсәгез, шуның өчен мине бер сыйларга тиеш буласыз.

Шул чак бер төркем яшьләр тышкы якта алар тәрәзәсе турында күләгәгә өстәл һәм урындыклар китереп куйдылар. Кызыл почмактан шахмат тактасы алып чыктылар.

«Урал»да шахматчылар күп, еш кына турнирлар үткәрәләр. Бүген шулар чираттагы уенга әзерләнәләр икән.

Утырышып беткәч шахматчылар әйләнә-тирәгә карана башладылар.

— Харис кайда?

— Лидер ник чыкмаган?

— Моны ничек аңларга?.. Шүрләмәгәндер ич?..

Арада аларга кемдер җавап биргәндәй:

— Менә үзенне теплоходтан куып төшерсеннәр әле, башында шахмат кайгысы булыр идеме? — дип әйтеп куйды.

Чандыр гына гәүдәле булса да, мичкәдән чыккандай яңгыравык тавышлы боцман Соколов ачу белән кычкырды:

— Барыгыз, барыбер китерегез үзен! Судья чакыра дип әйтегез

Аңа карап турнирны ярты юлда калдырып булмый бит. Харисны да әйтер идем, исе киткән икән. Бөтен дөнья бер Әсәдуллинга барып терәлмәгән бит... Һаман саен күз буяп, мин, мин дип борынын чөеп кенә йөри алмас, ул туңбашка да бер авызлык табылыр әле.

Артельче, төнтек чырайлы рулевой Мортазин, башкалар уйнаганны читтән генә карап торган җиреннән:

— Монда капитанның гаебе юк. Харис пристаньда сугышып йөргән икән, капитан аны яклап калырга тиешмени? — диде.

— Әй син, ялагайбай, тик кенә тор,— диде Соколов, кырт кисеп.

— Мортазин чын вояжердан бер дә ким түгел ул,— дип тагын берсе чәнчеп алды.— Капитан күчтәнәчләрен дә диспетчерларга шома гына илтеп тапшыра белә, бер уңайдан үзен дә онытмый: әле икрасын, әле балыгын итәк астыннан гына озатып кесәсен калынайта белә ул.

Монарчы бик кәефле генә сөйләшеп утырган Әсәдуллинның җәенке кашлары җимерелде, күзләрендә зәһәр очкыннар кабынып китте. Шулай да ул ярсуга ирек бирмәде, үзен бик тиз кулга алды һәм, тышта ишетелгән сүзләргә бөтенләй колак салмаган кебек, тыныч кыяфәт белән, карбызын ашый-ашый, сөйли бирде. Илбарис белән Зәйтүнә дә, аны уңайсыз хәлдә калдырмас өчен, алдан сүз куешкан кебек, аеруча игътибар белән тыңлыйлар һәм, урынлы-урынсыз булса да, мөмкин кадәр күбрәк көләргә тырышалар иде.

— Якуб Хисамович,— диде Илбарис, аның тәлинкәсенә кып-кызыл карбыз телеме салып.— Командага эш хакы биреп бетердем, әмма сезнең энекәшегез Харис прогрессивкасын алмады. Кирәк түгел, намусым тартмый диде.

— Ничек?!. Кире кагамени?.. Менә гаҗәп, намусына ни булган аның? — Әсәдуллин авызына китергән карбызын капмыйча көлеп җибәрде.— Ярар, алмаса, ялынмыйбыз... Хәзер кушмаса, соңрак кушар, үзе соратыр әле.

— Якуб Хисамович, тагын бернәрсә. Наташа расчет сорый бит, теплоходтан китәргә җыена икән. Сәбәбен сораштырып та караган идем, берни дә әйтмәде, яшьләнгән күзләрен сөртә-сөртә чыгып китте.

Әсәдуллинның тагын кашлары җимерелде.

— Зыян юк, теләми икән, китә бирсен,— диде ул, кулындагы карбызын тәлинкәгә кире куеп.— Безнең монда балалар бакчасы түгел, барысын да иркәләп кенә торып булмый... Китә калса, кадрлар бүлегенә хәбәр итәргә кирәк, бүтән кеше җибәрсеннәр...

## VII

Радиорубкада бик эссе һәм бөркү. Көндезен кояш җылыткан стеналардан эссе бәреп тора. Өстәл почмагында зырылдап әйләнгән вентилятор да бернинди җинеллек бирми.

Тиздән «Урал» идарә белән сөйләшергә тиеш. Шунарчы Зәйтүнә аппаратларны көйләп утыра. Кулы эштә, ә күңелендә Әсәдуллин. Менә-менә үзе килеп керергә тиеш. Ул гел шулай итә: Зәйтүнәнең рубкада икәнен белдеме, юк эшен бар итеп кереп чыга. Хәер, Зәйтүнә үзе дә аны күрергә ашкынып тора һәм очрашу минутларын түземсезлек белән көтеп ала иде.

Әнә Әсәдуллин кереп тә житте һәм яктыдан кысыла төшкән күзләре белән бер мәл әйләнә-тирәгә елмаеп карап торды.

— Син бу чүп оясын кайчан чистартып өлгердең әле?..— диде ул һәм приемник көйләп утырган Зәйтүнәнең чәчләреннән сыйпап алды, нелеп маңгаеннан үпмәкче иде, тегесе бармак янап, башын читкә алды.

Әсәдуллин урындык алып янәшә утыргач, Зәйтүнә көтмәгәндә капитанның күзләрендә комсыз ашкыну күреп, ихтыярсыз сагаеп калды, аңа кинәт куркыныч булып китте.

Нәрсәдән икәнлеген ачык итеп белмәсә дә, Әсәдуллин бу үзгәрешне шундук сизде, бүтән кагылмады. Хәтта читкәрәк тайпылып, авыз эченнән нидер көйли-көйли, куен дәфтәрендә актарынгандай итте. Шул арада идарәдән тапшыру башланды, инде бераз тынычланган Зәйтүнә һава торышы, фарватердагы үзгәрешләр турында мәгълүматларны гадәтенчә бик тиз язып алды.

Ин соңыннан, ике яктан да тапшырулар тәмам булгач, эфирдагы башка авазларны җиңеп, ныклы калын тавышлы ир кеше дәште:

— «Урал!» «Урал»мы бу?.. Якуб Хисамович, хәерле кич!

Әсәдуллин аны беренче сүзләреннән үк таныды һәм трубканы тиз генә үз кулына алды:

— Тынлыйм, иптәш начальник... Исәнмесез, Николай Николаевич.— дип түбәнчелек белән җавап бирде ул.— Эшләрне әйтәсезме?.. Әйбәт кенә тәгәри... Бу рейста да хәзергә графиктан алда барабыз... Кешеләрме?.. Әйе, алар да әйбәт кенә... Барысының да күңелләре күтәренке, бүген прогрессивка бирдек. Кыскасы, барысы да тырышып эшли, ышанычыгызны, ә-әл-бәттә, аклырбыз.

Зәйтүнә аңа беренче мәртәбә күргәндәй гаҗәпләнеп карап торды. Монарчы һәрвакыт һавалы һәм горур күреп гадәтләнгән, команда членнары алдында үзен эре тотып кына йөргән Әсәдуллин бу минутта кинәт юашланып калды, гаепле кешедәй, ничектер түбәнчелек белән һәм әйтер сүзен таба алмыйча, еш кына тотлыга-тотлыга сөйли иде.

Бер мәл дәшми торганнан соң, репродуктордан шул ук ныклы тавыш:

— Анысы әйбәт, кешеләр турында һаман кайгыртырга, игътибарлы булырга кирәк. Шулай эшләп яхшы итәсез,— дип мактап алды.— Тагын менә нәрсә, син баржа йөртеп карарга җыенасың икән. Без монда иптәшләр белән уйлашып-киңәшеп алган идек. Ниятегез кызыклы гына күренә. Сынап карарга рөхсәт бирәбез һәм уңышлар телибез. Диспетчерларга әйтелде, үзенә юлда баржа әзерләп куярлар...

— Иптәш начальник, аңламадым, нинди баржа, кем ж-җыена?.. Теге ни, болай команда арасында сөйләнү генә бит әле ул... Кысыр хыял гына...

— Сез нәрсә? — диде начальник ризасызлык белән.— Андый ният кысыр булырга тиеш түгел. Без моңа зур өмет баглыйбыз. Мондый эштә кирелә-киттеле ярамый. Сынап карарга кирәк.

— Иптәш н-начальник, мин болай гына әйтәм, принципта каршы түгелмен... Кушасыз икән, тырышып карарбыз...

— Әлбәттә, тырышырга һәм булдырырга кирәк... Югыйсә, тапкансың сүз: кысыр хыял да, коры сөйләшү генә, имеш. Бер кузгалгансыз икән, эшләргә кирәк. Менә шул, уңыш теләп калабыз, хушыгыз...

Рубка эче тынып калды. Әсәдуллин үзен әле һаман начальник каршында хис иткәндәй, репродукторга озак кына ихтирам белән карап торгач, маңгаендагы тир бөрчекләрен кульяулыгы белән сөртеп алды.

## VIII

«Урал» киң елганы ярып һаман алга бара. Як-якта тәбәнәк ярлар, яшел болыннар, су буена ук сыенып утырган хуторлар күренеп кала. Төрле пароходлар, кәрваннар, балыкчы сейнерлары очрый.

Волгоград ГЭСы шлюзларын үткәч, кинәт диңгезгә килеп чыккан кебек булып китте. Кая карама, чиксез-кырыйсыз су чайкала.

Саратовка житәрәк Увек пристане турында «Урал»ны кечерәк кенә баркас каршылады. Өске палубасында елгачылар формасы кигән, кулына кара плащ һәм кечкенә чемодан тоткан өлкән яшьләрдәге бер кеше басып тора иде. Танып алу белән, Әсәдуллин аны үзе каршылады, үзе белән янәшә буш каютага алып керде.

Бу — Иделдә туып үскән, бөтен гомерен пароходларда эшләп үткәргән карт елгачы, капитан-наставник Космачев иде. Каютасында әйберләрен куйгач, ул шунда ук рубкага күтәрелде, команданың эше, тормышы турында сорашты. Аннары кителенең куен кесәсеннән кәгазь чыгарып:

— Мин башка теплоходларда йөргән арада сез монда кызыклы гына фикер күтәреп чыккансыз икән,— диде.— Идарә каршы түгел. Ярдәмгә-кинәшкә дип мине җибәрделәр. Миңа диспетчердан приказ: Саратов рейдыннан бодай төягән баржаны алырбыз...

Әсәдуллинның чырае караңгыланып китте.

— Иван Кириллович, минем үземнең моңа никтер бер дә кулым тартмый,— диде ул. Илбариска таба ачулы караш ташлап.— Әнә кем хыялы ул, бөтен команданың башын шул әйләндерә, бөтен халыкны миңа каршы куйды...

Космачев, нәрсәнедер ачыкларга теләгәндәй, башта Әсәдуллинга, аннары Рамазановка бер мәл сүзсез генә карап торды, чаларган кыска мыегын сикертеп алды. Әмма телдән аны-моны сиздермәде.

— Ярар, бу хакта соңыннан... Һәрхәлдә, буш хыялга охшамаган бу. Әнә Саратовка якынлашып та киләбез инде. Бу баржаларның кайсысы безнеке икән? — Ул, бинокль алып, рейдтагы судноларны карый башлады.

Тиздән алар бодай төягән зур баржа янына килеп туктадылар. Баржаның шкиперы, базык гәүдәле, тәбәнәк буйлы егет, башта ышанмый торды.

— Үзйөрешле баржа белән баржа йөртәләрмени? — дип бик гаҗәпләнде.

Әмма аңлатып биргәч, шунда ук риза булды һәм бөтен командасы белән эшкә кереште.

Баржаны эттереп барырга булдылар. «Урал» борыны белән арттан баржаның кринолинына терәлде. Ике яктан һәм аркылы-торкылыга корыч арканнар белән тарттырып бәйләделәр.

Якорьларны күтәрткәч, ашыкмыйча гына юлга чыктылар. Тиздән рейд артта калды. Яңа күпер астыннан үткәч кенә бер күңелсезлек була язып калды. Югарыдан төшеп килүче «Авангард» теплоходының биек дулкынынннан кәрван чайкала башлауга, сул яктан корыч «дилбегә» шартлап өзелде. Баржа, туры барышын югалтып, кинәт уңга борыла башлады һәм тиздән агымга аркылы ятты.

Бер мәлгә барысы да аптырап калдылар. Бик тиз генә нинди дә булса чара күрелмәсә, авария яки башка бер күңелсез хәл килеп чыгачагы ачык иде.

Авыр тынлыкны башлап бозучы Әсәдуллин булды.

— Ах, харап иттеләр,— дип каударланып кычкырып җибәрде ул.— Баржаны да, теплоходны да харап иттеләр. Иван Кириллович, сез булмасагыз, мин моңар юл куячак түгел идем... Инде хәзер теләсәгез нишләгез, җавабын үзегез бирегез, мине бутамагыз... Минем монда бернинди катнашым да юк...

Иван Кириллович белән тиз генә киңәшеп алгач, Илбарис баржаның алгы ике якорен да салырга, теплоходтан сузылган корыч арканнарны ычкындырырга команда бирде. Бөтен командага авыр минутлар кичерергә туры килде. Тик баржа якорьга туктагач кына кешеләр җиңел сулап куйдылар.

Сул як «дилбегә»гә искереп тузган аркан куелган икән, баржаны дулкын чайкаган вакытта шул өзелгән. Яңа корыч аркан белән тарттырып бәйләгәч, кәрван тагын кузгалып китте. Очраган теплоходлар дулкын кузгатып үтсәләр дә, инде кәрван бернинди хәвеф-хәтәрсез алга бара бирде.

— Болай булгач, борчылмаска да мөмкин,— диде Иван Кирилло-

вич, авыр тынлыкны бозып.— Әйбәт барабыз, яхшы бәйләгәч, тоташ бер судно кебек. Күз тимәсен, рульгә дә әйбәт буйсына...

Түбәндә команда членнары да җанланып киттеләр.

— Күрәсеңме, бара бит, ыжгырып бара...

— Миңа тамаша, үзйөрешле баржа белән дә баржа йөртеп булыр икән.

— Чынлап та шәп кенә бара бит... Гаҗәп тә инде.

— Бер карaганда монда хәйран калырлык әллә нәрсә юк,— диде Соколов, сүзгә кушылып.— Хәзер үзйөрешле баржаларны әнә нинди куәтле итеп төзиләр, күрәсез, аңарга үзе хәтле судноны йөртү дә әллә ни кыен түгел...

Тагын байтак вакыт шулай әйбәт кенә баргач, Иван Кириллович белән Илбарис капитанга хәерле вахта теләп, түбән төшеп киттеләр һәм палубада әле һаман таралышмыйча үзара җанланып сөйләшеп торган яшьләр янында туктадылар.

— Иван Кириллович, шәп бара бит! — диде боцман Соколов, баржага күрсәтеп.— Югыйсә, безнең монда булмас, барып чыкмас дип каркылдап колакларыбызны тондырып бетергәннәр иде.

— Әйбәт барабыз, дуслар, бик әйбәт, бер дә зарланырлык түгел.— Иван Кириллович фуражкасын салды, эсседән тирләгән маңгаен, битләрен кулъяулыгы белән сөртеп алды.— Әгәр без алып китмәгән булсак, баржа буксир пароход көтеп күпме торган булыр иде әле... Башка үзйөрешле баржалар да шулай эшли башласалар, нинди зур экономия ясалачак!.. Бик зур эффект бирәчәк бу...

## IX

Зәйтүнә каютада кечке ашка табын әзерләп йөри иде. Тышкы яктан кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшкәне ишетелде һәм яртылай ачык ишектән Илбарис, аның артыннан исәнләшеп Иван Кириллович белән механик Федор Степанович килеп керде.

— Зәйтүнә, син безне чәй белән сыйла әле, бу челләдән тәмам сусап беттек,— диде Илбарис.— Әнә Иван Кириллович әйтә: чын татарча каты чәй эчәсем килә ди... Әйдә, осталыгыңны күрсәт әле...

Иван Кириллович киштәдәге китапларга игътибар белән күз йөртеп чыкты, кайберләрен кулына алып актарып та карады:

— Дөрес, лоциясе дә, навигациясе дә, компасы, локаторы да кирәк,— диде ул.— Хәзер елгачының бөтен эше техника ярдәмендә үтәлгән чорда, китапсыз мөмкин түгел... Әле кайчан гына бер якорьны бөтен команда җыелышып мең газап белән күтәрә идек, хәзер бер матрос брашпильның кнопкасына гына баса...

Алар, кулларын юып сөйләшә-сөйләшә табын янына утырышкан арада, Зәйтүнә өстәлгә җиләк-җимешен китереп куйды, камбуздан кыздырылган балык алып керде, чынаякларга чәй салды. Федор Степанович белән карашып алганнан соң, Илбарис шкаф артыннан шешә тартып чыгарып, балык алдыннан берәр рюмка салып бирмәкче дә булган иде, әмма Иван Кириллович:

— Мондый кызуда һич тә кирәге юк... Аннары вакыты да түгел,— дип каршы килде һәм ул, балыкны мактый-мактый бер мәл ашаганнан соң, сорау бирде: — Дуслар, миңа бер хәл бик сәер тоелды: Әсәдуллинны ник команда яратмый? Сәбәбе нәрсәдә?.. Үзе болай сәләтсез капитан түгел бит ул...

Барысы да ашаудан туктап көрсенеп куйдылар. Бу сорау Зәйтүнәне аерууча чәнчеп алды. Мондый хәлне ул инде үзе дә ничектер сизгән һәм ялгышамдыр, миңа гына шулай тоеладыр дип уйлап, үзен тынычландырырга тырышкан иде.

— Әйе, Әсәдуллин булдыксыз капитан түгел,— диде Федор Степа-

нович, күнелсез тынлыкны бозып.— Елга транспортын белеп, яратып эшли. Ләкин аның зур бер житешсезлеге: үз кул астында эшләүчеләрне кирәксә-кирәкмәсә дә рәнжетә торган гадәте бар. Команда членнары белән борының чөеп кенә сөйләшә, әз генә аныңча булмаса, беркемгә дә колак салмый. Хаклымы, түгелме, фәкать ул кушканча гына булсын... Шуңа күрә бездә кешеләр яратып эшләмиләр, җае чыкса, башка суднога күчеп китәргә генә торалар. Ә кайберәүләрне ул үзе китәргә мәҗбүр итә...

— Кара син аны, шулаймыни? — Иван Кириллович, теше сызлый башлагандай, кинәт чыраен сытып куйды.— Ә мин, картлач, шуны күрми йөргәнмен. Алдынгы теплоход булгач, андый нәрсә башыма да китмәгән минем...

Һич тә көтмәгәндә, Әсәдуллин ишектә үзе күренде һәм гадәтенчә кыю кыяфәт белән бусага аша атлап кергән шәпкә:

— Ә, сез мондамыни... Тәмле булсын ашыгыз,— диде һәм, кыстаганны да көтмәстән, өстәл янына килеп утырды.— Илбарис, син нәрсә, Иван Кириллович хөрмәтенә рәтлерәк балык китертмәдең. Анда әсәтр бар иде бит...

— И, бөтенләй оныта язганмын, үзең балык дигәннән искә төште... Менә монда Рыбнадзордан сиңа хат бар әле,— дип, Иван Кириллович стенага эленгән китель кесәсеннән кечерәк кенә конверт алып бирде.— Ни язганнардыр, белә алмадым, барказка утырганда гына китереп тоттырдылар. Озакка сузмасын, җавап язып җибәрсен дип әйтеп калдылар.

Конвертны ачып укый башлауга, Әсәдуллинның кашлары җыерылып килде. Зәйтүнә аның кулындагы кәгазь калтырый башлаганын күрде. Моны Иван Кириллович та сизде, ахрысы.

— Ни булган, күнелсез хәбәрмени?..— диде ул, Әсәдуллин кулындагы кәгазьгә күз салып.— Акт! Рыбнадзор акт язганмыни?.. Сез төннәрен браконьерлардан күпләп-күпләп балык аласызмыни?.. Дөресме шул?.. Аннары нигә сезгә шул хәтле балык, кая куясыз аны?..

— Иван Кириллович, алар башка судно белән бутаганнар булса кирәк... Рыбнадзор безне тотмаган, димәк, берничек тә исбат итә алмый...

— Ярар, анысы шулайдыр, бәлкем... Ләкин әнә алар бу хәл инде беренче тапкыр гына түгел, эшне прокуратурага тапшырабыз дип язганнар бит...— Иван Кириллович күзлеген киеп актны яңадан укырга тотынды.— Антиповка турыннан сәгать ничәләрдә үттегез әле сез?.. Төнге сәгать уникедәме? Шул, шул, сезгә туры килә бит...

Әсәдуллин ачык итеп ни дә булса әйтә алмады, иңбашларын гына җыерып куйды.

— Тагын менә нәрсә, дуслар,— диде Иван Кириллович.— Сез практикант Әсәдуллинны теплоходтан төшереп калдырырга булдыгызмыни? Монысы ни өчен, яхшылап ачыкладыгызмы? Бик кинәт каерып ташламыйсызмы?..

— Юк, ялгышмыйбыз, Иван Кириллович... Харис минем бертуган энекәшем ул, мин аны яхшы беләм һәм бик хаклы рәвештә төшереп калдырам... Бүтәннәргә гыйбрәт булыр...

— Тукта әле, Якуб Хисамович, тукта... Син ничектер сәеррәк сөйләшәсең. Һаман мин дә мин... Алай гына булмый бит ул. Теплоходта коллектив та бар бит әле... Ә коллектив практикант Әсәдуллин өчен бик борчыла. Ул аны һич тә хаксызга рәнжетелде дип саный... Халык белән сөйләшкәндә мин шуны сиздем.

— Мин теплоходта кешеләрдән дисциплина таләп итәм, эш таләп итәм. Шуннан ризасызлык күрсәтүчеләр дә булуы мөмкин... Ә Харис пристаньда исереп, әллә кемнәр белән сугышып, коллективка тап төшергән икән, үз туганым булса да, күз йомып кала алмыйм... Башкаларга гыйбрәт булыр...

— Якуб Хисамович, турысын әйткән өчен хәтерең калмасын, мин сина бер вакыйганы исенә төшерергә телим,— диде Илбарис.— «Рошаль» пароходында практикада йөргән вакытта хәтерлисеңдер, син бер дә сәбәпсезгә Астраханьда калган иден. Өч көннән соң гына безне юлда куып җиттең. Синең өчен без өч көн вахтада тордык... Шундыйрак хәлләр аннан соң да булгалады бит. Әмма сине куып төшермәделәр, хатаңны аңлатырга тырыштылар... Безгә дә шулай эшләсәк, бер дә гөнаһ булмас иде.

Монарчы тыныч кына сөйләшкән Иван Кириллович сабырлыгын җуя башлады. Илбарис белән Федор Степановичка сораулы караш ташлады:

— Алайса менә нәрсә, практикант Әсәдуллинның үзен чакыртыйк әле без... Кыек-мыек сөйләргә урын калмасын...

Тиздән Харис Әсәдуллин кереп житте һәм, коры гына исәнләшеп, ишек янында тукталды. Өстендә зәңгәр якалы, ачык изүле ак күлмәк. Кара куе чәчләре артка яткырып таралган. Соргылт күзләренең карашы җитди иде.

— Харис, син комсомолец башың белән ни эшләп эчеп исереп йөрисең? — диде Иван Кириллович, бераз дәшми торганнан соң.

— Юк, мин эчмәдем, мин исерек түгел идем... Дөрес түгел, ялган сөйлиләр.

— Менә сиңа мә! — Капитан Әсәдуллин көчәнүле елмаю белән кулларын җәеп җибәрде.— Аек кешене милиционер озата киләмени... Рәхмәт әйт, ярый әле ябып куймаганнар...

— Алайса ник сугыштың соң? Бала түгел бит син. Шулай ярыймыни?

— Ярамаганын хәзер үзем дә аңлыйм,— диде Харис, уңайсызланып.— Кисәк кенә кызып китеп, тыела алмый калдым. Барысы да шул балыктан килеп чыкты...

— Нинди балык ул? Балыкның монда ни катнашы бар?.. Син белеп такылда!..

Харис ничек дип җавап бирергә белмичә аптырап калды, әйтер сүзе авызында тереләп калгандай, тамак кырып куйды.

— Мин түгел, теге исерек матрослар такылдаган балык,— диде ул, әбыйсына кыю карап.— Шуларның берсе бөтен халык алдында миңа бәйләнә башлады: бу юлы да әсәтер күп алдыгызмы, икрасы да, вобласы да җитәрлекме, ди. Ә икенчесе: «Урал»ның капитаны белә ул, диспетчерга балыкның иң шәбен генә ташып тора, ди. Шуның өчен аларга кире кайтканда да йөге табылып тора, причалларда да чиратсыз төяниләр, чиратсыз бушаталар, ди... Их сез, күз буяучы алдынгылар дип, бөтен халык алдында миннән көлә, төрткәли башлады... Һәм мин түзмәдем, ачудан кызып, үзенә бәреп җибәрдем...

Харис чыгып киткәч, өстәл янындагылар бер-берсенә туры карарга уңайсызланып, барысы да сүзсез калдылар.

## X

«Урал» Казанга иртән килеп житте. Алып килгән баржаны элеваторга куйдылар. «Урал»ның үз йөген куәтле краннар белән тоз причалында бушата башладылар.

Иван Кириллович белән Әсәдуллин рейсның уңышлы тәмамлануы турында селектордан идарәгә хәбәр итәргә киттеләр.

Теплоход монда бер тәүлек торачак иде. Вахтадан буш халык шәһәргә чыгып китте. Илбарисның, шәһәргә чыгу түгел, иркенләп утырып тамагына ашарга да вакыты юк иде. Зәйтүнә башкалар белән бергә чыкты.

Берничә көн рәттән су өстендә килгәннән соң, коры җир ничектер сагындырган икән. Алар кибетләрдә булдылар, музейга кереп чыкты-

лар. Үзәк стадионда футбол карадылар. Кич белән арып-талып кайтып керсәләр, боцман Соколов аларны көтелмәгән хәбәр белән:

— Егетләр, Әсәдуллинны бездән алалар,— дип шаккатырды.

— Кемне?.. Әсәдуллинныммы?..

— Нәрсә такылдыйсың?.. Булмаганны!

— Нигә булмасын... Теплоходны бая ук тапшырып бетерде. Әнә әйберләрен җыештыра инде... Зурлап озатып калырга әзерлән...

Зәйтүнә моңа ышанырга да, ышанмаска да белмичә аптырап калды. Ә башкалар бу хәбәрне барысы да җиңеллек белән каршыладылар. Арадан берсе:

— Бик шәп иткәннәр, ул тутый кошка күптән шул кирәк иде,— дип хәтта шатланып та куйды.— Әйдә китә бирсен, ак юл телибез үзенә... Анысы да монысы, яңа капитан килдеме соң? Нинди кеше?

— Килде, килде, инде эшләрен дә кабул итеп бетерде... Кем икәнен белергә телисезме?.. Әнә ул үзе,— дип машина бүлегеннән менеп килгән Илбариска күрсәтте.

Барысы да елмаеп куйдылар. Ә Зәйтүнәгә тагын гаҗәпләнергә туры килде. Хыялбай дип көлеп кенә йөрелгән мыштым Илбарисны бөтен команданың шулай якын итүен һәм аның капитан булып калуына шатлануларын ничектер башына сыйдыра алмый иде ул.

Тиздән Әсәдуллин чемоданнарын күтәреп палубага чыкты. Илбарис аңа вокзалга әйберләрен илтешергә ике кеше бирде. Иван Кириллович белән бергә үзе дә аны причал капкасына кадәр озата чыкты һәм хәерле юл теләп саубуллашты. Ә команда члennарыннан озатучы бүтән беркем дә булмады. Бары тик Зәйтүнә генә аның китүен кызгану катыш әрнү белән каюта тәрәзәсеннән пәрдә аша карап калды.

Берничә минуттан Илбарис белән Иван Кириллович кайтып керделәр. Кызыл почмак ишеге төбендә тәмәке көйрәтеп утырган Федор Степановичны да дәшеп алдылар. Бөтен команда кебек, аларның өчесенең дә күңелләре күтәренке, йөзләре якты иде.

— Ну, Илбарис Рамазанович, капитан булуың белән котлыйм һәм уңышлар телим! — диде Иван Кириллович, беравык елмаеп карап торганнан соң.— Тырышып эшлә, һәрвакыт кешелекле бул. Хәзер, безнең көннәрдә бу бигрәк тә әһәмиятле. Әгәр бик борыныңны чөя, юкка да, барга да акырына башласаң, кешеләрне биздерәсеңне көт тә тор. Әнә Әсәдуллинны үзең күрдең. Югыйсә, болай үзе тырыш та, эшне дә яхшы белә иде бит.

— Анысы шулай, ул яктан тел тидерерлек түгел,— диде Илбарис.— Хәзер аны кая алдылар соң?.. Гомумән бу ничек болай килеп чыкты әле?

— Башкача мөмкин түгел, бөтен коллективны таркатырга ярамый бит. Идарәгә һәм парткомга барысын да яшермичә сөйләп бирергә туры килде. Билгеле, бераз миңа да эләкте, әлек кая карап йөрдең диләр... Хәер, аны да төртеп екмадылар... Заводтан яңа теплоход чыгып килә икән, шуны кабул итәргә җибәрделәр... Идарәдә аның белән сөйләшерләр әле... Сабак булыр үзенә...

— Әгәр булмаса, тормыш үзе өйрәтә ул... Шулай бит, Зәйтүнә? — диде Илбарис, көтмәгәндә күзләре белән генә хәйләкәр елмаеп.— Ярар, ул хакта җиткән. Үз эшебез дә муеннан. Хәзер безгә кәрванга нинди сигнал куярга? Нинди чалкалар кулланырга, аларны ничек тарттырып бәйләргә?.. Иван Кириллович монда чагында болар турында бергәләп киңәшергә, хәл итәргә кирәк...

Зәйтүнә, ни әйтергә дә белмичә, аңа аптырап карап тора. Илбарис гомергә шулай Хыялбай булып калган һәм җилбәзәк хатынының күңелендә ниләр барын белергә дә теләми, күрәсең... Әллә, киресенчә, Зәйтүнә үзе ялгыша, үзе аны аңламый инде... Ничек тә әнә шуны беләсе иде...

*1966, Казан.*

*Равил Фәйзуллин*

## Карт һәм шагыйрь

ШАГЫЙРЬ

Дөнья буйлап килəм.
Байлыгым, тәҗрибәм юк,
рыям, мәкрем, хәйләм юк,
тик гаҗәпләнә беләм!
Гаҗәпләнеп нәфрәтләнәм,
гаҗәпләнеп сөенәм!
Миңа өр-яңа җиһан бу!
Төсләр, әйбер төрлелеге
күзләрне камаштыргач,
кеше күңеле хәлләренә
ис китеп карап торгач,
күңелдә, кош баласыдай,
очар сүзләрне тоеп,
җаннары теләгән якка
аларга ирек куеп,
очырам да, вөҗүдемдә
иң бөек ләззәт тоеп,
көләм, я елыйм сулгып...

КАРТ

Көлү-көлү, елау-елау,
елан да елый диләр.
Мәгънәсез елаган — мескен,
мәгънәсез көлгән — юләр!
Максатсыз черки да очмый, —
син сүзләр очырасың.
Я бәхетең ташый синең,
я сызып ачынасың.
Хикмәте ни?

ШАГЫЙРЬ

Чолгамыйча туры әйтәм:
бәхетем ташкан түгел.
Хәтта андый бәхет миңа
кирәк тә түгел бүген!
Иртәгә калсын...
Ә бүген?
Бүген көрәшәбез әле!
Җирнең пакьлеге өчен,
илнең аклыгы өчен!
Киткән зиһен, киткән көчнең

кайткан чагылышы итеп
күрәсе килә матурны,
күрәсе килә акны,
чумрасы килә шатлыкны
күзләргә сыйган чаклы.
Күрәсе килә кешене,
хыялдагы кебекне,
җирне күркәмлисе килә,
очырасы килә чүпне,
хәвефсез һәм чиста итеп
саклыйсы килә күкне,
һаваны сулап туймаслык,
гел саф итәсе килә,
шартлылыкларны бетереп,
чын иреклелек тоеп,
җирне үзеңнеке итеп,
бәйрәм итәсе килә!
Тормышны күбрәк ямьләп,
яшәп китәсе килә!

## КАРТ

Кем теләми саф һаваны?
Кем теләми пакь җирне?
Шагыйрем, хисеңне тый да
чак кына тыңла мине!
Җир үзе ничә катлыдыр,
әмма тормыш — катлырак.
Берзаман сабый акылың
калыр әле аптырап.
Шавың кимер, кыйблаң авар,
дөнья үзен төшендергәч.
Аллалар да котсыз кала,
асылына ук чишендергәч!
Белеп тор, бу җир бик иске,
мәхәббәтләре иске,
бар гадәтләре иске —
бик күп нәрсә бүлгәләнгән:
«безнеке һәм сезнеке».
Кем гайрәтле — шул югары,
кем өлгер — юл яра алдан.
Бар да омтыла. Берәү дә
чүбектән яралмаган!
Кояшны әле керфеккә,
әле тезләргә төшерү
бәлки кыендыр...
тик авыррак
икмәкне таңре-җирдән
иренгәчә менгерү!
Азап хәләл хезмәт белән
бакча-сарайлар төзү,
матди тереклек итүне
заманынча җиткерү!
Син әйтәсең — көрәш дисең,
ә соң нәрсә ул көрәш?
Тәнең өчен, җаның өчен,
дөнья куу — шул көрәш!

### ШАГЫЙРЬ

Миңа кирәкми сарайлар,
мәрҗән, энҗе, асыллар.
Рухым ирешкән хакыйкать
гали, өстен барсыннан!
Булса ирек, булса җирлек,
ипи-тоз, хет аз гына,
язармын, бер дә басмамын
талантым бугазына!
Көрәшем менә шул минем!

### КАРТ

Рухың нык булу һәйбәт ул,
иҗтиһат итү яхшы.
Хәтереңә хилаф килмәс,
шуны да онытмачы:
Хезмәтләне олыласак та,
әле дә кадерсезләр бар.
Ми кипкәнче хезмәт итеп,
исеме кадерсезләр бар.
Җирдә бакча, сарай төзеп
мәдәният калдырып та,
оныклары яд итәрлек
урыны юк барырлык та...
Кызулык ул, малайлык ул —
камыр кыңгырау кагу.
Кыңгыраулмасаң да тормыш
ай-яй-яй гына ару!
Кирәк-кирәкмәскә көю,
ачыну һәм лаф ору
нигә кирәк? Үзе сәнгать —
эндәшмичә шым тору!
Мәҗнүн, бәлки мәңгелектер,
кеше гомере бер саплам.
Кеше ни әлек — тән иясе,
яман күзләрдән саклан!

### ШАГЫЙРЬ

Саклан, дисең. Соң нәрсәдән?
Үземнең хаклыгымнанмы?
Күп күргән күзләремнәнме?
Намусым аклыгыннанмы?
Әллә халкым моң-хәсрәтен
тыңлап көенүдәнме?
Илнең якты йөзен күреп
нарасый сөенүдәнме?
Саклан дисең... ә соң нидән??
Беләм: кечкенәлегемне дә,
Җирнең зур икәнен дә,
тормыш — кунактан кайткач мин —
күзәнәк җир тәнендә...
Беләм: һәммә нәрсә үлә,
кабердәр генә үлми.

Тираннар, патшалар үлә,
шагыйрьләр генә үлми!
Әгәр җирдә алдан ук мин
бәямне белеп торсам,
мәгънәсезлек дулкынында
буш гомер сөрер булсам
китәм...
гадәтләрен ташлап китәм,
мәхәббәтен, икмәген...
Әгәр Кояш күпсенмәсә,
чын кешеләр читкә итмәсә
тормыштан тиз китмәмен!
Чөнки эшлисе эшем бар,
исбатлыйсы сүзем бар.
Бераүнен сөясе килгән
матди тәнем — үзем бар!

## КАРТ

Егет! Бераз сабыйрак син:
күзләрең, сүзләрең дә.
Тарих — ерак, хаклык — тирән
яшәеш үзәнендә.
Еллар, чорлар катлаулы ул,
тарих үзе сиртмәле.
Бу дөньяда кемнәр булып,
кемнәр генә китмәде.
Әй, ул туры акыл белән
мәйданга килүчеләр!
Мин моны болай эшлим дип,
дәгъвалап йөрүчеләр!
Шул янып йөрүче йөздән
туксан тугыз кимендә
мәңгелеккә «мәйдан» тапты
Билгесезлек Илендә.
Кабер, кабер, кабер, кабер
кабер кая карама.
Кайсысында әрем үсә,
кайсысында карама...
Юк анда һава, җил, яңгыр,
хәрәкәт, бушлык, төс, тәм.
Барыбер, яшен үтсә дә,
буран үтсә дә өстән.
Юк анда, караңгылыктан,
суыктан башка берни.
Ичмасам җир үзәгенең
җылылыгы да менми!
Сулыйсың икән, тормышның
сер-көен өйрән Җирдә.
Табигать бәхеттән җан биргәч,
озак яшәмәскә нигә?

## ШАГЫЙРЬ

Яныйсың да үлем белән,
озын гомер димлисең.
Тик аны ник һәм кем өчен
яшисең соң димисең.

Минем тормыш нәрсә соң ул?
Бар дөнья ал да гөл дип
авыз мыгырдатумы?
Чак саксызлык күргә дә
ачынып җан атумы?
Әллә «җир-суны яндырып
һәм күкләрне ватумы?»
Боекса, бөек халкымның
күңелен юатумы?..
Син әйтәсең — яшә дисең,
озын гомер димлисең,
тик аны ник һәм кем өчен
яшисең соң димисең.
Уйламыйсыңдыр үлемнен
бик үк начар түгелен:
китер, хәзер кабул итәм
Үлемсезлек үлемен!

КАРТ

Гаҗәпләнәм: шагыйрьләргә
иблистә дә булмый торган
көч килә әллә кайдан!
Үлемнән дә чирканмагач,
әйдә, йөр, шамакайлан!

ШАГЫЙРЬ

Әйе, йөрим, гизәм, көләм.
Тир тәмен тойган халыктан
хикмәтле сүзләр сөзәм,
күңелемдә кайнатам да
аларга тылсым өрәм,
мәхәббәттән я нәфрәттән
күңелдә таулар өям,
кара савытымдагы айга
мадхия язып бирәм,
сейфлар да ишетерлек
мәзәкләр сөйлим, көләм...
Дөнья буйлап килә!

1963 ел

—●—

*Сәгыйт Таҗетдинов*

# ҮЛЕМНӘН ЯШӘҮГӘ

## Документаль повесть[1]

Русчадан **В. НУРУЛЛИН** тәрҗемәсе

### Ә көннәр үтә...

Менә 1944 елның феврале дә үтеп бара инде. Мин һаман шулай ачлыктан интегәм, һаман шулай унике сәгать эшләгәннән соң бик арып кайтам, көн саен, сәгать саен кыйналу, кимсетелү, үлем көтеп йөрим.

Әмма шулай да җанга бераз җиңелрәк хәзер, чөнки яшерен радио көн саен Совет Армиясенең яңа җиңүләре турында хәбәрләр алып тора. Ленинград блокададан коткарылган, Новгород янында дошманга бик каты удар ясалган, Буг елгасы тирәсендә азат итү сугышлары бара. 17 февральдә Корсунь-Шевченко районында фашист гаскәрләрен тар-мар итү тәмамланган. Баганадагы фашист радиосы көн саен әле теге, әле бу совет генералының «бөек» Германия ягына чыгуы, немец гаскәрләренең җиңүе турында тамаклары ярылганчы тик кычкыра бирсен шунда. Безгә аннан ни зыян?! Дөреслекне бик яхшы беләбез бит без. Яшерен радиоалгычлар чехларда да, австриялеләрдә дә, немецларда да, полякларда да бар. Дөрес, без алардан һәр көнне түгел, бәлки өч тәүлектән өч тәүлеккә генә мәгълүматлар алабыз. Урынына һәм шартларына күрә монысы да бик әйбәт инде. Әмма күңел дигәнең кош кебек талпынып торганда фронт хәлләрен тагын да ешрак ишетеп-белеп барасы килә! Сергей Пельман группабыздан бер иптәшне эсэсчылар барагына җыештыручы итеп урнаштырырга тәкъдим итте. Анда радиоалгыч бар һәм, «хуҗалар» өйдә юк вакытта, шуның аша Советлар Союзын тотарга мөмкин булыр, диде.

Тиздән кирәкле кешесен дә таптык. Эсэсчылар бүлмәсен Коля исемле яшь кенә бер егет җыештырачак. (Фамилиясен тәки белә алмадым мин аның!) Коля немецча да ярыйсы гына белә, зирәк егет. Сергей аңа әйбәтләп инструкция биреп җибәрде.

— Немецча белүең турында берүк сиздерә күрмә,— диде аңа. — Фашистлар сине бик гомум сүзләрне генә, ипилек-тозлык кына немецча аңлый дип уйласыннар. Ышанычларын яулап алгач, бүлмәләрендә үзең генә калган вакытларда, радиоларын кабызып, Мәскәүне тотарга тырышырсың. Әмма бик сак бул, Коля, бик-бик сак бул, энекәем!..

---

[1] Ахыры Башы 10, 11 саннарда.

Николай без көткәннән дә унганрак булып чыкты. Җыештыручы булып эшли башлавына атна-ун көн үттеме икән, ул инде өч тапкыр соңгы хәбәрләрне тыңлап кайтырга да өлгерде. Ләкин безне хәзер бу да канәгатьләндереп бетерә алмый, чөнки Коля системалы рәвештә тыңлый алмый — мөмкинлек юк. Ә соңгы көннәрдә фронтта хәлләр бик тиз үзгәреп тора, аларны һәр көн тыңлап-белеп барасы килә. Юк, болай булмый. Үзебезгә яшерен радиоалгыч булдырырга кирәк!..

Александр Семенович Календарев яши торган камерада кечкенә аштан соң бик күп яшь тоткыннар җыела. Александр Семенович ул егетләргә математикадан һәм инглиз теленнән дәресләр бирә. Ваня Киреев, Вася Шахов, Ваня Гребенюк, Боря Балаевлар — аеруча тырыш егетләр. Каяндыр карандаш кисәкләре юнәткәннәр, цементтан бушаган кәгазь капчыклардан дәфтәр ясаганнар һәм шундый тырышып укыйлар алар, ихтимал, нормаль шартларда, тыныч вакытта да алай ук тырышканнары булмагандыр. Бу уку аларга ике яклап файдалы. Беренчедән, белемнәре арта, икенчедән, Александр Семенович биргән геометрик, алгебраик һәм тригонометрик мәсьәләләр белән мавыгып, алар ачлыкны да, туганнарын сагынуларын да һәм минут саен үзләрен көтеп торган кимсетү-хурлыкларны, үлемне дә онытып торалар...

Лагерьда шигырь язучы яшьләр дә байтак. Анатолий Неживой, Леня Вуколов һәм башкалар матур-матур шигырьләр язгалыйлар. Аларга өлкән шагыйрь Иосиф Павлович Маседкин киңәшләр биреп, шигырьләрендәге йомшак урыннарны күрсәтеп, ярдәм итеп тора. Шунлыктан яшьләр аны бик хөрмәт итәләр...

Кичә Александр Семеновичлар штубесында яшьләр аеруча күп булды. Мин килеп кергәндә егерме биш-утызлап егет нарларның өченче катына ук менеп кунаклаганнар да, дөньяларын онытып, Женя Медведев башкаруында Блокның «Скифлар»ын тыңлыйлар иде.

Медведев — Одессадан, курку белмәс бер егет. Элек бронепоезд йөртүче булган, аннары чолганышта калып, әсирлеккә эләккән. Аннан качып барган вакытта аны фашистлар тотып алып Дахауга озатканнар. Женя поэзияне үлеп ярата һәм бик күп шагыйрьләрнең әсәрләрен яттан белә икән...

Аннары сүз Маседкинга бирелде. Шагыйрь башта үзенең берничә шигырен сөйләде, аннары Лермонтовның «Купец Калашников һәм Иван патша турында җыр»ын яттан укып чыкты. Бөек Лермонтов үзенең бу әсәрен йөз елдан соң менә шушы буй-буй сызыклы тоткын кием киеп, үлемгә хөкем ителгән кешеләр рәхәтләнеп, йотылып тыңлап утырырлар дип уена да китермәгәндер, әлбәттә...

Аннары бер яшь кенә, ябык кына егет ниндидер мәзәк тавышлы уен коралында «Катюша»ны үзе уйнап, үзе җырлап җибәрде. Миңа аның ул коралын карар өчен өченче катка менәргә туры килде. Әмма менүем үкенечкә калмады — моңарчы гомеремдә очрамаган музыка коралы күреп төштем. Ниләр генә уйлап чыгармый бу адәм баласы! Гап-гади консерва банкысына утыз биш-кырык сантиметр озынлыгындагы такта беркетелгән һәм шуңа кыл урынына төрле юанлыктагы тимер чыбыклар тарттырып куелган булып чыкты. Шунысы гаҗәп — егет бу балалайкасында бик оста итеп уйный иде. «Катюша»дан соң ниндидер җиңелчә генә русча бию көен дә уйнап җибәргәч, барактагыларның кәефләре тагын да күтәрелеп китте...

Бик әйбәт нәрсә уйлап тапкан бит бу Александр Семенович! Фашистлар тырнагына килеп эләккән әлеге яшь егетләргә менә шушындый җан азыгы, олыларның акыллы сүзләре, аталарча киңәшләре һава кебек, су кебек ук кирәк ләбаса! Бу яшь егетләр белән аралашканда Александр Семенович үзе дә яшәреп киткәндәй тоела. Андый чакта аның коңгырт-яшел күзләрендә шатлык очкыннары уйный, йөзе ачылып китә.

* * *

Дахау концлагере эчендә, кухнядан йөз илле метрлар чамасы читтәрәк, чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган эсэсчылар өчен махсус штраф лагере бар. Анда дезертирларны, политик яктан ышанычсыз дип табылган СС солдатларын һәм офицерларын ябып тоталар.

Кухнядан караган кешегә ул лагерьдагы хәлләр бик яхшы күренеп тора. Лагерь уртасында зур гына сазлык бар. Фашистлар штрафчы немецларны менә шунда куып кертеп, сәгатьләр буе тез тиңентен баткакта йөртәләр. Яки сәгатьләр буе җиргә йөз түбән яткырып, кулларында бер күтәрелеп, бер төшеп торырга мәҗбүр итәләр. Гадәттә мондый күнегүләрнең азагында штрафчылар тәмам хәлдән таеп, пычракка йөзтүбән капланалар.

Әйе, нацизмның вәхши принципларына каршы килгән очракта, фашистлар эсэсчыларның үзләре белән дә күп сөйләшеп тормыйлар.

Лагерьда гаепле эсэсчыларның башка төрләре дә бар. Ләкин алары «политик»лар түгел, бәлки урлап яки башка берәр җинаять эшләп эләккән бәндәләр генә. Аларга фашистлар бераз йомшаграк мөгамәлә күрсәтәләр. Аларны лагерьда кечкенә «фюрерлар» — рапортфюрер, лагерьфюрер һәм башкалар итеп куялар.

...Бүген егерме өченче февраль — Совет Армиясе көне. Эх! Заманында көндез полкта, ә кичен дус-ишләр белән бергәләп, нинди әйбәт итеп үткәрә идек без бу бәйрәмне! Ә хәзер... Менә әле яңа гына иртәнге барлау булды. Тиздән, эшкә җибәрер өчен, безне бригадаларга бүлеп тезәчәкләр. Көн бераз туңдырып тора. Әмма ачык зәңгәр күк йөзенә караган һәм Альп буе болыннарыннан искән ниндидер аеруча рәхәт, саф җилне тойган кешегә яз җитүен чамалавы кыен түгел. Ә яз — күңелдә өмет-омтылышлар кузгата торган вакыт!..

Кинәт минем җиңемнән тарттылар. Сискәнеп борылып карасам — Иосиф Лаушер икән. Аксыл йөзе борчулы, зәңгәр күзләре кайгылы иде аның.

— Читкәрәк китик әле, Сәгыйт,— диде ул акрын гына.— Коточкыч яңалык бар бит әле: бүген төнлә утыз бер совет очучысын крематорийда яндырганнар! Вагон идәнен тишеп качарга җыенган булганнар, шуның өчен. Бу турыда иптәшләреңә дә сөйлә, Сәгыйт, аларга да үз иптәшләренә әйтергә куш... Фашистлар хәзер тәмам котырындылар. Көнчыгыш фронтта җиңелүләренә ачулары чыккан аларның,— дип, Лаушер минем кулны зур, җылы учына алды.— Сәгыйт дус, бөтен иптәшләреңә дә әйт, без күңелебездән сезнең яклы... Һәрвакыт сезнең белән бергә...

Берьюлы утыз бер очучыны диген, ә?.. Лаушерның бу хәбәреннән соң күз алларым караңгыланып китте. Эшкә баргач та гел шул турыда гына уйландым, кулларым һич тә линза ялтыратырга теләми иде. Моны эсэсчы да сизеп алды булса кирәк: «Темп! Темп!» дип җикеренә башлады.

— Ни булды сиңа, Сәгыйт? — диде Панов, эсэсчы минем тирәдән киткәч. Аңа очучыларны яндырулары турында әйттем.

— Совет Армиясе көнен менә ничек билгеләгәннәр икән ул вәхшиләр! — диде Панов һәм, ачуына түзә алмыйча, бинокль пыяласын шытырдатып сындырып ташлады.— Бүген кичке аштан соң бөтен активны руслар яши торган баракларга җибәрергә кирәк... Фашистларның бу кансызлыгын барысы да белеп торсын!.. Очучыларны крематорийга ташлау — безгә кисәтү ул. Бик сак булырга кирәк хәзер безгә...

Кулларым бинокль җыя, күңелем Панов әйткән сүзләр турында уйлана. Безнең антифашистик группага нәкъ әнә шул саклык һәм тиешенчә яшеренлек җитеп бетми бит. Иң элек Пановның үзен сакларга кирәк. Әгәр фашистлар аның оешма активында торуын һәм комиссар

булганлыгын белеп алсалар, аны туп-туры газ камерасына яки крематорийга озатачаклар лабаса! Юк, моннан соң рус баракларына кереп йөрергә, бигрәк тә филиаллардан Дахауга килгән әсирләргә фронттагы хәлләрне сөйләргә ярамас аңа. Гадәттә, якшәмбе көннәрендә, Алахтан, Гиглингтан, Катреннан һәм Дахауның башка филиалларыннан кием-салым, азык-төлек алып китәргә машиналар килә монда. Машиналарны төягән арада аускомандада эшләүчеләрнең берәрсе һәрвакыт безнең баракка фронттагы яңалыклар турында сорашырга кермичә калмый, чөнки филиалларда радиоалгычлар юк. Күбесенчә безгә полк командиры Николай Павлович Борисенков, штаб начальнигы Иван Николаевич Орешников, хәрби инженер Михаил Петрович Седов һәм Виктор Крапивныйлар тарафыннан җибәрелгән кешеләр керә. Алар һәр яңалыкны йотылып тыңлыйлар. Язып алырга карандаш-кәгазьләр юк, билгеле. Әмма андый чакта хәтер дә бик яхшы, күп нәрсә сыйдыра бит ул! Совет гаскәрләре азат иткән шәһәр һәм район исемнәрен ике-өч тапкыр кабатласаң, отып алу өчен аларга шул бик җиткән... Безнең блокта халык болай ышанычлы кебек инде. Әмма фашистларның, филиалдан килгән әсирләр нигә гел шушы баракка керә икән, дип кызыксынулары бар бит... Димәк, безгә көчләрне чәчәргә кирәк булачак: филиалдан килүчеләрнең берсен минем белән, икенчесен Семен Моисеевич Маляров белән, өченчесен Медведев белән очраштырырга кирәк булыр. Очрашуны да гел безнең баракта гына түгел, башка урыннарда да билгеләргә мөмкин. Әйтик, әлеге һәрвакыт кеше күп йөри һәм шул сәбәпле фашистларда шик тумый торган «Ирек урамы»нда очрашырга да була ич...

Әле кичә генә безгә Артем Марценюк килгән иде. Ул әйтә: үзебезгә дә радиоалгыч эшләргә мөмкин булыр шикелле, ди. Максим Петрович Колобаев, Франтишек Зупка һәм Захарадислар радиоалгычлар һәм электр приборлары ремонтлый торган «Доктор Кимель» командасында эшлиләр икән. Менә шулар башта акрынлап детальләр алып кайтырга, аннары кичкенә генә, ләкин шактый көчле радиоалгыч эшләргә була дип әйтәләр, ди...

Әмма кая урнаштырырга соң аны? Советлар Союзыннан тапшыруларны тыңлаучыларга үлем җәзасы бирәләр бит!.. Димәк, лагерьда эсэсчылар азрак йөри, азрак күрә торган урын табарга кирәк... Бу мәсьәләне Артемга хәл итәргә куштык.

Володя безгә элеккечә көн саен диярлек килеп йөри. Кайчакларны үзе белән Саша исемле уникe-унөч яшьлек зәңгәр күзле бер малайны да ияртеп килә. Саша кайдадыр лагерьның аргы башында ук, әллә французлар, әллә чехлар барагында (хәтеремдә калмаган) яши икән. Володя аны бик ярата, шуңа күрә, иренмичә, безнең янга да алып килә иде.

Менә бүген дә алар икәү килеп керделәр.

— Тыңлагыз әле, Сәгыйт абый, Сашаның ни сөйләвен! — диде Володя, туп-туры минем янга килеп.

— Яле, Сашенька, тыңлап карыйк әле! — дидем мин, аның кәефе әйбәт булмавын сизеп.

Малайның зәңгәр күзләреннән кинәт эре-эре яшь бөртекләре тәгәрәп чыкты. Шулай да ул, юеш керфекләрен угалап, җиңе белән борынын сөртеп, үзен ничектер кулга алды да:

— Безнең баракка өченче көн балалар китерделәр, Сәгыйт абый, — дип сүзгә кереште. — Сиксән кеше алар... Бик кечкенәләре — җиде-сигез яшьлекләре дә бар... Бик ябыклар, беләкләре карандаш юанлыгы гына. Украинча сөйләшәләр. Кичә мин берсе белән болдырда утырдым. Куллары да, аяклары да карандаш юанлыгы гына...

— Ул малай нәрсә диде әле сиңа, Саша? — дип бүлдерде аны Володя. Күрәсең, малайның кирәкле сүзен тизрәк әйттерәсе килә иде.

— Нәрсә әйттеме?.. Эти беләи әнине немецлар асты, ә мине газ камерасында тончыктырып үтерәчәкләр, диде. Мине дә, мондагы башка малайларны да шулай итәчәкләр, диде. Дөрес әйтә микән ул, Сәгыйт абый?

Шушы малайларның сүзен тыңлап, аларның фашистлар тарафыннан һичшиксез юк ителәчәген белеп торганчы, Ельня тирәсендә мине яралаган граната кыйпылчыгы, яралап кына калмыйча, үтереп үк киткән булса, яхшырак булган булыр иде, бәлки. Минем кебек олы кешегә, олы кеше генә түгел, балаларны, хатын-кызларны, карт-карчыкларны сакларга тиеш булган кадровый офицерга, менә шушы күзләрен өмет белән текәп торучы ике бала каршында, берничек тә ярдәм итә алмыйча, үземнең көчсезлегемне тоеп торудан да яман нәрсә булырга мөмкинме соң?

Нишләргә дә белмәгәч, мин Сашаның башыннан сыйпаган булдым. Эх, бу малайның күз яшьләрен туктатыр, бу куркыныч сорауларын оныттырып торыр өчен, һич югында, бер генә шакмак шикәрем булсын иде, ичмасам! Ләкин минем бернәрсәм дә юк шул... Аларның хәлен җиңеләйтерлек берни дә эшли алмыйм мин...

Бераз тынычлангандай булып, малайлар кайтып киткәч, Лунгинс янына бардым. Ул балаларны газ камерасыннан коткарып калу өчен берни дә эшләп булмас микәнни?

Лунгинс, гадәтенчә, мине игътибар белән тыңлады. Аннары йөзе караңгыланып, күз тирәләрендәге җыерчыклары тагын да тирәнәеп, зураеп киткәндәй булды. Һәм ул акрын гына нарына барып утырды. Гадәттә көр күңелле бу кешенең хәзерге минутта бик авыр хисләр кичерүе күз карашыннан ук сизелеп тора иде. Читен, бик читен иде аңа үз милләттәшләренең вәхшилеген көн саен, сәгать саен күреп тору.

— Юк, Сәгыйт, без ул бичара балаларга берничек тә ярдәм итә алмыйбыз, — диде Лунгинс, тирән көрсенеп. — Алар үлемгә дучар ителгән... Шуңа монда китергәннәр аларны. Тик бу немецлар барысы да шундый явыз дип уйлый күрмәгез, Сәгыйт. Фашизм — ахмаклык, котырганлык ул... Эшкә ярарлык, үзләренә файда китерә алырлык кешеләрне, тәмам хәлдән таеп, эштән чыгып егылмыйча, үтерергә ашыкмыйлар монда... Безнең бер иптәш конторда эшли, картотекалар тотырга булыша. Фашистлар һәр әсирнең күпме файда китерә алуын бик җентекләп исәпләп чыгарганнар. Коточкыч бухгалтерия ул, Сәгыйт. Алар исәбе буенча, эшләүче тоткынның гомере монда тугыз ай, ягъни ике йөз житмеш көн икән. Ашау-эчүгә, киемгә киткән расходларын чигереп ташлаганнан соң да, тоткын крематорийга барып кергәнче шактый зур табыш калдыра икән. «Табыш» дигән графада барысы да: әсирнең күпме эшләве дә, алтын тешләре дә, акчасы һәм башка шундый кыйммәтле әйберләре дә, хәтта яндырылганнан соң аннан күпме көл калуы да исәпкә алынып барыла... Ә балалар?.. Алар бары зыян гына бит. Хәтта янганнан соң көлләре дә аз була. Шуңа аларны озак тотмыйлар нацистлар... Менә эшләр ничек бит, дустым Сәгыйт!..

Бүген төнлә тагын тентү булды. Бу юлы баракны аеруча каты сүгенешеп актардылар. Хәтта берничә җирдән идәннәрне куптарып, фонарьлар белән идән асларына кадәр яктыртып карадылар. Кырык минутка сузылган бу тентүгә лагерь офицеры Юнг җитәкчелек итте. Без кырык минут буена «смирно» басып тордык.

Бөтен баракның астын өскә әйләндереп ташлаганнан соң, ниһаять, кара тутлырак йөзле бер озын гына кешене алып керделәр. Алтынчы баракның икенче камерасында яши иде ул. Элек көнбатыш Украинада агроном булып эшләгән булса кирәк. Әнә шул кешене барак уртасына бастырдылар да:

— Менә бу рус сезнең блокта коммунистлар автомат һәм башка кораллар яшергәннәр дигән иде, — диде Юнг, теге кешегә күрсәтеп. — Ул

шулай ук сез баш күтәрергә җыенасыз икән дип тә әйтте. Тентү вакытында без корал тапмадык. Бу тоткын безне алдады, ә сезгә хыянәт итте. Сатлык җан ул. Без бу кешене яратмыйбыз. Бүген ул русларны сата, ә американлылар килсә, немецларны аларга сатар. Мин бу кешене сезнең хөкемгә тапшырам.

Юнг шулай диде дә үз табакташларын ярып чыгып китте. Ә баракта коточкыч тавыш купты. Кемдер әлеге сатлык җанның янагына тамызып алырга да өлгергән иде, ул канлы борынын каплап почмакка елышты.

Ә халык һаман саен кыза барды:

— Бәреп үтерергә кирәк, кабахәтне! Хәзер үк лагерь судны ясарга үзенә!

— Нинди судлап тору ди ул тагын! Өзгәләргә дә ташларга этне!

Василий Ефимович Стрелков һәм Иван Иванович Петров, шаушуны туктатырга теләп, бар көчләренә:

— Иптәшләр, иптәшләр! Туктагыз әле, тынычланыгыз әле! — дип кычкырдылар.

Панов мине һәм тагын берничә өлкән офицерны үз янына чакырып китерде:

— Иптәшләргә шуны аңлатырга кирәк, — диде ул, — әгәр бу хыянәтчене үтерсәк, фашистларга безнең барыбызны да юк итү өчен сәбәп кенә булачак... Хыянәтчене соңыннан тикшерербез, ә хәзергә әйдәгез, халыкны тыярга кирәк...

Ярты сәгатьләп вакыт үткәч, ниһаять, барак тынып калды. Барысы да үз урыннарына таралыштылар. Ә агроном, ярым үле, ярым тере хәлендә һаман да почмакта басып тора иде. Аны бер читкәрәк алып киттек тә безнең корал җыюыбыз һәм баш күтәрергә әзерләнүебез турында кайдан белүен сорадык.

— Кичә төнлә йокламыйча ята идем мин, — диде ул. — Шунда кемнәрнеңдер шыпырт кына: «Берәмләп качу мөмкин түгел монда. Коралны восстание күтәрергә кирәк!» дигәнен ишеттем. Тик кемнәр икәнен аера алмадым. Аннары алар аерым детальләрдән корал җыю турында да сөйләшә башладылар.

Полковник Петров артык түзә алмады.

— Әгәр корал тапсалар, бөтен блокны юк итәчәкләрен уйламадыңмы соң син, сволочь! — диде.

— Заговорны фаш иткән өчен, ихтимал, ирекә чыгарырлар дип уйлаган идем мин. Аннары мин румын подданные бит, — диде бу сатлык җан.

— Румын подданные түгел, адәм актыгы син! Аңладыңмы? — диде Ленский һәм, әрем капкандай чыраен сытып, төкереп куйды.

Аннары сакчы сатлык җанны үзе белән алып чыгып китте. Барак тып-тын булып калды.

* * *

Язның күнелләрне җилкендерә торган иң матур чагы.

Дөньяга үлән исе, яфрак исе һәм күңел кузгаткыч җир исе таралган вакыт. Ләкин без җанга рәхәтлек бирә торган шул табигый исләрне дә күкрәк тутырып исни алмыйбыз. Көне-төне крематорий морҗасыннан чыгып торган әче төтен барысын да каплап китә...

Оптика цехы каршында эсэсчылар өчен төрле яшелчә әйберләре: кишер, суган, редиска, укроп утыртылган. Төшке аш вакытларында эсэсчы Франц бездән ул яшелчәләргә су сиптерә, чүпләрен утата. Менә шул чакларда кояш кызуында җәйрәп яткан җирдән чыккан ис борыннарны кытыклап, күңелләрне әллә нишләтеп нечкәртеп җибәрә һәм ту-

ган якларны искә төшерә. Күрәсең, җир исе шушы каһәрләнгән Дахау лагеренда да, безнең Оренбург даласында да бертөрледер инде!

Бүген миңа артык куе булып тишелгән кишер үсентеләрен сирәгәйтергә кушылды. Аның үзенә бертөрле тәмле исе нигәдер газиз әнкәемне, аның туктаусыз эшләүдән ярылып, кытыршыланып беткән, ләкин шулай да гаҗәеп йомшак кулларын искә төшерде. Әй, әнием. Бердәнбер газиз әнекәем! Бигрәк авырдыр инде сиңа. Кече улың инде фин сугышында ук үлеп калды... Уртанчы улың Хәлил фашистларга каршы сугышып йөри... Кем белә аны — әллә исән, әллә күптән үлгән инде ул... Инде килеп мин, олы улың Сәгыйт, монда тоткынлыкта ятам, әнием. Нәрсә уйлыйсың икән син минем турыда? Нинди хәбәр китерделәр икән сиңа?.. Үлде яки хәбәрсез югалды диделәрме икән? Әллә, улың хыянәтче булган, илен сатып, дошман ягына чыккан, диделәрме икән?.. Юк, алай димәсләр. Әйткән булсалар да, әнием ышанмас аңа. Юк, ышанмас, ышанамы соң?.. Кыен безгә, икебезгә дә кыен, әнекәем! Бер безгә генә түгел, меңнәргә, миллионнарга кыен...

— Кичә Семен килгәндә син баракта юк идең, — диде минем белән бергә кишер сирәкләүче Иван Иванович Петров, уйларымны бүлеп. — Семен әйтә: безнең армия Одессаны һәм Кырымны азат иткән, ди! Шатлыгымнан биеп китәрдәй булдым.

— Биесәң дә гаҗәп түгел: синең туган якларың азат ителгән бит!.. Әйбәт пешекләнәләр, болай булгач, фашистларны, ә? Әллә чыннан да, җиңү көнен күрергә насыйп булыр микән безгә? Син ничек уйлыйсың, Иван Иванович?

— Исән калсак — күрербез, Сәгыйт... Сезнең эшләр ничек анда, концерт программагызны төзеп бетерәсезме әле?

— Әйе, Ленский һәм Семен белән бергәләп ул турыда киңәштек инде без. Кичә рәсми рәвештә Пушкинга багышланып үткәреләчәк, ә шигырьләрнең төрлесен укырга мөмкин булыр дип уйлыйбыз. Бары тик программада гына «Пушкин» шигыре дип язылган булсын. Моны мин башка лагерьларда булган тәҗрибәдән чыгып әйтәм.

— Кальварияне Дахау белән чагыштырып булмый бит, Сәгыйт. Иптәшләрне кыен хәлгә куймагаегыз...

— Без бит башкарылачак номерны әйткәндә үк: «Пушкин. Паспорт турында шигырь», — дип әйтәчәкбез, Иван Иванович. Ә Захаров Маяковский шигырен укыячак.

Петров көлеп куйды.

— Син лагерь начальствосын бөтенләй ахмак дип уйлыйсыңмы әллә, Сәгыйт?

— Юк. Немецлар ахмак түгел. Хикмәт шунда: аларның барысына да кәгазьгә язылган сүзләргә ничектер фанатикларча ышану хас. Кәгазьдә Пушкин дип язылган икән, димәк, кичәдә бары тик аның шигырьләре генә укылачак дип уйлаячаклар алар һәм һич тә шикләнмәячәкләр... Әйе, әйе, сугыш турында да шул кәгазьгә язылганнарга һичшиксез ышанулары күренеп тора аларның. Мәсәлән, фашист газеталарында һәм китапларында рус армиясенең техникасы йомшак, алар сугышка әзер түгел, рус халкы — түбән раса, кыргый халык дип язалар. Ә эсэсчылар шуңа ышаналар. Инде безнең гаскәрләр үзләрен пыр туздырып куа башлагач та, һаман да шул фикерләрендә торалар бит, чөнки алар, әлеге дә баягы, кәгазьгә язган сүзләргә ышаналар...

Лагерьдагы совет тоткыннары арасында профессиональ актерлар, җырчылар, музыкантлар һәм элек үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә катнашып йөргән кешеләр дә байтак булып чыкты. Безнең баракта Кириленко фамилияле бер трубач яшь. Начальство аны эсэсчыларның күңелен ачу өчен оештырылган лагерь оркестры составына кертте. Шул оркестрда уйнаучыларга хәтта Мәскәү гостиницаларындагы швейцарларныкын хәтерләтә торган махсус киемнәр дә бирделәр.

Безнең булачак концертны әзерләүдә элек Киев театрларының бер сендә эшләгән артист Ленский бик тырышып йөри. Нинди юллар белән алгандыр — анысы безгә караңгы, әмма сап-сары чәчле, ап-ак йөзле бу житез кеше рус баракларының берсендә кичә үткәрергә рөхсәт алып куйган инде. Бүген без — Семен Маляров, Ленский, Шалыга (ул да Киев театры артисты) һәм мин — дүртебез бергәләп концерт программаларын төзедек. Программаларын дип шуна әйтәм: без ике программа төзедек. Берсе — рәсми, начальство өчен, ә икенчесе — яшерен, башкаручылар өчен.

Начальство өчен төзелгәненә гел Пушкин әсәрләрен генә керттек. Шигырьләр дә, «Евгений Онегин»нан арияләр дә, романслар да күп анда. Ә башкаручылар өчен булган программага «Катюша», «Землянка», «Изге сугыш» һәм башка җырларны билгеләдек.

Җырчы Шалыга Степан Разин турындагы рус халык җырларын, «Вот мчится тройка почтовая», «Дубинушка»ларны башкарачак. Артист Ханов «Кармен» операсыннан Тореадор ариясен, Жуков совет җырларын җырларга булдылар. Ә Ленский миңа, сер итеп кенә, нинди дер бер Вожак дигән бәндәнең сугыш башлавы, аннары уңайсызлыкка очрап, кайбер кирәкле әйберләрен дә кияргә онытып, качып китүе турында үзе язган мәсәлне сөйләячәген әйтте һәм аны сөйләп тә күрсәтте. Бик кызык мәсәл ул. Аның кемгә ишарә ясавы да ачык аңлашылып тора. Тамашачыларга да, һичшиксез, ошаячак ул. Тик менә немецлар гына сизмәсен инде.

— Хафаланмагыз, подполковник, — диде Ленский, аңа бу шигемне әйткәч. — Пычагымны да аңламаслар! Әгәр шикләнеп калып яңадан кабатларга кушалар икән, мин аларга «...Олег турында җыр»ны сөйләп бирермен. Анда да сүз поход турында бара ич!

Җыеп кына әйткәндә, концерт шактый кызыклы һәм файдалы булырга тиеш.

* * *

Кичә концерт вакытында тамашачыларның елмайган якты йөзләренә, очкынланып ялтыраган күзләренә карап торганда аларның кайберләрен хәтта таный да алмадым мин. Чыннан да, елмайган-көлгән чакта кешенең йөзе шактый үзгәрә бит. Ә монда мин кайберәүләрнең елмаюын беренче мәртәбә генә күрдем.

Концерт ике сәгать — кичке тугыздан унбергә хәтле — барды. Һәм аның файдасы әйтеп бетергесез зур булды. Беренчедән, концерт вакытында ясалган ике тәнәфес вакытында безнең активистлар тамашачы тоткыннарга фронт хәлләрен сөйләсәләр, икенчедән, тәмам өметсезлеккә бирелгән кайбер кешеләрнең дә күңелләре яктырып, фикерләре ачылып китте. Күзе калайланып, йөзе нурсызланып калган шундый адәмнәрнең берсе, мәсәлән, Ленский янына килде дә:

— Менә, артист иптәш! Ике ел әсирлектә яшәү дәверемдә беренче тапкыр көлдем мин бүген. Көлү, елмаюларның нәрсә икәнен дә оныткан идем. Рәхмәт, искә төшердегез! — диде.

Безне Пушкин кичәсе канатландырып җибәрде бит! Бер ай — ай ярымнан (шуннан да иртәрәк рөхсәт итмәсләр) Лев Толстойга багышланган икенче кичә үткәрергә булдык. Мондый концертларга рөхсәт бирә торган кешегә Ленский шул уебызны әйткәч, теге мәгънәле генә итеп каш сикертте дә:

— Зер гут! (Бик яхшы!) Граф Толстой! О-о! Гений! — диде.

Захаров белән Ленский бергәләп «Сугыш һәм солых»ны исләренә төшерергә дә керештеләр инде. Романда Наполеонның Мәскәүне ташлап качуы сурәтләнгән битләрдән өзекләр сөйләмәкче алар. Бу да шулай ук барысына да аңлашыла торган ишарә булачак. Гитлер хәтта чәчен дә Наполеонныкы сыманрак итеп, маңгаена төшереп йөртә бит!

* * *

Без үзебезгә радиоалгыч булдырырга ниятләгән идек. Әле дә ул уебыздан кайтканыбыз юк. Үзган берничә ай эчендә шул радиоалгыч өчен кирәк булачак барлык детальләрне дә акрынлап-акрынлап цехтан алып кайттылар инде. Аларны канализация трубаларында, дезинфекция камераларында яшереп тоталар. Рәхмәт егетләргә! Зур тәвәккәллек сорый торган бик куркыныч эш бит бу! Дөрес, лагерь уставында радио детальләре урлап кайткан кешегә нинди җәза биреләчәге турында аерым пункт юк югын. Ләкин әләккән тәкъдирдә, кем дигәндә, штраф барагына китәсеңне көт тә тор инде!

Радиоалгычны җыйнаганнан соң куяр урын да таптык. Геннадий Нуретдинов белән Алексей Ткаченко ул эшне үз җаваплылыкларына алырга булдылар. Геннадий белән Алексей кер юу командасында эшлиләр. Кер юа торган бинада берничә бүлек: юылган кер, юылмаган кер бүлекләре, тиф һәм башка төр йогышлы авырулар киемен дезинфекцияли торган бүлекләр бар. Менә шул дезинфекция бүлеге иң аргы башка урнашкан һәм аның ишеге дә аерым, бөтенләй икенче якта. Шунда ук үтүк кыздыру өчен розеткалар да бар. Аларга радиоалгыч тоташтырырга да мөмкин. Ә иң мөһиме шул: анда эсэсчылар кереп йөрмиләр — куркалар.

Радиоалгыч куяр урын булгач, аны җыючысы да табылды. Иректә шартларда да гаҗәеп зур осталык сорый торган катлаулы бу эшне Сергей Дорофеев башкарды. Радиоалгычны Кызыл Хачтан кайсыдыр ил тоткыннарына килгән посылка ящигына җыйды. Беренче мәртәбә үз радиоалгычыбыз китергән хәбәрне ишеткәннән соң никадәр шатлануыбызны беләсезме иде! Юк, әйтеп-сөйләп кенә аңлатып бетереп булмый ул шатлыкны! Үзе кичергән кеше генә тулысынча аңлый аны...

Радиоалгычны, ул-бу була калса дип, дезинфекция казанына яшереп, өстенә пычрак киемнәр каплап торалар. Ә уңайлы вакытта, бигрәк тә иртәнге сводкаларны тапшыру минутларында, я Нуретдинов, я Ткаченко аны яшеренеп кенә эшләтеп алалар. Аннары, ышанычлы кешеләр аркылы, яңа хәбәрләр бөтен рус тоткыннарына таратыла.

Геннадий белән Алексейның кыяфәтләренә хәтле әллә ничек үзгәреп, хәрәкәтләренә кадәр җиңеләеп китте хәзер. Хәер, гаҗәпләнерлек урын да юк: Левитан тавышын, җиңү салютларын иң беренче булып ишетә бит алар! Радиоалгыч белән мавыгып йөргәндә йогышлы авырулардан салдырылган керле киемнәрдән авыру эләгүе яки берәрсе сизенеп алып, үзләрен фаш итүе дә бик ихтимал бит. Ул чагында беттең инде. Шундук газ камерасына илтеп тыгачаклар аларны. Әмма бу егетләр анысын уйлап та бирмиләр...

Мин Лунгинс белән сөйләшергә бик яратам. Бу зирәк немец белән гәпләшкәч, күңелем әллә ничек баеп китә, ышанычым арта төшә. Дахау лагере турында мондагы тоткыннарның барысыннан да күбрәк белә ул. Лунгинс күптәннән инде коммунистлар партиясе члены. Тельман белән дә яхшы таныш булган.

— Лагерьга ябылуыбызның беренче елларында безгә — коммунистлар һәм социал-демократларга — нинди зур көрәш алып барырга туры килгәнен беләсезме, Сагыйт? — диде ул миңа бер көнне. — Лагерьдагы бөтен административ урыннарга үзләренең аңгыралыклары аркасында безне күрә алмый торган уголовникларны куйганнар иде бит! Аннары фашистлар үзләре дә, кем коммунистларны һәм гомумән кызыл венкельлеләрне (политик тоткыннарны) күбрәк кимсетә, хурлый — шуны тизрәк иреккә чыгарабыз, дип котыртып торалар иде. Коточкыч хәл иде ул, Сагыйт! Блок башлыклары да, штубе башлыклары да, писарьлар

да, каполар да — барысы да шул яшел венкельле[1] бандитлар иде. Эшчеләр командаларында да, складларда да, мунчада да, крематорийда да, изоляторда да шул ук уголовниклар өлкәнлек итәләр иде... Әнә шул «яшел»ләр урынын «кызыллар» алсын өчен, күпме ачлык игълан итәргә, никадәр протестлар белдерергә туры килде безгә! Сер итеп кенә әйтәм, Сәгыйть: кайбер уголовниклардан аларны үтереп кенә котылырга туры килгән чаклар да булгалады... Шульц дигән бер блок башлыгы бар иде, мәсәлән. Аннан да кабахәт җанның, белмим, булуы мөмкин микән? Немец уголовный кодексы законы буенча, гомер буена төрмәдә черетелергә тиеш бәндә иде ул. Әмма нигәдер аны Дахау лагеренда тоталар иде. Ай-яй, җәберләде дә соң инде безне! Ни өчен дисеңме? Үзен начальство каршында яхшы итеп күрсәтер өчен, Сәгыйть. Без, каршылык группасындагы кешеләр, һич тә түзәр чамабыз калмагач, йоклатмыйча җәзалап үтерергә булдык аны. Йөз кешедән дежур тору графигы төзедек тә Шульцка йокларга ирек бирми башладык. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында аны чиратлашып сөйләштерә, сәбәп табып, кая булса да аны чакыра башладык. Шулай йоклатмыйча йөдәтүебезнең дүртенче көнендә дөмекте ул. Аннары бу хәлне ишетеп белгән кайбер уголовниклар үзләре үк, рядовой итеп калдыруны сорап, гаризалар бирә башладылар... Ә хәзер, Сәгыйть, күрә торгансыңдыр: лагерь эчендәге бөтен кечкенә начальниклар да дип әйтерлек — кызыл венкельле кешеләр... Син теге сатлык җан румынны пишләтергә икән дисең. Шуның кебек үк үләргә тиешле кабахәт җан ул.

## Көрәшебез активлаша бара

Кичә кичке аштан соң яңа китерелгән тоткыннарны урнаштырган баракка кергән идек — аптырап калдык. Алар арасында элек армия командующие булган генерал-майор Сергей Владимирович Вишневский да бар иде. Аны да, Пресняков кебек үк, немецлар «бик зурлап» Рославльдән Берлинга, «истәлекләр язарга» дип алып киткәннәр иде.

Исәнлек-саулык сорашканнан соң, Сергей Владимирович кыска гына үзе турында сөйләп алды. Аны да немецлар бернинди Берлинга да алып бармаганнар, бәлки лагерьдан лагерьга күчереп йөртә торгач, ниһаять, Дахауга озатканнар икән. Соңгы айларда ул Флесенбург концлагеренда яшәгән.

Сергей Владимирович белән бер этапта Дахауга танк бригадасы командиры генерал-майор Николай Филиппович Михайлов, генерал-майор Тонконогов, полковник Ковалев, берничә комиссар — барлыгы иллеләп кеше китерелгән иде.

— Николай Филиппович туберкулез белән авырый, — диде миңа Вишневский, кипкән яфрак төсле саргаеп-сулып калган һәм мәеттәй хәрәкәтсез яткан генерал Михайловка таба ымлап. — Бик бетәшкән ул. Госпитальга урнаштырырга иде аны. Ничек тә урнаштырасы иде!

Вишневский шулай диде дә тынып калды. Мин аңа җентекләбрәк карадым. Хикмәт шунда: ул үзе дә бик ябык, аягында чак-чак кына басып тора иде. Әмма шул хәлендә дә иптәше өчен кайгыртып азаплана, шунысы гаҗәп иде миңа...

Сергей Владимирович — зур тәҗрибәле, хәрби эшне бик әйбәт белүче командир. Армиядә Николай патша заманыннан бирле хезмәт итеп килгән. Әмма, кызганычка каршы, ул белеме, тәҗрибәсе белән армиягә, илгә файда китерә алмый калган. Сугыш башында ук әсирлеккә элəккән...

---

[1] Яшел венкель — тоткынның профессиональ җинаятьче булуын белдерә.

Җәйге тын кич. Мондый кичләрдә берәүнең дә блокларда, штубеларда утырасы килми. Шуңа күрә әсирләр әлеге «Ирек урамы» буйлап акрын гына арлы-бирле йөренәләр.

Панов, Маляров, Марценюк һәм мин «һава сулап» шунда йөрибез. Аннары безгә Власкин да килеп кушыла. Яңа китерелгән тоткыннар хакында сөйләшә башлыйбыз.

— Аларны ничек тә безнең группага тартырга кирәк... Бигрәк тә Вишневскийны. Акыллы кеше, бик әйбәт оештыручы һәм зур хәрби начальник ул, — ди Панов.

— Ләкин башта бераз хәл кертергә кирәк әле аңа! — ди Власкин.

Мин Семенга мәгънәле генә итеп карап алам да:

— Әле өченче көн генә безнең белән дус чит ил тоткыннарына берничә посылка килгән иде. Димәк, безгә дә ул кадерле ризыктан бераз өлеш чыгар дип ышанырга мөмкин. Аускомандада эшләүче иптәшләр дә азрак бәрәңге табарга вәгъдә иткәннәр иде... Бәлки, генерал Вишневскийга да өстәмә порция оештырып булыр. Син ничек уйлыйсың, Семен? — дим.

— Мин дә шулайрак уйлыйм, Сәгыйт Абдуллович.

— Генералны ничектер безнең оптика цехына урнаштырасы иде бит, — ди Марценюк.

Ә Михайловны ревирга салырга кирәк, — ди Панов. — Анда туберкулез бүлегендә чех врачы эшли бит. Зупка белән сөйләшеп карарга кирәк булыр.

— Анысын эшлибез аның... Галашка белән килешермен, — ди Семен һәм, Сергей Пельманны күреп алып, аны да кул изәп безнең янга чакыра башлый.

— Юк, Семен, калдырып тор бу юлы, — ди аңа Панов. — Болай да биш кеше җыелганбыз бит инде. Бүленешегез, иптәшләр. Безне бергә күрмәсеннәр. Ә син, Семен, Сергей белән соңыннан сөйләшерсең.

Мин Панов һәм Власкин белән китәм.

— Сәгыйт Абдуллович, Орешников белән кайда очрашырга сөйләшкән идегез? — дип сорый Панов, бераз тыныч кына атлагач.

— Шушы «Ирек урамы»нда очрашырга сүз куешкан идек. Алар бу юлы продуктлар алып китәргә киләчәкләр.

— Бик яхшы, алай булгач. Димәк, Седов җибәргән кеше минем янга баракка киләчәк. Ә Громов белән син очрашачаксыңмы, Тимофей?

— Әйе, иптәш Панов...

Якшәмбе көнне безгә зуппе, ягъни макаронлы аш бирәләр. Атна буена көтеп алынган бердәнбер юньлерәк ризык ул. Кайчакта безне, берничә рус офицерын, Фриц Лаушер үз штубесына чакырып, өстәмә порция белән сыйлаштыра. Ләкин төшке ашка ерак әле, һәм мин бүген, халык кайнап торган «Ирек урамы» буйлап арлы-бирле йөрим. Филиаллардан машиналар килергә тиеш...

Әһә! Әнә, килделәр дә бугай инде!

Начальниклары документлар артыннан йөргән арада төяүчеләр буш булалар. Менә шул форсаттан файдаланып, тиешле кешеләр белән очрашып, фронттагы хәлләр турында мәгълүматлар алып китә алар...

Бүген Орешниковка безнең гаскәрләрнең Карелия һәм Ленинград фронтларындагы уңышларын һәм Ленинград тирәсендә фашистларның көчле оборонасын өзүләрен сөйләдем.

— Аллага ышанмыйм мин, Сәгыйт Абдуллович. Аллага ышанмыйм, әмма тәки «Аллага шөкер!» дип әйтәсем килә бит, әй! — диде ул, шатлыгыннан мине кочаклап алып.

Һәм Орешниковның күзләренә шатлык яшьләре бәреп чыкты.

Ләкин хискә бирелеп торыр чак түгел иде.

— Менә нәрсә, җан кисәгем, — дидем мин ана, кинәт кискен тонга күчеп. — Сез анда бераз саграк булыгыз. Бу яналыкларны үзегездәге тоткыннарга чылбыр буйлап кына таратыгыз. Югыйсә сезнең бер иптәш филиалга кайтып житү белән баракка йөгереп кергән дә полный доклад ясаган. Ярамый алай!

— Карагыз әле, Сәгыйт Абдуллович, — диде Орешников, шундук житдиләнеп китеп. — Монда безнең белән хатын-кызлар лагерьларыннан да өч машина килде. Шул машиналарның шоферлары әйтә, үткән атнада атна буе Дахауга хатын-кызларны озатып тордылар, диләр. Барлыгы меңләп хатын-кызны озатканнар булып чыга. Политик агитация алып барган өчен озатканнар, имеш. Чәчләре кырылган, үзләрен ирләр киеменә киендергәннәр, ди. Сез бу турыда берәр нәрсә белмисездер?

— Юк. Ләкин...

Күңелдән коточкыч шик йөгереп үтте. Аларга монда эшләр эш юк. Әгәр эшләсәләр, хатын-кызларның кайсы цехта эшләвен белми калмас идек инде. Димәк...

— Әллә аларны җәзалап үтерергә китерделәр микән соң монда? — диде Орешников, аптырашка калып.

— Шуңа охшый шул, болай булгач... Крематорий көне-төне эшләп тора бит... Ярый, тикшерербез... Әгәр аларны агитация өчен яндыралар икән... Аңлыйсызмы, безгә ничек сак булырга кирәк хәзер!.. Бары тик индивидуаль тәртиптә генә эш итә күрегез, иптәш Орешников!.. Бетерегез ул докладларны!..

Ничек ачыкларга соң бу хатын-кызлар мәсьәләсен? Бәлки безнең чит ил иптәшләребез берәр нәрсә белә торганнардыр? Үзебезнең яшүсмер тоткыннарга мөрәҗәгать итеп караудан да зыян булмас. Алар — үткән халык, әллә нәрсәләрне күреп-белеп торалар.

* * *

Тегү мастерскоенда немец солдатларына мундирлар да, буй-буй сызыклы тоткын киемнәре дә тегәләр. Анда эшләүчеләрдән Власкин, Макаров, Киселев һәм Демусларны мин яхшы беләм. Киселев белән Демус — әле мыек та төртмәгән яшь кенә украин егетләре. Тимофей Кириллович Власкин исә — урта яшьләрдәге бик акыллы, сабыр кеше, безнең группаның актив члены. Безнең группа үз алдына бурыч итеп куйган төп эшләрнең берсен — саботаж оештыруны бик тырышып тормышка ашырырга тотынды. Әле кичә кичен генә:

— Немецларның машиналары пычагыма да ярамый!.. Һаман ватылып кына торалар, — диде ул, хәйләкәр елмаеп.

— Нәрсә сөйлисең син? Минем әнинең «Зингер» фирмасы чыгарган машинасы илле ел берииндә ремонтсыз эшләгән! — диде аңа Никифор Иванович Молоков, шаяртып, аптыраган булып.

— Синең анаң ул машина белән фашист киеме текмәгән шул!.. Кыскасы, атналык планның яртысы да үтәлмәде. Мастер эсэсчының җен ачулары чыга. «Рус дуңгызлары! Яңакларга кирәк сезне! Эш рәте белмисез! Гел өйрәтеп кенә торырга кирәк!» — дип җикеренә.

Шунда мин үзебезнең Францны искә төшердем. Боларныкы белән чагыштырганда шактый тыйнак ул тыйнагын, артык каты сүгенми. Әмма рус офицерларының «томаналыгына», бинокльләрне әле һаман да юньләп җыярга өйрәнмәүләренә ул да гаҗәпләнеп бетә алмый... Нишлисең бит, шулай «Ахмак Иван» булып йөрү — бу очракта саботаж ясау өчен иң кулай чара безгә. Шуңа күрә немецларга бер дә хәтеребез калмый. Тик артык кызып китмәскә, чамадан уздырып җибәрмәскә генә кирәк!

Дахау лагеренда, алда мин әйтеп киткәннәрдән тыш, тагын бер чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган һәм эсэсчылар тарафыннан бик тырышып саклана торган зона бар. Зона эченә берничә барак, житештерү цехлары һәм складлар урнашкан. Ул цехларда «мессершмитт»лар өчен кирәкле детальләр ясыйлар. Немецлар ул зонаны «прецефикс» дип йөртәләр. Менә шул прецефикста дүрт йөздән артык төрле милләт тоткыннары яши. Аеруча руслар күп. Барлык халыкара конвенцияләр буенча да хәрби әсирләрне үз ватандашларына һәм союздашларына каршы сугышу өчен корал һәм сугыш техникасы эшләп чыгарырга мәҗбүр итү катгый рәвештә тыела. Әмма фашистлар ул законнар белән исәпләшеп тормыйлар!

Безнең группа әнә шул прецефикста эшләүчеләргә ничек йогынты ясау турында күптәннән уйлый иде инде... Шундый әһәмиятле детальләр житештерүче тоткыннарга үз эшләрендә брак һәм яшерен саботаж ясау турында аңлату-агитация алып барганда, бик шәп булыр иде бит! Ләкин прецефикста эшләүчеләр белән аралашу мөмкин түгел. Дөрес, атна-ун көнгә бер тапкыр анда торучы тоткыннарны лагерьдагы күмәк мунчага алып килаләр. Әмма ул арада гына ни эшләп була соң? Бигрәк тә эсэсчы сакчылар күз алдында!

Уйлаша торгач, без тоткыннар белән уртак тел табып, аларны берләштерә алырлык бер үз кешебезне прецефикска җибәрергә, дигән карарга килдек. Башка чара юк иде.

Бу җаваплы эшне Михаил Петрович Седовка йөкләдек. Михаил Петрович батыр йөрәкле, сабыр холыклы һәм башкалар белән бик тиз уртак тел таба белә торган кеше, 1941 елда әсирлеккә эләккән хәрби инженер иде.

Седовны прецефикска урнаштыруда безгә чит ил тоткыннары, атап әйткәндә, лагерь канцеляриясендә эшләүче Раймонд Шнобель ярдәм итте.

Михаил Петрович февраль башында прецефикска күчерелде һәм безнең антифашистик группа билгеләгән план буенча эш итә башлады. Аның агитациясе нәтиҗәсендә тоткыннар бик зур саклык белән генә барлык цехларда да брак ясый башлаганнар иде. Әнә шул тыштан караганда бер дә сизелмәслек браклар җыелып, әзер продукция бөтенләй эшкә ярамаслык хәлгә килә. Дөрес, бик хәтәр эш инде бу. Моның өчен тоткыннар арасында нык дуслык, фикердәшлек кирәк. Әмма, Михаил Петровичның тырышлыгы аркасында, прецефикстагы рус тоткыннарына чит ил тоткыннары да ярдәм итәләр иде. Цех мастерларыннан поляк Вольневич, австриялеләр Бергер, Бронштетер, Вицекслар һәм әзер продукцияне кабул итеп, тиешле урынына озатырга әзерләү белән житәкчелек итүче грек Николас Захарадис белән бер фикердә булмасалар, седовчыларга, әлбәттә, бик кыен булыр иде. Заказчыга — «Мессершмитт» фирмасына — брак продукцияләр озату өчен шактый тәвәккәллек кирәк ләбаса! Ә Николас рус дуслары хакына бу эшне һич икеләнүсез башкара...

Зәңгәр күзле кечкенә Сашаны ияртеп, кичке аштан соң Володя бүген дә безнең баракка килеп керде. Саша, элеп киптергәндәй, тагын да агарып, ябыгып калган.

— Нигә болай ябыктың әле син? — дип сорадым мин аннан.

— Аның ашаганнан соң гел эче авырта, Сәгыйт абый, — диде Володя, күзләрен зур ачып. — Төнлә дә йоклый алмый. Авырта, ди, елый. Уң яктан авырта аның эче.

Бу малайның кай җире авыртуын белү һәм дәвалау өчен ревирга җибәрәсе иде дә бит, файдасы булмас шул... Фашистлар балаларны дәвалауны артык эш саныйлар...

— Ә теге «барып чыккан» малайлар юк инде хәзер, Сәгыйт абый!—

диде Володя, кинәт сүзен икенчегә борып. — Аларны, күрәсең, икенче лагерьга күчергәннәрдер.

— Әйе, шулайдыр, икенче лагерьга озаткганнардыр аларны, — дигән булдым мин, аның сүзен җөпләп. — Анда мондагыдан яхшырак булыр аларга.

Бу гөнаһсыз нарасыйга шулай димичә нәрсә әйтәсең? Аның якты уйларын ничек каралтмак кирәк?

— Димәк, аларны крематорийда яндырмаганнар, яхшырак лагерьга гына җибәргәннәр, шулай бит, Сәгыйт абый? — диде Володя. Аннары, миннән җавап көтеп тә тормастан, чын күңеленнән куанып, кәҗә бәтие сыман сикергәләп китеп тә барды. Авыр ботинкаларын лаштырлыштыр сөйрәп, Саша да аның артыннан китте. Чамадан тыш ябыкканга, арттан караганда сиксән яшәр картка охшап калган иде ул. Болай булса аны да тиздән бераү дә кире кайтмый торган «бүтән лагерьга күчерәчәкләр» инде...

Чех врачы Иосиф Галашка ярдәмендә Николай Филиппович Михайловны үнөченче баракка — туберкулез белән авыручылар янына урнаштырдык. Дөрес, анда авыруларны дәваламыйлар. Ашау ягы да бик начар. Аларны бары тик эштән генә азат итәләр. Хәер, Дахау шартларында шунысы да зур нәрсә инде аның...

Ашату дигәннән, ул яктан лагерьда эшләр көннән-көн начарлана бара. Фашистлар Украинадан һәм Белоруссиядән эшелонлап-эшелонлап икмәк, май һәм ит ташый алмыйлар хәзер. Ә үз продуктлары алай мулдан түгел. Менә шул хәл без әсирләр тормышында соңгы айларда аеруча ачык чагыла башлады: икмәкне элеккедән дә күбрәк опилка кушып, баланданы үзган елгы черек кәбестә күчәне салып пешерәләр.

Өченче көн Франциядән ике товар эшелоны килгән иде. Ул эшелоннарда тоткыннар китерелгән икән. Тотен командада эшләүче иптәшләр шул эшелоннардан өч йөз житмеш мәет бушатканнар, ә исән калган мең дүрт йөз утыз өче шундый ябык, хәтта аякларына да басып тора алырлык түгелләр иде, ди. Аларны шундук крематорийга озатканнар...

Тотен командада эшләүчеләр Дахауга тоткыннар алып килгән вагоннарда еш кына итләре ашалып беткән мәет сөякләре була дип сөйлиләр. Минемчә, ышанмаслык нәрсә юк монда. Тоткыннарга, юлда ашарга дип, болай да җан асрарлык кына итеп бирелгән паекларны эшелонны саклап баручы фашистлар аракыга алыштырып бетергәч, унар-унбишәр көн бер тәгам ризык капмыйча бикле вагоннарда барган тоткыннарга мәет ите ашаудан башка ни чара калсын соң?

— Бирәннәр, — ди Франтишек Зупка, нацистларның шушындый кабахәтлекләренә нәфрәтләнеп. — Хәзер алар бөтенләй котырдылар. Гитлер үзенең көннәре санаулы калуын сизенә, һәр совет кешесен политик дошман, коммунист дип исәпләргә куша... Әле күптән түгел генә, — ди Зупка, сүзен дәвам итеп, — миңа фашистларның тагын бер вәхшилеге турында сөйләделәр. Хәтерегездәдер, 1943 елның көзендә әсирләр алмашу турында килешү булып, авыру һәм бик ябыгып эштән чыккан тоткыннарны алмашырга дип каядыр озатканнар иде. Сезнең Стрелков язылырга теләмәгән иде ул чакта. Менә шуларны җыю пунктына хәтле бикле вагоннарда берни ашатмыйча-эчертмичә алып барганнар. Барып җиткәч, вагоннарны ачсалар — барысы да ачтан үлеп беткән, ди. Молодец ул сезнең Стрелков — эшнең ни белән бетәчәген алдан ук сизенгән!

* * *

Һәр көнне йокыдан уяну белән йөрәк сулыгып-сулыгып авырта башлый. Әйтерсең, кемдер аны сөякчел бармаклары белән кыса, туктатырга тели. Көн саен бер-бер куркыныч хәл көтеп, үләмме яки исән ка-

ламмы дип борчылып-куркып яшәгәнгә шулай авырта ул. Үзең исән калсаң да, көн саен синең йөрәгеңне өшетеп, җаныңны тетрәтерлек бер-бер хәл булмыйча калмый монда.

Бүген эштән кайтышлый Кайгородцев һуштан язып егылган. Власкин, Скопкин һәм мин өчебез күтәреп аны ревирга илттек. Анда безне югослав врач кабул итте.

— Дистрофия, — диде ул, Кайгородцевка күз салу белән. — Кискен формадагы дистрофия. Аны бары тик әйбәт ризык һәм ял белән генә дәвалыйлар. Ялын бирербез без аның. Әмма лазарет паегы белән генә рәтләнә алмас ул... Сез аңа нинди дә булса өстәмә ризык таба алырсызмы икән соң?

Кемнең нинди кеше булуын бер күрүдә үк абайлап алырга өйрәнгән инде без. Әле дә шулай булды: «Бу югославка ышанырга була!» дигән нәтиҗәгә килдем мин һәм Кайгородцевка өстәмә ашамлык китереп торачагыбызны әйттем.

— Алайса, бик яхшы! Бик хәлсезләнгән иптәшләрне китергәләгез шулай... Кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышырбыз... — диде югослав.

Без аның белән сөйләшеп торган арада врач Иосиф Галашка әле һаман да аңына килә алмаган полковникның веналарына кан җибәрергә дә өлгергән иде инде. Тагы бераз яткач, Кайгородцев һушына килде, күзләрен ачты.

— Зыян юк. Рәтләнерсез. Бераз госпитальдә ятарсыз. Шикләнмәгез, сезнең дусларыгыз без, — диде аңа Галашка.

Аннары мин Михайлов янына кереп чыгарга рөхсәт сорадым. Ул күрше бүлмәдә генә ята иде. Николай Филиппович бераз рәтләнә төшкән, күңеле дә күтәрелеп киткән. Килеп керүемә миннән лагерьдагы яңалыклар, фронт хәлләре турында сораша башлады. Мин безнең гаскәрләрнең Румыния җиренә барып керүен һәм Бухарестны азат итүен әйткәч, Николай Филиппович шатлыгыннан нишләргә дә белмәде.

— Озакламый сугыш бетә инде болай булгач. Эх, шул көнне тизрәк җиткерәсе иде! — диде ул, күзләрен очкынландырып.

Ревирдан күтәренке күңел белән кайттым. «Шундый каты авыру хәлендәге Николай Филиппович җиңү көнен тизрәк җиткерергә теләп ятканда безгә, әле аякларында торучыларга, ул көнне якынайту өчен бөтен көчебезне куеп тырышырга кирәк!» Менә шул уй канатландырган иде мине.

Буялып-пычранып беткән буй-буй костюм, авыр агач башмак кигән Дахау тоткынының тышкы кыяфәте читтән карап торган кешегә шактый ямьсез тәэсир калдыра. Әгәр инде тоткынның атна-ун көн буена сакал-мыегы да кырылмаган булса — ул бөтенләй күңел кайтаргыч булып күренә. Ә андыйлар шактый күп монда. Чөнки сакал-мыек кырырга пәке юк. Бәхеткә каршы, әле ярый безнең цехта эшләүче украин егете комсомолец Костя Семенов кайдандыр бер лезвие кисәге юнәткән. Аны тимер чыбыктан ясалган тоткычка җайлап куйган. Без барыбыз да шул лезвие белән кырынабыз. Көзге урынына уч төбе кадәрле ялтыравыклы калай кисәге тотабыз. Костя ул лезвиене үзе генә белгән урында яшереп саклый.

Гомумән бик булдыклы һәм тәвәккәл егет ул Костя. Кайвакыт каяндыр берничә бәрәңге табып алып килә. Аны, немецларга сиздермичә генә, цехтагы электр плитәсендә пешереп ала да безнең белән бүлешеп ашый. Александр Семенович Календарев белән аеруча дус алар, һәм күп вакыт әдәбият турында сөйләшеп утыралар. Костяның хәтере яхшы, бик күп язучыларның шигырьләрен яттан белә. Поэзиягә бирелеп китеп, бервакыт коеп яуган яңгыр астында, манма су булып юешләнгәннәрен дә сизмичә, ярты сәгать чамасы сөйләшеп тордылар алар.

* * *

Баланданы, зур-зур бакларга тутырып, бараклар янына алып килеп өләшәләр. Бу эшне башкаручы кешеләрне немецлар кибелькоманда дип атыйлар. Кибелькомандага гадәттә штрафчыларны куялар. Алар, унунике кеше, әлеге зур-зур баклар утыртылган тимер арбага җигелеп, аны барактан баракка тартып йөриләр.

Менә шул кибелькомандада якын көннәрдә генә бер яңа кеше күренә башлады. Озын буйлы, мәһабәт гәүдәле, төскә-биткә алай карт күренмәсә дә, ап-ак чәчле ул кеше күзләренең сәерлеге белән үзенә җәлеп итте мине. Юк, хикмәт аның ул күзләре бераз шешенке һәм яше коелып китәр төсле булып мөлдерәп торуында гына түгел иде. Ничектер, ялангач дип әйтимме, гадәти түгел иде аның күзләре.

Әле кичә кич кенә, баланда өләшкән арада, без аның белән сөйләшеп киттек. Бичара штрафчының кемгә булса да күңелен бушатасы килгән иде, ахры.

— Сез Таҗетдинов түгелме? — дип беренче булып сүз башлады ул. Шунда мин аның күзләрен якыннан күрдем. Аның каш-керфекләре өтелеп беткән һәм шул урыннары кызарып-чиләнеп тора икән ләбаса! Шул сәбәпле миңа теге көнне ничектер сәер булып күренгән икән!

— Мин подполковник Мөҗәһит Хәйретдинов, — диде ул акрын гына.— Ишеткәнегез бардыр, Перлахтан — Дахау филиалыннан — китерделәр монда.

Шунда кылт итеп хәтеремә Иосиф Лаушер сөйләгән вакыйга килеп төште. Июль аенда Перлахтан, Дахаудан һәм Мосбургтан җитмешләп совет офицерын, ярыйсы гына киендереп, каядыр озатканнар дигән иде ул.

Башта бу хәлгә безнең бик эчебез пошкан иде. Фашистларга хезмәткә күчтеләр микәнни, илгә хыянәт иттеләр микәнни, дип аптырашкан идек.

Берничә көннән соң, ниһаять, ул мәсьәлә ачыкланды. — Әлеге җитмеш совет офицерын, — диде Иосиф Лаушер, — Мюнхен гестапосына алып киткән булганнар икән. Шунда җәзалаган вакытта шул җитмеш кешенең икесе үлгән, ә калганнарын Дахауга алып кайтканнар да үлем барагына япканнар. Барысының да хәле бик авыр, ди.

Дахаудагы антифашистик группа турында эсэсчылар берәр нәрсә сизенделәрме икән әллә? Безне әнә шул уй борчый иде... Сизенгәннәр дияр идең — безнең активтан һәм йомышларны үтәп йөрүче ышанычлы кешеләрдән берәүне дә алып китмәделәр... Димәк, ике генә сәбәп кала: я фашистлар, тикшереп-нитеп тормыйча, күзләренә кем чалынса — шуны кулга алганнар, яисә Дахаудагы һәм аның филиалларындагы күп меңләгән совет тоткыннары арасында безнекеннән тыш та антифашистик яшерен оешмалар бар.

Бүген кич безнең баракка Семен Маляров, Геннадий Нуретдинов һәм Николай Матрослар кергән иде. Алар кайбер нәрсәләрне ачыклап та өлгергәннәр икән инде. Теге җитмеш офицерны алып киткән көннәрдә фашистларның әсирләргә начар мөнәсәбәт күрсәтүләренә каршы Совет хөкүмәте биргән нота лагерьда киң таралган иде. Без аны яшерен радио аша язып алган идек. Геннадийларның әйтүенә караганда, гестапочылар офицерлардан шул нота текстының әсирләр кулына кайдан килеп керүен белергә теләгәннәр, Мәскәүнең Дахау лагере белән элемтәсе бармы әллә дип сорашканнар һәм шуны ачыкларга теләгәннәр, имеш...

Җәзалап та җиңә алмагач, гестапочылар гадәттә тоткыннарны шул ук көнне юк итәләр: башта аталар, аннары крематорийда яндыралар иде. Безгә шунысы сәер тоела — нигә гестапочылар бу юлы ул кагыйдәләрен үзгәрттеләр икән?.. Зупка әйтә, бәлки, югарыдан үлем карары

чыгарылганны көтәләрдер, ди. Әмма беребез дә моның сәбәбен төгәен белми. Ни булса да булган — алтмыш сигез офицерны Дахауга кире кайтарганнар һәм азрак кыймылдар чамалары барларын кибелькомандага эшкә дә кушканнар. Мөҗәһит тә шул командага эләккән. Аның белән берничә мәртәбә сөйләштек инде без. Шунда ул миңа фашистлар үзен гестапода бик каты җәзалавы турында да, тормыш юлы хакында да сөйләде. Башкортстанның Төрекмән авылында туган икән ул. Аннары мәдрәсәдә укыган. Бик яшьләй шигырьләр яза башлаган. Аларны Казанда чыга торган газета-журналларда да бастырып килгән. Хәрби училищеда укыган. Аны тәмамлагач, Ерак Көнчыгышта хезмәт иткән. Хасан күле тирәсендәге сугышларда катнашкан. Бөек Ватан сугышында полк командиры булып хезмәт иткән...

Очрашуларыбызның берсендә Мөҗәһит миңа акрын гына менә шушы җырны җырлап бирде:

Здравствуй, женка! Или ты не узнала
Своего сердечного дружка?
Юношей ты меня провожала,
А теперь встречаешь старика!

— Мине җәзалап үтерәчәкләр бит, Сәгыйт, — диде ул аннары. — Бу бераз кичектереп торулары гына... Мин шуны үтенәм синнән, Сәгыйт: сугыштан соң безнең авылга барып, минем хатынны тап та аңа менә шул мин әйткән җырны җырлап күрсәт. Һәм әйт: ирең йөз кызартырлык эш эшләмәде, диген. Җәзалауларына түздем, үлемне дә совет офицеры буларак каршыларммын!

Гестапочылар Мөҗәһитнең керфек һәм кашларын сигарет уты белән өтеп кенә калмаганнар, кыйный-кыйный муенын һәм яңакларын да шештереп-күгәртеп, башын тишкәләп бетергәннәр иде.

— Мине совет хөкүмәте нотасын тоткыннарга аңлатуда гаепләделәр, — диде Мөҗәһит. — Миннән ул нотаны кайдан алуыбызны, немец эшчеләренең кайсылары белән элемтәдә булуымны, нинди яшерен оешмада торганлыгымны әйттермәкче булдылар... Ә башта милли легионга командир булырга кыстап караганнар иде... Беләсеңме син ул нәрсәне?

— Белмимме соң инде, Мөҗәһит! Шауляй һәм Демблин лагерьларында чакта легионга кыстап үземнең каныма тоз салдылар бит минем...

Мөҗәһит белән без бүген дә очраштык.

— Эх, Сәгыйт, һич кенә дә үләсе килми бит, агай-эне! — диде ул, тирән көрсенеп. — Җиңү бик якын бит инде... Ә мин аңарчы яши алмаячакмын! Хәзер менә рәхәтләнеп, җир җимертеп сугышып йөрисе иде дә бит...

— Нигә сез гел үзегезне тиздән үтерәләр дип уйлыйсыз, Мөҗәһит! — дидем мин аңа, үземчә юатырга теләп. — Гестаподан соң ук атмаганнар икән, димәк, бөтенләй атмаскадыр исәпләре.

— Юк, Сәгыйт! Хатын-кыз түгел ләбаса мин, исән калдырмаячакларын бик яхшы белеп торам... Ә бүген шундый куркыныч төш күрдем әле. Иптәшләрем белән карурман эченнән барабыз икән. Урман дөмкараңгы, күңелгә шом салып агачлар шаулый. Һәм шунда кинәт безнең өскә агач артларында посып торган төрле җанварлар ташлана. Зур, кызыл авызын киң итеп ачып, бер озын һәм юан буар елан миңа таба шуыша башлый. Менә ул, килеп җитеп, мине чорнап ала да буарга тотына. Менә бетерә, менә тынсыз итә дигәндә генә уянып киттем...

Шуннан соң ул, гестапода җәзалаган көннәрдә чәче агарып калган башын аска иеп, тынып калды.

Мин һаман да аны юатырга тырышкан булдым:

— Сезне атарга батырчылык итмәсләр алар, Мөҗәһит! Ул заманнар үтте бит инде.

Ишетмәдеме, әллә ишетеп тә, барыбер файдасы булмавын аңлаптырмы — Мөҗәһит минем сүзләремә игътибар итмәде. Сүзсез генә кулымны кысты да, иптәшләре белән баланда арбасына җигелеп, китеп барды.

Исән калдырмасларын белсәм дә, бу очрашуның Мөҗәһит белән соңгы очрашу булырын һич тә башыма китермәгән идем. Хәер, адәм баласы гел шулай оптимист булып, соңгы кечкенә генә ышанычы да беткәнче өмет белән яши бит ул...

Әйе, Мөҗәһитне мин бүтән күреп сөйләшә алмадым. Дүртенче сентябрьдә башта аны атканнар, аннары крематорийда яндырганнар. Берүзен генә түгел, әлбәттә. Барлыгы туксан бер кеше иде алар. Алтмыш сигезе — совет офицерлары, калганнары чит ил тоткыннары.

Крематорийда яндырылган совет офицерлары арасында полковник Тарасов, подполковник Шелест, подполковник Красавецкий, майор Михайлов (Зингер), капитан Громов та бар иде. Дүрт француз полковнигы һәм алты немец офицеры да әлеге анда. Аларны Мосбург концлагерында шактый актив эш алып барган антифашистик яшерен оешмага катнашуда гаепләгәннәр.

Беркөнне радиодан Гитлерга һөҗүм булуын ишеттек. Кызганычка каршы, ул җенле фюрер үлемнән котылып калган икән. Аннары, шул һөҗүмгә ачу итеп, Гитлерның өч йөз җитмеш мең тоткынны юк итәргә дигән приказы чыкты. Ул приказга безнең иптәшләр дә әлеге...

Фашистлар һаман саен котыра, әшәкеләнә бара. Юк кына сәбәп булса да, я эштән чыгарганчы кыйныйлар, яки үтереп, крематорийда яндырырга гына торалар. Ләкин аңа карап безнең яшерен антифашистик группаның эше тукталмый. Киресенчә, көннән-көн җәелә, үсә бара. Чылбыр принцибы буенча эш итә ул. Группа әгъзаларының күбесе үз төркемендәге биш кешене генә белә, ә башкалары, үзләре аерым эш башкаручылар — бары тик бер генә кеше белән таныш. Әйтик, менә пекарняда эшләүче Сергей Горбатенко. Ул бары тик Николай Матрос белән генә элемтә тота: гомерен кыл өстенә куеп, көн саен диярлек аңа бер кирпеч икмәк алып чыгып бирә. Тәмам ябыгып, дистрофия белән авырый башлау чигенә җиткән тоткынарга өстәмә паек итеп бирелә ул икмәк. Әмма оешмага ярдәм итүен Горбатенко үзе белми.

Генерал Тонконоговны таш вату эшендә эшләячәк командага билгеләгәннәр. Бик авыр, каторжаннар эше бит ул. Яков Иванович болай да бик ябык, көчкә атлап йөри. Таш вату — үлем булачак аңа. Менә шуны искә алып, яшерен группа, ничек итеп булса да, Тонконоговны саклап калырга дигән карар чыгарды.

Штубе писаре Юлиус белән сөйләшүнең унай нәтиҗәсе булмады.

— Соң инде! Исемлекләре төзелгән, кул куелган, — диде ул.

Бу эштә безгә ревирда эшләүче австрияле врач ярдәм итәргә булды. Температура күтәрә торган инидидер дару бирде ул һәм шуны Тонконоговка эчерергә кушты...

Яков Ивановичның тәне бик нык кызышып китеп, эсселеге 39 градуска җиткәч:

— Хәзер үк ревирга илтегез үзен! Тиф була күрмәсен! — диде блок башлыгы.

Ә безгә шул гына кирәк тә. Яков Ивановичны тиз генә күтәреп лазаретка илттек. Ул, температурасы нигә югары булуын белсә дә, юлда ыңгырашып барды. Хәле бик начар шул!

Австрияле врач, генералны карагаҗнан соң, йөзенә канәгатьлек билгесе чыгарып, мыгырданып алды. Аннары авыру тарихына латинча нәрсәләр язып куйды да:

— Ун көнләп ятар монда. Житәме шул? — дип сорады.

— Әлбәттә, житә! Таш ватарга барачак этап иртәгә ук озатылачак...

— Ә температурасы өчен борчылмагыз. Хаҗәте бетү белән төшерербез без аны... Зыяны юк аның, — диде врач.

## Ә үлемгә дүрт кенә адым

Сәгать төнге ике яки өч тирәсе булырга кирәк. Мин тыштагы багана башына куелган прожектор яктысына карап ятам. Чәнечкеле тимер чыбыкны шундый шәп яктырта ул — иренмәсәң, нарында яткан килеш тә чәнечке төеннәрен санарга мөмкин! Ләкин ул төеннәр белән мавыгыр вакыт түгел хәзер. Мине башка уй, башка хәсрәт бораулый. Шуңа кичтән бирле күземә йокы кергәне юк... Хәер, бер мин генә түгел, лагерьдагы бик күп тоткыннар йоклый алмыйдыр бүген. Әнә Илларион Андреевич та тирән сулап, көрсенеп куйды. Димәк, ул да йоклый алмый ята...

Юк, йокларга тырышудан мәгънә чыкмас, ахры. Күземне йомдыммы — каршыма киләләр дә басалар. Ә күкрәкләрендә: «Саботаж ясаган өчен асылды», дип язылган такта.

Конвейер сафтан чыгарылганнан соң, лагерьдагы тегү мастерское бер атна чамасы туктап тора. Бу хәлне ишетеп, Мюнхеннан гестапочылар килеп житә, Киселев белән Демусны кулга алалар. Күрәсең, бу ике яшь егет җәзалауга түзә алмаслар, эшне ачып салырлар дип өметләнгәннәрдер алар. Шулай итеп, безнең бөтен антифашистик группаның язмышы кыл өстенә куела...

Әмма әлеге ике яшь офицер берсүз дә әйтмиләр. Калак сөякләрен каертып, терсәкләреннән асып куйгач та, каеш чыбыркы белән кыйнап арка тиреләрен яргалап бетергәч тә, фашистларга берсүз дә әйтмиләр ул геройлар... Аннары фашистлар аларны, күкрәкләренә әлеге такталарны асып, лагерьдагы үзәк капка буена асып куялар...

Алар хәзер дә шунда эленеп торалар әле. Күземне йомсам — шул ике егетнең күгәреп сузылып торган ялан аяклары, каралып-канланып беткән һәм танып булмаслык хәлгә килгән йөзләре күз алдыма килә. Мондый чакта күзгә йокы керәме соң?.. Уйланып ята торгач, үз хисләремне тикшерергә керешәм. Курканмы соң мин? Әйе... Менә шул егетләр кебек асылынып тору куркыныч, әлбәттә... Әллә барысын да ташларгамы? Агитация, саботаж, өстәмә паек белән кешеләрне тәэмин итеп йөрү... Мин боларның берсенә дә мәҗбүри түгел ләбаса!.. Боларны беркем дә кушмый ич... Барысын да ташларга да, ничек итеп булса да җанымны саклап калу өчен, бер почмакка сыенырга, блок башлыгы Францка — «Володя абый»га ярарга тырышып кына яшәргәме?.. Юк! Җаным да тартмый, йөрәгем дә каршы килә моңа. Сүз дә юк, асылган эт кебек баганада эленеп торганчы, сугыш кырында пуля тиеп яки снаряд кыйпылчыгыннан үлүе мең өлеш артык булыр иде... Әмма, ни хәл итмәк кирәк... Асылу хурлыгыннан куркып, кул кушырып утыру үзе хурлык бит ул...

Караңгы күк йөзе акрынлап яктыра, көнчыгыш як аллана башлады инде. Тиздән «подъем» булыр. Безне аппельплацка алып чыгып тезәрләр дә урыннарыбызга алып китәрләр, ә теге ике офицер бүген дә шул капка буенда асылынып торыр...

Николай Хонич — «Чәчле Николай» бүген миңа гадәттән тыш борчулы һәм әллә ничек гаҗәбрәк күренде.

— Карагыз әле, подполковник, — диде ул, тиктомалга мине туктатып, — сез теге асылган егетләрне күрдегезме? Тиздән мин дә шунда эленеп торачакмын...

Николайның күзләре кысылган, йөзенә ачулы елмаю чыккан иде.

— Нинди юк сүз сөйлисең син, Николай? Әле кайчан гына үзең эсэсчы врач гомер бирде миңа дип сөйләгән идең бит!

— Анысы шулай. Әмма мин фашистлар белгертергә теләмәгән бик күп нәрсәләрне беләм бит... Бу турыда беркемгә дә сөйлисем килмәгән иде, — диде Николай, бераз уйланып торганнан соң. — Хәзер инде сөйләсәм дә була. Барыбер үтерәчәкләр инде мине. Беләсезме, Сәгыйт Абдуллович, мин ул чакта шактый озак булдым бит анда... Күпне күрергә, күпне ишетергә һәм күпне кичерергә туры килде... Мине кайнар ваннага салып җылытканнарын әйткән идем инде сезгә. Ә миннән соңгы берәүне, салкында тотканнан соң, хатын-кызлар лагереннан китерелгән бер хатын янына куйдылар. Ул хатын үз тән җылысы белән җылытырга тиеш иде теге кешене. Ул тоткынның аяк-куллары тәмам агарып, туңып беткән иде. Шунда, озак та тормыйча, үлде ул. Ә җылытырга тиешле хатын, моңарчы гомерендә күргәне булмаса да, бик кызганды аны һәм үлгәннән соң да әле шактый вакыт аяк-кулларын угалап, җылытып азапланды... Ә доктор Рашер белән санитар бу хәлне шундый тыныч карап тордылар, әйтерсең, алар каршында кешеләр түгел, бәлки мәче балалары газаплана...

Ә икенче бер көнне тәҗрибә өчен китерелгән минем ише тоткыннарга укол бирделәр. Доктор белән санитар үзләре противогаз киделәр. Аннары доктор әсирләрнең иңбашларына һәм уч төпләренә ниндидер сыекча белән укол ясады. Кулларын алга суздырып, бер сәгать тик кенә бер урында утыртканнан соң, укол ясалган әсирләрне койкаларга яткырдылар. Ә кичкә таба ул әсирләрнең барысының да тәннәре куыкланып кабарып чыкты һәм алар, авыртуга түзә алмыйча, кычкырыша-акырыша башладылар. Ах, аларның ул тавышлары, иптәш подполковник! Әле дә булса колак төбемдә яңгырап тора!.. Иртәгесен аларны рәсемгә төшерергә дип бер офицер килде. Ә алар әле һаман кыргый җанварлар кебек акырышалар — чөнки күзләре сукрайган иде! Төнлә алар янында булган санитар да бөтенләй диярлек сукраеп калган иде... Ул доктор аларга нинди укол ясагандыр һәм аны ни өчен ясагандыр — анысын белмим... Аннары әлеге ярым сукыр санитар миңа бер кеше сөяген икенче кешегә күчереп утырту буенча хатын-кызлар тәнендә ясалган операцияләр төшерелгән күп кенә рәсемнәрне күрсәтте. Алар арасында арка миләрен, женси органнарны кисеп алган вакытларда төшерелгән рәсемнәр дә бар иде...

Мин Хоничны шуннан ары тыңлый алмадым, янышнан китәргә мәҗбүр булдым. Аның нурсызланып тилереп калган күзләренә карап тору мөмкин түгел иде, чөнки ул сөйләгәннәр барысы да дөрес... Дөрес һәм адәм акылына сыймаслык хәлләр иде...

Ярый әле бу көннәрдә радио шатлыклы, күңел күтәргеч әйбәт хәбәрләр китереп тора (24 августта Румыния Германиягә каршы сугыш игълан иткән, 31 августта Белоруссия фронты гаскәрләре Көнчыгыш Пруссия чигенә килеп җиткәннәр), югыйсә Николайның бу сүзләреннән соң акылдан язуың мөмкин иде...

Соңгы вакытта лагерьдагы эсэсчылар да шактый үзгәрә башладылар. Бигрәк тә бу үзгәреш берәр гаеп аркасында монда эшкә китерелгәннәрендә сизелә. Әйтик, кичә генә блокта башлык булып торучы Франц — элекке эсэсчы офицер — безнең белән гомер булмаганча ачылып китеп сөйләште.

Без Стрелков белән икәү аскы нарларда сөйләшеп ята идек, тирәбездә бераз әйләнгәләп йөргәннән соң, Франц та янybызга килеп утырды:

— Әйе, тоткынлык — шәп эш түгел икән! — диде ул, нигәдер үзен дә тоткынга санап, һәм авыр сулап куйды.

— Сезгә нәрсә ул? Минә безне әйтсәң дә ярый иимаса! Күпме эш-

ләсәк тә, шул сыек баландадан һәм кимсетелүдән башка, рәхмәт тә ишеткән юк, — дидем мин.

Франц шактый вакыт эндәшми торды. Аннары бары безгә генә ишетелерлек итеп (эсэсчы коллегалары ишетсә — харап) сайрарга кереште:

— Юк, сезнең белән килешмим мин... Сез Россиягә — өйләрегезгә кайтырсыз... Чыдам, нык кешеләр сез... бик нык кешеләр... Ә мин андый түгел... Миңа бик начар булачак. Сугыш бетәр... Фюрер миңа ышанмас һәм янадан лагерьга озатыр.

— Сугыш кем файдасына бетәр бит әле, — диде Стрелков, сүз арасында гына әйткәндәй итеп.

Арнецларча аксыл-саргылт йөзле Франц тагын уйга чумып, тынып калды. Чыннан да, аның хәле шәптән түгел шул. Германия җиңсә дә, штрафчы буларак, аны лагерьда калдырачаклар, без җиңсәк тә — башыннан сыйпамаячакбыз...

* * *

Вакыт никадәр акрын узган кебек тоелмасын, көннәр һаман үтә тора. Инде менә 1944 елның көзе дә килеп җитте. Яңгырлар да еш яугалый хәзер. Болай да боек күңелләрне көзге яңгырлы һәм салкын көннәр тагы да боектыра төшә.

Әле шушы көннәрдә генә Дахауга китерелгән кешеләрнең берсе элек полицай булганлыгы ачыкланды. Шул ук төнне аңа суд та ясалды. Полицай: «Мине куркыттылар, мәҗбүр иттеләр, мин беркемне дә рәнҗетмәдем», — дип акланырга тырышып караса да, аның белән озак сөйләшеп тормадылар.

— Инде син бер тапкыр сатылган икәнсең, икенче тапкыр сатылырга һәм башкаларны сатарга да күп сорап тормассың! — дип бик тиз эшен бетерделәр. Башкача мөмкин түгел иде. Хәзер, яшерен оешма эшләп торган вакытта, андый типлар бик куркыныч безнең өчен. Башта юхаланып йөргән булалар, соңыннан тоталар да саталар сине алар.

Фронтта хәлләрнең кай якка үзгәрә баруын чамалап, илгә хыянәт иткән бәндәләр хәзер эзләрен югалтырга тырыша башладылар. Бер лагерьда берәр гаеп эшлиләр дә башка лагерьга китеп ычкыну ягын чамалыйлар. Шул рәвешчә үзләрен фашизм корбанына әверелдермәкче алар. Ихтимал, тоткыннарның берсе танып алмаган булса, Киев тирәсендәге бер авылда полицай булып торган теге адәм актыгы да шулай иткән булыр иде.

Аны үлемгә хөкем иттеләр. Һәм төнлә бу хөкем җиренә җиткерелде. Шикле тавыш ишетеп килеп чыккан һәм бу эшне күреп алган блок башлыгына, күршесенең икмәген урлаган өчен үтердек без аны, диделәр.

Ул полицайны хөкем итүчеләрнең берсе — Вәли Бикташев иде. Татар егете Вәли Бикташев — элек ротада замполит булып хезмәт иткән кеше. Ләкин лагерьда аны күбрәк Виктор Максимович дип йөриләр иде. Әле шушы араларда гына шул ук Вәли Александр Крапивныйга әверелде. Бик үткен һәм тәвәккәл ул егет Дахауга килеп капканчы берничә лагерьдан качарга өлгергән инде. Әнә шул качуларының берсеннән соң үзен Виктор дип йөртә башлаган. Дахау концлагерына эләгүе дә качуы аркасында булган хәл инде. Ә ике-өч кенә атна элек Вәли моннан да ычкынмакчы булган: сентябрь башларында йөзләп тоткынны Дахаудан Альп буендагы Котерн дигән бер кечерәк шәһәргә бараклар төзергә җибәргәннәр иде. Вәли дә шул йөз кеше арасына эләккән. Котернда аларны биек таш койма белән әйләндереп алынган бер завод бинасының икенче катына урнаштырганнар. Завод үзе Альп тавыннан ага торган бер елга буена салынган икән. Вәли Бикташев үзе кебек ике яшь офицер (Геннадий Гусев һәм Леонид Рядченко) белән менә шул елгага сикереп төшеп качмакчы булган.

Койма буендагы бәдрәф тәрәзәсенә куелган рәшәткә тимерен алар, кача-поса, аз-азлап уңдүрт көн буена игәгәннәр. Аннары, ниһаять, тәрәзәне ачкач, ноябрьның береннән икесенә каршы төндә качарга булганнар. Башта, кем качарга тиеш икәнлеген ачыклау өчен, жирәбә салганнар. Жирәбә буенча иң элек тәрәзәдән Рядченко чыгарга тиеш булган. Төн уртасы җиткәч, алдан әзерләгән бауларны алып, Рядченко бәдрәфкә киткән. Аның артыннан Бикташев та чыккан. Ләкин... Леонид җиргә сикереп төшәргә дә өлгерми кала — аткан тавыш яңгырый. Шунлук фашистлар тревога күтәрәләр һәм...

Комендант ярдәмчесенең әйбәт кенә кәефләнеп «төнге мәҗлестән» кайтып килгән вакыты булган, Рядченконы ул атып үтергән. Ә Бикташев бәдрәфтән чабып чыгып барганда коридорда сакчыга юлыккан.

— Ят! — дип кычкырган аңа сакчы һәм венкелендәге номерын килеп караган.

Аннары Леонидның үле гәүдәсен дә алып кергәннәр. Комендант эсэсчы солдатларны чакыртып китергән һәм тоткыннарны кыйный-кыйный допрос алырга керешкән...

Монда, Дахауда, хәзер Вәли белән гестапочылар шөгыльләнергә тиеш. Алар Котерннан аның «эше» килеп житүен генә көтеп торалар. Ә ул «эш» килгәч, гестапочылар Рядченко качкан вакытта Вәлинең бәдрәфтә булганлыгын бик тиз белеп алачаклар... Ни булыр икән инде аңа?.. Рядченкодан башка тагын кемнәр качарга җыенган булуын, тәрәзәдәге тимер рәшәткәне кемнәр игәгәнлекне, ул игәүне кайдан һәм кем алганлыкны сораштырып, аны тәмам интектереп бетерерләр дә соңыннан асарлар.

Ә аны коткарырга кирәк. Ничек булса да йолып калырга кирәк Вәлине. Безнең комитет бертавыштан шул фикергә килде һәм аны тормышка ашыру чарасына керեште. Бу юлы да безгә теләктәшлек күрсәтүче чит ил тоткыннарына мөрәҗәгать итәргә туры килде. Алдан сөйләшкәнчә, блокшрайбер Бикташевны ревирга немец врачына күрсәтергә алып барды.

— Киемнәрегезне алыштырыгыз. Менә бу чисталарын киегез,— дип, врач Вәлигә бүтән киемнәр бирде. Ул киемнәргә 50211 номерлы венкель беркетелгән иде.

— Бу Александр Михайлович Крапивный киемнәре, — диде аннары врач. — Ул юк инде, үлде... Хәзер сез аның исем-фамилиясе белән йөриячәксез... Номеры да сезнеке булыр. Ә үзегезне бүген «акт» белән списать итәбез. Дизентериядән үлде диярбез. Крапивный бездә операция һәм мәет бүлмәләрен җыештыручы булып эшләгән иде. Хәзергә аның вазифасын башкара торырсыз... Ә аннары күз күрер...

Ун көнләп ятканнан соң, Вәли «терелеп» ревирдан чыкты һәм безнең антифашистик группаның иң актив членнарыннан берсе булып китте.

* * *

Соңгы көннәрдә тоткыннар арасында, бигрәк тә немец һәм австриялеләр баракларында, кичләрен кызу-кызу бәхәсләр була башлады. Хикмәт шунда: Совет Армиясенең бик тиз һөҗүм итеп, немец солдатларын күпләп-күпләп «казаннарга» тутырып килүе фашистларның бөтен картасын бутап, планнарын җимереп ташлаган иде. Аптырагач, сугышырга кешеләре житмәгәч, чәчләре агарган немец картларын һәм әле мыек та чыкмаган яшүсмерләрне армиягә ала башлаганнар иде. Шул көннәрдә генә Гитлер үзе, немец һәм австрияле политик тоткыннарга мөрәҗәгать итеп, аларны үз теләкләре белән солдат хезмәтенә сугышка барырга өндәгән һәм армиягә барган кешеләрнең «гөнаһ»ларын кичерергә вәгъдә иткән иде.

Тоткыннар менә шул хакта бәхәсләшәләр. Гитлер өндәмәсенә риза булганнары болай диләр:

— Әгәр мәсьәләгә теоретик яктан килеп карасак, без ризалык бирергә тиешбез. Беренче империалистик сугыш елларында большевиклар тактикасын гына хәтерләгез: патша армиясен эченнән таркату өчен, алар шул армиядә хезмәт итәргә булдылар түгелме? Без дә армияне эчтән таркатырбыз да соңыннан совет гаскәрләре ягына чыгарбыз.

Ә икенче берәүләре, тарихка кереп тормастан, ачыктан-ачык:

— Монда, ач килеш, фронтка китмәгән өчен кайчан тотып атарлар икән дип көтеп ятканчы, алдан ук ризалык бирергә кирәк. Кулыбызга корал алгач, күз күрер әле, — диләр.

Әмма без, рус коммунистлары, бу фикерләргә каршы. Бу очракта большевикларның ул заманда патша армиясендә хезмәт итүләрен мисалга китерүнең нигезе юклыгын аңлатырга тырышабыз. Ул чакта солдат һәм офицерларның коммунистмы-түгелме икәнен белмиләр иде бит, шуңа күрә алар армияне таркату турында агитация алып бара алдылар, ә сезне бик яхшы беләләр, сез аерым исәптә булачаксыз. Һәм телгә алып әйтерлек файдалы эш эшли алмаячаксыз, дибез аларга. Аннары сезне көнбатыш фронтка — руслар ягына чыгарлык җиргә кем җибәрсен? Тоткын коммунистларны, мөгаен, италия фронтына җибәрә торганнардыр, дибез. Аннары шуны да истән чыгармагыз: сезнең ризалык бирүегез фашистларга бик зур козырь булачак, Рейх өчен кыен көннәрдә сыйнфый көрәш онытылып торырга тиеш, чөнки әнә коммунистлар да ватанны яклаучылар сафына бастылар дип, бөтен Германиягә шаулаячаклар, дибез...

Ләкин без ничек кенә тырышсак та, немец һәм австрияле коммунистларның фашистлар кармагына чиерткәннәре дә булды. Без аларны бик кызганып озатып калдык. Хәер, аркаларына «Дахау» дип язылган киемнәр кидерә башлагач, алар үзләре дә эшне аңладылар аңлавын, тик соң иде инде...

Безнең сүз дөрескә чыкты. Киткәннәренә ике-өч атна үтте дигәндә, ул «патриотлар»ның күбесе, яраланып һәм гарипләнеп, яңадан Дахаудагы ревирга кайтарылдылар. Немец командованиесе аларга шулкадәр шикләнеп карый, хәтта хәрби госпитальгә салырга да батырчылык итми икән!

Яраланып кайткан «патриотлар» башта ук безнең сүзне тыңламауларына үкенеп бетә алмыйлар иде хәзер. Чөнки аларның кайберләрен хәтта палач итеп тә файдаланган фашистлар: кулларына төшкән француз һәм югослав коммунистларын, партизаннарны атарга мәҗбүр иткәннәр.

Нужа күрми — акыл керми ата балаларына, дип җырлый халык. Рус коммунистларының хаклы булуын, вакыйгаларга дөрес бәя бирә белүен раслаган бу хәлдән соң, тоткыннар арасында безнең авторитет тагы да үсеп китте, алар безгә күбрәк ышана башладылар.

* * *

Альп тауларының карлы түбәсе күк гөмбәзен терәтеп торган төсле, ә тау буйларын куксел томан каплаган. Агачлар, кызгылт-сары киемнәрен салып, ялангачланып калган. Ботакларын җил селкеткәнгә, алар көзге салкыннан туңып калтырыйлар кебек тоела. Юеш, салкын һәм күңелсез вакыт хәзер. Шунлыктан йөрәктәге сагыш тагын көчәеп, төен булып тамак төпләренә утыра...

Кичә кич безнең баракка Володя килеп керде.

— Ә Саша кайда соң? — дидем мин, аның үзе генә булуына сәерсенеп. Соңгы айларда алар гел бергә йөриләр иде һәм без шуңа күнегеп беткән идек инде.

Володя күзләрен тутырып миңа карады да елап җибәрде.

— Саша авырган иде, Сәгыйть абый, — диде ул, яшьләрен сөртә-сөртә. — Өченче көн ревирга салганнар иде. Ә бүген аны күрергә дип ревирга баргач, санитар әйтте: «Нинди малай ул? Монда Саша исемле малайның булганы юк! Монда бернинди малайның да булганы юк?» — диде... Кая куйдылар икән аны, Сәгыйть абый?

Мин, барак артык салкын булмаса да, туңып, калтыранып торган бу ябык малайның аркасыннан сөеп, үземчә юаткан булдым:

— Елама, Владимир! Тиздән бетәр бу кыенлыклар. Барысына да чик куелыр! Ишеткәнсеңдер, безнең самолетлар Мюнхенны нинди шәп итеп бомбага тоттылар. Тагын берничә ай гына түзәсе калды инде, аннары барысы өчен дә үч алырбыз әле фашистлардан... Саша өчен дә үч алырбыз... Ә син нык бул... күңеленне төшермә... Без җиңәчәкбез, тиздән җиңәчәкбез, Владимир! Түз, энем, түз тагын азрак... — дидем.

Дахауда тагын бер куркыныч хәл туды — тиф авыруы башланды! Йогышлы авырулар барагыннан көн саен уннарча мәет алып чыгалар...

Мин бу авыруның кинәт болай котырып китүенә нигәдер шикләнә башладым. Һәм безнең яклы санитар Мехлис нәрсә әйтер икән дип, аның янына сорашырга бардым.

— Соңгы ике көн эчендә генә дә унсигез санитардан нибары бишәү калдык, — диде Мехлис, хәлсезлектән ишек янагына сөялеп. — Руслар аеруча күп үлә.

— Соң әле күптән түгел генә берни юк иде ләбаса! Һәрвакыт дезинфекцияләп, «бет үтерү» көннәре ясап торалар иде.

Мехлис кесәсеннән сигарет алып кабызды. Аның ул «эрзац» сигаретыннан күгәргән салам исләре килә. Ләкин Мехлис аңа әһәмият итми иде. Киресенчә, ләззәтләнеп, тәмен белеп, рәттән берничә тапкыр суырды.

— Тиф ул — башлавы җиңел, бетерүе кыен авыру, — диде аннары. — Асу, ату, үзегез дә аңлыйсыздыр, шактый четерекле мәсьәләгә әйләнеп бара хәзер... Заманалар бүтән чөнки. Эшләре начарга баруын чамалыйлар фашистлар... Барысы өчен дә җавап бирергә туры киләчәген аңлыйлар... Ә тиф? Тиф, алла биргән авыру дигәндәй, табигый стихия ул! Аның өчен җавап бирәсе юк. Аннары, аны тарату да бик ансат — бөтен лагерьга унлап тиф бете җитә...

Менә хикмәт кайда икән! Шикләнгән идем шул... Ай-яй-яй! Нинди вәхшилек, ә?!.. Әлбәттә, тиф дар агачы түгел инде. Әмма үтерү, нинди юл белән генә эшләнсә дә, шул үтерү булып кала ләбаса!

Мехлисның озак сөйләшеп торырга вакыты юк иде, ул авырулар янына китеп барды. Мин аның артыннан сокланып карап калдым. Гаҗәеп әйбәт күңелле, үз-үзен аямыйча, башкалар өчен тырыша торган бер кеше ул! Тоткынлыкка эләккәнче дә санитар булып эшләгән икән, монда да үзе теләп шул яраткан эшенә урнашкан. Көн дими, төн дими — һаман авырулар янында. Үзе тәмам ябыгып беткән инде, ләкин сукранганын бер дә ишетмәссең...

Элекке батальон комиссары Артем Марценюк лагерьдагы мебель фабрикасында электриклар бригадасында эшли. Дөрес, бу өлкәдә белеме бик чамалы аның. Шулай да безнең группа аны нәкъ шул эшкә урнаштыруны кирәк тапты, чөнки ул, электрик буларак, фабрикадагы барлык цехларга да кереп йөри алачак иде.

Ә Артем булган җирдә эш пешә инде! Электрик булып эшли башлау белән үк, Марценюк ышанычлы дуслар табып та өлгерде. Михаил Сидоренков, Константин Медведев һәм Николай Литвиненколар белән аеруча дуслашып китте ул. Һәм, алар белән бергәләп, саботаж оештыру эшен шактый уңышлы үти башлады. Әйтик, узган җәй фабрикага утыз машина китергәннәр иде. Өч атна эчендә ул машиналар ремонтла-

нып бетәргә тиеш иде. Өч атна түгел, биш ай үтте инде, ләкин ул машиналарның һаман ремонтланып бетә алганнары юк: әле бер деталь, әле икенче кирәк әйбер «житми»!

Артем кичә тагын эштән күтәренке күңел белән кайтып керде. Фабриканың слесарьлар цехында эшләүче австриялеләр, чехлар һәм немецлар соңгы өч ай эчендә ясаган бракларын исәпләп караганнар: ике йөз табак калайны, йөз метрдан артык тимерне, ике ящик болтны бракка чыгарып һәм «югалтып» бетергәннәр! Артемның шуңа бик кәефе килеп кайткан иде. Бер Артем гына түгел, барыбыз өчен дә куанычлы хәл иде бу. Һәм шуның белән бергә бик хәтәр дә. Мондый эшне сизсәләр... Әмма тоткыннарның фашистларга нәфрәте шул кадәр зур — алар бернидән дә куркып тормыйлар! Һәркайсы фашизмны җиңүгә аз булса да көчен бирергә тырыша. Дахауда атыш тавышлары да, сугыш кырындагыча, дары төтене исе дә юк, ләкин монда да каты көрәш бара!

Латиф-задә шул кызу канлылыгы аркасында тагын берәр ярамаган нәрсә эшләп ташлаган, күрәсең — бу көннәрдә гестапочылар аның белән кызыксына башладылар. Допроска да чакырттылар, куркытып та караганнар.

Гестапо тотынса — хәерлегә булмый инде. Тизрәк, берәр чарасын табып, Латифка ярдәм итәсе иде бит. Тик ничек ярдәм итәргә соң? Номерын һәм фамилиясен алмаштырыргамы? Моның өчен аны ревирга урнаштырырга кирәк бит. Һәм бик тиз урнаштырырга кирәк... Гестапочылар андый эшне озакка сузмыйлар... Эх, Тәуфикъ, Тәуфикъ! Ник болай кызу канлы булдың соң?

...Кар шундый күп ява, әйтерсең, аны күктән капчыклап коеп торалар.

Без, суыктан бөрешеп, аппельплацта тезелеп торабыз. Бүген конвойчыларның кәефләре башка көннәрдәгедән дә начаррак: таң атар-атмаста, өстәвенә ишелеп кар явып торганда, тоткыннарны барлап чыгу шактый кыен аларга.

Барлау беткәч, Семенны күреп, аңа тиз генә Тәуфикъ турында әйттем. Ул кичен ревирга барырга һәм Тәуфикъны «үтереп» тору хакында Иосиф Галашка белән сөйләшеп карарга булды.

Кар яуганлыктан, мастерской эче караңгы. Шуңа күрә без бүген көндез дә лампочка яктысында эшлибез. Ул лампочкалардан төшкән үг яктысы, бинокль линзаларында чагылып, күзләрне камаштыра. Медведев (ул да хәзер безнең цехта эшли )ераклык үлчәгечне юри яхшылап жыя белмәгәнгә салыша, әледән-әле пыялаларын «ялгыш» идәнгә төшереп җибәрә.

— Ревирда эш барып чыкмаса, ни эшләрбез икән?— ди ул, Тәуфикъ турында баягы сөйләшүгә яңадан кайтып.

Мин аңа ни дип җавап бирергә дә белмим. Ул турыда хәтта уйларга да куркам. Бердәнбер ышанычлы чара венкелен алыштыру инде. Аннары тагын, Дахау филиалларының берсенә җибәрергә мөмкин. Ләкин анысын эшләр өчен шактый вакыт кирәк булачак. Вакыт дигәнең бик аз шул хәзер! Бөтенләй юк диярлек!

Шушындый чакта үзеңнең көчсезлегеңне күреп-белеп торудан да кыен хәл бармы икән?..

Ниһаять, зарыгып көткән кич тә җитте. Без эштән кайтканда кар туктаган, күк йөзе аязып калган иде. Саргылт ай нурында кар бөртекләре җемелдәшеп, болай да арыган күзләрне камаштыра.

Кичке барлауга аппельплацка җыелгач, мин Маляровны караштыра башладым. Бүген кич үк врачлар белән Тәуфикъ мәсьәләсендә сөйләшеп карау турында аңа тагын бер кат искәртеп куймакчы идем. Шунда кемдер терсәгемнән тотты. Әйләнеп карасам — Лунгинс икән.

— Исәнме, Сәгыйт? — диде ул. Йөзе борчулы иде. — Кыен булса да, сиңа берьюлы ике күңелсез хәбәр әйтергә тиешмен, Сәгыйт, — диде аннары, бераз сүзсез торгач. — Иртәнге барлаудан соң Латиф-задәне каядыр алып киткәннәр бит! Шул китүдән бирле блокка кайтканы юк, ди. Мин әле яна гына шунда кереп чыккан идем. Бәлки допростадыр, ә? Әһә, туктап тор әле! Әнә теге иптәштән сорыйм әле.

Лунгинс шулай диде дә, меңләгән халык арасына кереп, юкка да чыкты.

— Ишеттегезме, Александр Семенович? — дидем мин шул тирәдә басып торган Календаревка.

— Ишеттем, Сәгыйт Абдуллович. Фашистлар бездән житезрәк булып чыктылар шул.

Күңел әрнүенә һич чик-чама юк! Әйтеп тә, сөйләп тә бетерә торган түгел.

Озакламый Лунгинс та әйләнеп килеп житте.

— Я, ничек, иптәш Лунгинс?

— Эшләр шәп түгел, Сәгыйт: Латифны штраф режимындагы лагерьга җибәргәннәр. Ә аннан?.. Гадәттә анда эләккән кешеләр кире кайтмый инде... Хәер, хәзер узган елгыга караганда башкачарак эшләнә бугай...

— Вас гибтс[1]? — дип кычкырды шул чак рапортфюрер. — Аллес ауф ди блоке[2]!

— Иртәгә «Ирек урамы»нда очрашырбыз, — диде Лунгинс пышылдап кына һәм кулын болгап саубуллашты да китеп барды.

Никадәр сыек булса да, ул кичне тамагымнан баланда да үтмәде. Латифның бушап калган нарына карагач, йөрәк ярылып киткәндәй булып, сулыгып-сулыгып сызлый, тын кысыла иде. Андый чакта тамакка ризык үтәме соң?..

Лунгинс тагы нинди яңалык әйтмәкче иде икән соң?..

* * *

Төнлә тагын бик күп кар яуган. «Кар командасы» күптән эшкә керешкән инде. Лагерь администрациясе ишек алдында көртләр өелеп торганны яратмый. Тоткыннар карны башта йөк машиналарына төйиләр. Ләкин ул машиналар ватык, моторлары кабына торган түгел. Шуңлыктан тоткыннар аларны үзләре жигелеп тартып йөриләр. Коллар хезмәте белән заман техникасын шушылай килештерүне бары тик фашистлар башы гына уйлап табарга мөмкин.

Мин акрын гына атлап «Ирек урамы» буйлап киләм. Лунгинсны көтеп иртүк «йөрергә чыккан» кеше мин. Кичә нәрсә әйтмәкче булган иде икән соң ул?.. Бүген төн буе диярлек Тәүфикъ турында уйланып яттым. Фашистлар милли легионга кыстаган вакытларда бергәләп күпме кыенлыклар күргән, күпме сөйләшкән, серләшкән һәм бер-беребезне юатышкан идек без!..

Әнә Навара да килә. Бүген аеруча картаеп, ябыгып киткән кебек. Аяк атлаулары да гадәттәгеләп авыррак, салмаграк шикелле. Хәер, шулай булмый хәле дә юк: безгә — яшьрәк, көчлерәк кешеләргә дә бик кыен бу Дахау лагеренда, ул карт кешегә тагын да авыррак лабаса!

— Исәнмесез һәм хушыгыз, Сәгыйт! — диде Лунгинс карт, яныма килеп житү белән. — Берничә сәгатьтән Дахаудан китәм мин.

— Ничек алай? Кая китәсез?

— Мине каядыр Гамбург тирәсендәге лагерьга күчерәләр. Безнең кечкенә фюрерлар мине монда артык озак утыра дигән карарга килгән-

---

[1] Вас гибтс — ни бар анда?

[2] Аллес ауф ди блоке — барыгыз да блокларга!

нәр. Тоткыннарны, колодадагы карталарны буташтырган кебек, күчереп йөртәләр бит алар.

Башта мин бу хәбәргә ышанмыйчарак тордым. Безнең яшерен оешмага һәрвакыт ярдәм итеп торган шушы кешелекле карт белән аерылышуны һич тә күз алдыма китерә алмадым. Күпме яхшы киңәшләр, Дахау турында, андагы тәртипләр турында никадәр мәгълүматлар биргән кеше бит ул! Дөрес, бертуган Лаушерлар, Климент Густаф һәм Зупка кебек чит ил тоткыннары да безнең оешмага күп ярдәм иттеләр. Әмма Лунгинс конкрет киңәшләре һәм практик эшләре белән барысыннан да күбрәк ярдәм итте дисәм — бер дә хата булмас.

— Исәнлектә күрешик дип әйтмим сезгә, Сәгыйт, «хушыгыз» дим, чөнки бүтән очрашмабыз дип куркам. Беләм, сез әле озак яшәрсез. Илегезгә кайта алырсыз, Лунгинс картны искә алгалагыз. Барыбыз да бер эш өчен көрәштек бит без...

Шушы сүзләрне әйткәннән соң Навара чын күңеленнән минем кулны кысты да, китәргә әзерләнеп:

— Иосиф Лаушер белән Зупканы да күчерәләр. Аларны Маутхаузенга җибәрәләр бугай, — диде.

Аның бу хәбәре мине тәмам телсез калдырды... Димәк, болай булгач, фашистлар чынлап торып активны таркатмакчылар икән. Кара син аларның әшәкелекләрен: бертуган Лаушерларны аерып, бер сугуда ике кешенең башын түндермәкче булалар бит. Алар монда кайгы-хәсрәтләрен бергә уртаклашалар, үзара сөйләшеп булса да, юаналар иде, ичмаса. Ә хәзер... лагерьдагы кыенлыклардан тыш, бер-бере турында уйлап, бер-берсе өчен кайгырып та интегергә туры киләчәк ләбаса аларга!

Әйе, фашистлар Каршылык хәрәкәтен таркатмакчы, аны җитәкчеләрсез калдырмакчы булалар. Шуңа «шикле» тоткыннарны төрле лагерьларга таратырга керешкәннәр алар. Ләкин мондый тоткыннарны лагерьлардан лагерьга күчереп йөртү — кабынган янгынны сүндерү булмаячак бит, чөнки ул төрле урыннарга ташланган «очкыннар» ялкынга әйләнеп, яңа, тагын да зуррак янгыннар кабынып китүе мөмкин... Мөмкин генә түгел, шулай булачак ул! Лунгинс, Зупка кебек кешеләр икенче лагерьга күчү белән кул кушырып утырырлар дисеңме?

* * *

Бик сагынам һәм бик юксынам мин Лунгинсны! Тоткынлыкта яши башлаганнан бирле бары ике кешене генә шушылай чын күңелдән хөрмәт итеп яраттым мин. Берсе — Иван Андреевич Пресняков, икенчесе — Навара Лунгинс иде. Баштарак Иван Андреевичтан башка беркөн дә яши алмам кебек тоелса да, соңыннан, вакытлар үтү белән, аңардан аерылу хәсрәте кими төшкән иде инде. Ә Лунгинс белән күптән түгел генә аерылыштык шул без... Аның акыллы зәңгәр күзләре, Тельман турында, властька килгәннән соң фашистларның коммунистларны ничек юк итүләре турында сөйләгәннәре бик еш исемә төшә...

Бүген иртән дә Николай Хоничны күргәч, (ул үзен кулга алган, яхрысы, хәзер иплэп кенә сөйләшә, сүзләрендә дә өметсезлек сизелми) Навараның «шайтан арбасы» турындагы сүзләре хәтергә килде. Тоткыннар 1942 елда Дахау лагеренда көпчәкле зур тимер ящикны шулай дип атаганнар. Чынлыкта исә ул күчмә лаборатория — барокамера булган. Тоткыннарны шул барокамерага кертеп, адәм баласының һавасы сирәкләнгән урында үзен ничек хис итүен белү өчен, тәҗрибәләр ясаганнар. Ул тәҗрибәләрне биеклек медицинасы буенча зур белгеч — врач ясый торган булган. Ихтимал, ул бу тәҗрибәләре белән немец очучыларының самолетта нинди биеклеккә очып менә алуларын белергә теләгәндер. Белә алганмы, юкмы — анысын Лунгинс төгәл генә әйтә

алмады. Әмма әлеге барокамерада 1942 елда гына да сиксән тоткынның һава җитмәүдән буылып үлүләрен бик яхшы белә иде ул.

Мена шушы хәлне сөйләгәч, байтак кына уйланып торганнан сон:

— Шундый вәхшиләрчә экспериментлар ясый торган милләт кешесе булуым өчен кайчакта үз-үземне каһәрлим мин, Сәгыйт! — дигән иде Лунгинс.

* * *

Элек вакытны үткәрә алмый интегә торган идек. Лагерь тормышының бер көне елга тиң иде. Ә хәзер вакыт шундый тиз үтә, бер-бер артлы булып торган яңалыкларны белеп барырга да чак өлгерәбез. Әле яңа гына 1945 елны каршылаган идек, инде менә январь ае да узып китте. Бу айда Украина һәм Белоруссия фронтлары, дошманны кысрыклый килеп, Варшаваны азат иттеләр. Мондагы поляклар шатлыкларыннан нишләргә дә белмәделәр. Алар белән бергә без дә куандык.

Узган якшәмбедә, гадәттәгечә, Дахау филиалларыннан иптәшләр килгән иде. Алар әйтә: берничә бригаданы Мюнхенга бомбага тотылган урамнарны җимерекләрдән арындырырга җибәрделәр. Мюнхенның кайбер урыннары кварталы-кварталы белән туздырылып ташланган, диләр. Бомбага тоту вакытында подвалларга качкан ике меңләп кеше шунда күмелеп калган, имеш.

Нишлисең бит, «Кылыч күтәреп килгән — кылычтан үлгән», ди халык. Моңа без гаепле түгел. Бик гадел үч алу. Һәм бу — башы гына әле!

Заманында национал-шовинизмның агулы кара еланы нәкъ әнә шул Мюнхен сыраханәләреннән баш калкытып чыккан һәм Европа буйлап агуын чәчеп шуышып киткән иде бит. Бөеклек чире кагылган ефрейтор Шикльгрубер да үзенең истерик ораторлыгын шул ук Мюнхенда башлап җибәргән иде. Хәзер ул ефрейторны халык Адольф Гитлер буларак белә. Белә һәм каһәрли-каргый аны.

Бүген лагерьда гомердә булмаган бер җанлылык, шау-шу хөкем сөрде. Хикмәт шунда: безнең баракларны җимерердәй итеп, иртән һава бик нык гүләп торды. Мюнхен ягына очып баручы безнең самолетлар тавышы иде бу. Кимендә биш йөзләп булгандыр алар.

Күкләрне-җирләрне тетрәтеп гүләп барган самолетлар тавышына без дә урамга чыктык. Менә самолетлар төркеменнән берсе кинәт калтыранып куйды һәм чайкала-чайкала аска төшеп китте. Аңа немец зенитчылары атты булса кирәк. Белмим, ничек сикереп калырга өлгергәннәр, самолет күздән югалуга, күктә бер парашютчы күренде. Парашютын җил безнең якка куганлыктан, ул һаман якыная барды һәм берничә минуттан нәкъ лагерьдагы эш зонасына — цехлар арасына килеп төште.

Тоткыннар аны шундук сырып алдылар. Мин көч-хәл белән түгәрәк эченә килеп кергәндә, парашютчы парашютыннан арынып беткән һәм буй-буй сызыклы тоткыннар костюмы кигән, сөяк белән тиредән генә калган тоткыннарга сәерсенеп карап тора иде. Шул чак ике эсэсчы халыкны ырып-ерып очучы янына килеп керделәр. Аларны күргә, очучы кулын кесәсенә тыкты. Без барыбыз да алга калкынып куйдык — атар микәнни? Юк. Очучы кесәсеннән пистолет түгел, портсигар чыгарды һәм эсэсчыларга папирос тәкъдим итте.

— Менә бит! — дип куйды Вишневский, мәгънәле итеп.

— Менә кайда ул чын цивилизация! Менә бу культура нчмасам! — диде аның янында торучы поляк.

Аннары очучыны каядыр алып киттеләр, ә безне этә-төртә эш урыннарыбызга куарга тотындылар.

Соңгы көннәрдә америка һәм инглиз очучылары лагерьга листовка-

лар ташлый башладылар. Аларның берничәсен үземнең дә алып укыганым бар. Берсенә: «Агачлар яфрак ярырга өлгергәнче үк сезгә килеп җитәрбез», диелгән. Ә икенчесенә бер куплет шигырь язылган иде. Эчтәлеге якынча менә болайрак иде аның:

Мартта — бомбалыйбыз.
Апрельдә — алга барабыз.
Майда — туздырып салабыз.

Замана бик каршылыклыга әйләнде хәзер. Бер яктан — ачлык, икенче яктан — җиңү салютлары; бер якта — крематорий морҗасыннан тәүлекләр буена чыгып торган кара төтен, икенче якта — якынаеп килгән канонада тавышлары; бер якта — эсэсчыларның тук, әмма күңелсез кыяфәтләре, икенче якта — тоткыннарның эчкә баткан, әмма өмет шатлыгы белән тулы күзләре. Кыскасы, кайгысы да җитәрлек, шатлыгы да күп.

Кичә төш вакытында бөтен лагерь дер селкенеп алды. Америка самолеты бомба ташлаган иде. Ул бомба прецефикс территориясендәге сугыш кирәк-яраклары складына төшеп, андагы снарядларны да шартлатты. Шул чакта, снаряд кыйпылчыгы тиеп, берничә тоткын һәлак булды.

Ә бүген союзниклар лагерьга аңлату листовкалары ташладылар: очучы барак номерларын буташтыру аркасында ялгышлык килеп чыккан икән. Бомбалар прецефикстан ерак булмаган комендатура бинасына ташланырга тиеш булган.

Әйе, бомбага тоту вакытында корбаннар да булды. Әмма бу хәл безне куркытмый. Без моңа сөенәбез генә, чөнки җиңү сәгатьләре якынаеп килә! Ә корбаннар бомбага тотмаган вакытта да, шөкер, Дахауда җитәрлек булды. Һәм әле дә булып тора.

Узган шимбә көнне прецефикс территориясендә башта бик каты киндидер шартлау тавышы ишетелеп, аннары кара төтен күтәрелгән иде. Ял көнне прецефикстан мунчага юынырга килгән тоткыннар әйтте: трансформатор будкасы янган икән. Янгын вакытында трансформатор сафтан чыкканлыктан, прецефикстагы цехлар да эштән тукталып калган.

Бер карагайда катнашы юк кебек тоелса да, безнең яшерен оешма тарафыннан эшләнгән планлы диверсия иде бу. Һәм ул диверсия менә болай тормышка ашырылган иде. Әлеге трансформатор будкасының тәрәзәсе прецефикстан тышта — тоткыннар үтеп йөри торган сукмакка карап тора иде. Әнә шул сукмактан үтеп барышлый бер тимер чылбыр янсә тимер кисәген тәрәзәдән эчкә ташласаң — ток чыбыклары тоташып китә дә шартлау була һәм шундук янгын чыга! Ләкин ничек ыргытырга соң ул тимер чыбыкны? Уйлаша торгач, егетләр моның да җаен тапканнар. Прецефикста эшләүче тоткыннар цехларда эшләгән вакытларында, фашистларга сиздермичә генә, шыпырт кына зажигалкалар ясап алып чыгалар да аларны я иптәшләренә бүләк итәләр, я берәр нәрсәгә алмашалар иде. Моны Алеша Юрцев дигән тоткын аеруча оста эшли иде. Көннәрдән бер көнне кайсысыдыр Алешага шундый фикер әйткән: «Идәнгә яки стенага бәрелү белән кабынып китә торган зажигалка ясый алмассыңмы, Алеша?» — дигән.

— Карап карармын,— дигән Алеша. Һәм атна-ун көн эчендә иптәшләре сораган зажигалканы ясап та биргән. Аннары... аннары ул зажигалка, бензинлы чүпрәккә төрелеп, трансформатор будкасына «кереп» киткән һәм әлеге янгын чыгуга сәбәпче булган.

Эсэсчылардан һәм электр эше буенча тәҗрибәле тоткыннардан торган комиссия, «бик җентекләп» тикшергәннән соң, янгын, подстанцияне дөрес эксплуатацияләнмәү сәбәпле, чыбыклар кушылып китүе аркасында чыккан, дигән нәтиҗәгә килде. Фашистлар янган агач будка урыны-

на кирпечтән яңаны салырга булганнар. Аны төзүчеләр бригадасына безнең оешма вәкилләреннән Виктор Воробьев, Иван Пассюк, поляк Киричинскийларны билгеләгәннәр. Әлбәттә, алар аны мөмкин кадәр озаграк төзергә тырышачаклар. Тик шунысы гына начар — бригадир итеп уголовник немецны куйганнар.

* * *

Михаил Петрович Седовның яңак тиреләре нервланып калтыраштыргалап куя, ун кулы буй-буй сызыклы пинжәк төймәләрен капшый. Ул кайчак бик азга гына тынып калып, кипкән иреннәрен ялап-чылатып ала да тагын сөйли башлый. Прецефикста өч кешене җәзалап үтерүләрен без ишеткән идек инде. Михаил Петрович ул аяныч хәлне үз күзе белән күргән бит!

— Янган агач трансформатор будкасы урынына кирпеч будка сала башлаганнары билгеле инде сезгә,— диде ул.— Аны төзүчеләр бригадасына безнең егетләрнең кайберләре кергәнен дә беләсез. Без ул егетләргә ашыгып эшләмәскә кушкан идек. Әмма аларга бригадир итеп билгеләнгән «яшел» немец бик әшәке нәрсә булып чыкты. Күрәсең, фашистлар каршында яхшы булып күренергә теләгәндер инде. Бертуктаусыз «Шнель! Шнель!» дип кычкырып һәм сүгенеп тора башлады бу. «Саботаж!» дип тә чиный. Менә шул хәлгә бик нык ачуы чыккан кызу канлы Виктор Воробьев, бер көнне түзмичә, теге уголовникның үзенең дә кирәген бирде. Ә немец шундук сак комендантына жалоба бирергә чапты. Кичке барлау вакытында эсэсчылар безнең егетләрне эт итеп кыйнап ташладылар. Ә икенче көнне иртән аларны прецефикстан алып киттеләр. Күпме тырышып карасак та, аларны кая алып китүләрен белә алмадык.

Михаил Петрович, кызып китеп, артык кычкырыбрак сөйли башлаган иде. Шуңлыктан аның акрынрак сөйләвен үтенеп, кулыннан тотарга туры килде. Без үзара юк-бар сүз сөйләшеп, һава сулап йөрүчеләр сыман ваемсыз күренергә тырышып, «Ирек урамы» буйлап бара идек. Михаил Петрович минем искәртүем өчен рәхмәт әйтеп елмайды да сүзен дәвам иттерде:

— Викторларны алып киткәнгә өч атна дигәндә безгә мунчага барырга әзерләнергә куштылар. Ләкин бу юлы ниндидер шик булуын без башта ук сизендек. Мунчага китәр алдыннан безнең барыбызны да тезеп куеп, баштанаяк тентеп чыктылар. Бу көнне сакчылар да башка вакыттагыдан күбрәк иде. Бүтән вакытларда без, мунчада юынганнан соң, мунча буена чыгып, бараклар янына барып йөри, хәтта кайчак лагерьдагы иптәшләребез белән дә сөйләшкәли ала идек. Бу юлы борылырга да ирек бирмәделәр. Юынып чыгу белән сакчылар урап алдылар да туп-туры крематорий ишек алдына алып бардылар. Анда һәркайсына берәр элмәк эленгән өч дар агачы эшләп куелган иде. Эсэсчылар безне шул дар агачлары каршына бастырып куйдылар, автоматларын кулларына тоттылар. Аннары каршыбыздагы трибуна сыман бер урынга рапортфюрер менеп басты һәм «Ахтунг!» дип команда бирде.

Аның бу командасыннан соң, шундук безнең егетләрне — Виктор Воробьевны, Иван Пассюкны һәм Киричинскийны алып килделәр. Алар шыр ялангач, бөтен тәннәре кыйналып күгәреп беткән иде. Куллары артка каерылып богауланган. Чыкмаган җаннары гына калган. Аякларында, белмим, ничек басып тора алалардыр. Ләкин алар шул хәлләрендә дә үлем алдыннан безне, иптәшләрен, күрүләренә куанышып, елмаешкандай итеп торалар, бичаралар!.. Юк, тукта, Сәгыйть, булмый, бераз тын алыйм әле...— Михаил Петрович, күнеле тулып, тынып калды. Миңа да бик кыен иде бу минутларда.

Бер тын гына atлап барганда бер борылыштан «Володя абый»

килеп чыкты. Кәефе әйбәт иде бүген ул хайванның. Үзенә каршы очраган бер яшүсмернең артына типте дә, авызын ерып, үз юлы белән китеп барды.

— Ә аннары тагын да коточкычрак хәл булды,— дип дәвам итте Седов, «Володя абый» бездән ераклашкач.— Егетләрнең өчесенә дә безнең күз алдында муеннарына элмәк кидерделәр... Виктор: «Хушыгыз, иптәшләр! Безне онытмагыз, үч алыгыз!» — дип кычкырды. Палач бар көченә аның янагына сукты һәм аяк астына куелган такта урындыкны тибеп аударды... Ә аннары мәетләрнең өчесен дә, вагонеткаларга төяп, крематорий бинасына алып киттеләр. Рапортфюрер: «Барыгызга да шушы дар агачы булачак!» — дип янап куйды.

## Саумы, Кояш!

Соңгы көннәрдә лагерьда, Австриядәге Альп таулары башында Гитлер немец оборонасының соңгы бастионы — «герман милли редуты» төзетмәкче була икән, аны совет хәрби әсирләре һәм чит ил коммунистлары көче белән төзетергә исәплиләр һәм бу эшне башкарып чыгу өчен егерме меңләп тоткынны шунда озатачаклар икән, дигән хәбәр таралды. Әмма тәгаен генә берәү дә берни белми иде әле.

Ә фронт Дахауга көннән-көн якынлаша бара. Тоткын артиллеристлар әйтә: туп тавышларына караганда, фронт Дахаудан сиксән-йөз километрда, диләр.

Әле узган якшәмбедә, гадәттәге «йөрергә чыккан» вакытта, Климент Густавны күреп сөйләшкән идем.

— Күңелсез мәгълүматлар бар бит әле, Сәгыйть Абдуллович,— диде ул.— Гестапочылар, бик тырышып, тоткыннарның карточкаларын тикшерәләр икән анда. Совет әсирләренең һәм коммунистларның карточкаларын аерып куялар, ә кайберләрен яндыра баралар, ди. Күрәсең, нинди дер вәхшилек эшләргә әзерләнәләр булса кирәк. Бик сак булырга кирәк бу көннәрдә.— Климент беравык ерактагы туплар тавышын тыңлап торды да, күңелсез генә итеп: — Сугыш бетәр алдыннан гына үләсе килми бит, Сәгыйть Абдуллович! — дип куйды.

Климентның бу хәбәрен чылбыр буйлап шундук Дахаудагы һәм аның филиалларындагы ышанычлы тоткыннарга тараттык. Фашистларның нинди дер кабахәтлек эшләргә җыенуын әйтеп, саграк булырга куштык.

Егерме бишенче апрельдә бөтен лагерь умарта оясы кебек гүли башлады. Имеш, Дахаудагы барлык тоткыннарны да Альп тауларына редут төзәргә күчерәчәкләр дигән хәбәр бөтен лагерьга таралган иде. Кеше ышанырлык хәл түгел бу, әлбәттә. Чөнки ток үткәрелгән чәнечкеле тимер чыбыклар, тирән канаулар, мина кырлары белән, пулеметлы, автоматлы сакчылар белән уратып алынган Дахау хәтле Дахауда күнелләре ярсыган тоткыннарны көч-хәл белән генә тыеп тора алган фашистлар тауда ничек буйсындыра алсыннар ди аларны? Без әнә шулай фикер йөртәбез һәм ул имеш-мимешкә ышанмый идек. Әмма тоткыннар арасында шуңа ышанучылар да күп иде.

Егерме алтынчы апрельдә иртән иртүк тоткыннарны аппельплацка тезеп, барлап чыктылар. Ләкин башка көннәрдәгечә бригадаларга бүлеп, эшкә алып китәргә ашыкмадылар. Безне — ун мең совет тоткынын — бер җирдә, биш мең немец һәм австрияле тоткыннарны үзләрен аерым урында җыйган килеш тота бирделәр. Гел аяк өстендә һәм коеп яуган яңгырда басып торып интегеп бетсәк тә, болай озаклауның файдасы да булды безгә. Шул вакыт эчендә киңәш-табыш итәргә, кайбер нәрсәләрне ачыкларга, ә иң мөһиме — үзара оешырга мөмкинлек туды. Сораша-сөйләшә торгач, фашистлар безне Дахаудан читкә алып китеп

юк итәргә жыеналар булса кирәк, дигән фикергә килдек. Һәм кулыбызда корал булмаса да, сугышсыз гына бирелмәскә карар кылдык. Дөрес, кайберләребез ул сугышта һәлак тә булыр, әмма безнең бүтән чара юк дип, актык тамчы каныбызга кадәр сугышырга булдык. Шул максат белән восстание штабы оештырдык.

Восстание житәкчесе итеп Сергей Владимирович Вишневскийны, аның ярдәмчесе итеп Илларион Андреевич Пановны, штаб башлыгы итеп полковник Иван Андреевич Петровны сайладык. Мина разведка начальнигы вазифасын башкару бурычы йөкләнде. Стрелков, Бикташев һәм Полянский да штаб составына кертелделәр.

Башка колонналарда да шундый ук штаблар оештырылды. Безнең белән күрше колоннаның башлыгы итеп генерал-майор Тонконогов, ә аның ярдәмчеләре итеп Семен Маляров, Сергей Пельман, Артем Марценюк, Николай Власкиннар сайланды. Кыскасы, һәр рус тоткыннары колоннасында антифашистик активтан вәкилләр бар иде. Восстание була калган тәкъдирдә безгә ярдәм итәрсез дип, австрияле һәм немец тоткыннары колонналарындагы коммунистлар белән дә сөйләшеп куйдык.

Ниһаять, төш вакытларында безне каядыр алып китәргә әзерләнә башладылар. Конвойчылар поход вакытында тоткыннар бик төгәл буйсынырга тиешле тәртипләрне аңлаттылар. Юлда барганда беркемгә дә сафтан чыкмаска, артка калмаска, тәмәке тартмаска һәм ризык ашамаска, сөйләшкәндә дә шыпырт кына сөйләшергә куштылар. Бу кагыйдәләрне бозган кешеләр шундук атып үтереләчәк икәнлеген әйтеп, куркытып куйдылар.

Аннары коры паеклар өләштеләр һәм, сакчылар, овчаркалар белән уратып алып, колонналарны Дахаудан чыгара башладылар. Лагерьда бары тик каты авырулар, аякларында басып тора алмаслык хәлсезләр һәм ярты көннән артыкка сузылган ыгы-зыгы вакытында венкельләрен үлгән чит ил тоткыннары венкеле белән алыштырырга өлгергән Михайлов, Медведев, Масленников, Нуретдинов һәм Календаревлар гына калды.

Хуш, үлем лагере Дахау! Хуш, крематорийның тончыктыргыч кара төтене! Хушыгыз, лагерьда калган иптәшләр! Сезне нишләтерләр икән инде монда?

Лагерьдан чыккач, безнең колонналарга тагын берничә колонна өстәлде. Башка лагерьлардан куып китерелгән, тәмам ябыгып, хәлсезләнеп беткән француз, поляк һәм немец еврейләре — барлыгы биш меңләп кеше иде алар.

Бу еврей колонналары килеп кушылгач, безне үтерергә алып баралар ахыры дигән фикеребез тагын да ныгый төште: фашистлар еврейләрне һәрвакыт иң алдан юкка чыгарырга тырышалар бит. Аннары русларны...

Безне як-якларына агач утырткан тигез юлдан түгел, бәлки юл читеннән алып баралар. Ә шосседан тыз-быз килеп автомашиналар, мотоцикллар йөреп тора...

Менә без Мюнхенга да життек инде. Ләкин безне шәһәргә алып кермәделәр, егерме меңләп халыкны анда алып керергә шикләнделәр булса кирәк. Мюнхенны читләтеп алып киттеләр.

Юлда безне йөз егерме-йөз утыз кешелек бер кечкенә колонна узып китте. Прецефиксте эшләгән кешеләр колоннасы булып чыкты ул. Аны көчәйтелгән сак саклап бара иде. Шулай да, ерактан булса да, Седовны күреп калдым мин. Ул да мине күргән булса кирәк — кулын селкеп сәламләп үтте.

Көн озын явып, бөтен киемнәрне манма суга әйләндергән яңгыр, ниһаять, кичкә таба туктады. Болытлар таралды һәм баеп барган кояш нурлары күзләрне чагылдыра башлады. Тирә як гажәеп бер язгы ма-

турлыкка күмелгән һәм юл буйларындагы агачларда өздереп кошлар сайрый иде.

Кояш батып, җир йөзенә кичке эңгер җәелә башлагач, привал игъ-лан иттеләр. Тоткыннар шундук кайсы кай җиргә аудылар. Аннары Дахауда бирелгән коры паекларны — өчәр йөз грамм икмәк белән тоз-лы балыкны ашарга команда булды.

...Ашавын ашадык та, тик менә эчәсе килүгә чыдап булмый хәзер. Елап үләм дисәң дә, якын тирәдә бер тамчы су юк. Шуңлыктан, ника-дәр арылган булса да, күзне йокы алмый. Эч тә бик поша. Кая алып баралар, ни эшләтмәкче булалар? дигән уй бер генә минутка да күңелдән чыкмый.

Шулай да таң алдыннан мине йокы баскан иде инде. Ләкин озак йокларга туры килмәде, әле рәтләп яктырып та бетмәс борын сафларга тезелергә һәм маршка әзерләнергә команда булды. Һәм тиздән колон-налар юлга кузгалды. Озак та бармадык, тагын яңгыр сибәли башла-ды. Пычракка баткан агач башмаклар аякларны кабартып-кырып бе-тергәнлектән, тоткыннарның күбесе көч-хәл белән, аксый-аксый гына атлап бара. Аптырагач, башмакларын кулларына тотып, ялан аяк ба-ручылары да байтак.

Безгә һаман су эчергәннәре юк әле. Барган уңайга авызыбызны ачып, яңгыр тамчыларын тотарга, шулай итеп кипкән тамакларыбызны чылатырга тырышабыз.

Тәмам хәле китеп, егылып калучылар да күренгәли башлады инде. Конвойчылар бугазларын ертып акыралар, артка кала башлаган хәлсез тоткыннарны резин таяклар белән кыйныйлар. Мин белгән кешеләрдән полковник Сотников белән полковник Ермолаев та егылып калган иде. Колонналар артыннан йөк машиналары чакыртып, арып егылучыларны шуларга төяделәр дә каядыр алга алып киттеләр.

Бер кичерәк кенә авылны узгач, привал игълан иттеләр һәм, ярты сәгатьтән соң кайнар кава (кофе) бирeләчәк, диделәр. Әмма халыкның анда кайгысы юк иде инде. Тоткыннарның күбесе ярым һушсыз хәлдә туктаган урынында ятып калган иде.

Привалда торган вакытта безнең янга Сергей Пельман килде һәм, конвойчыларның үзара сөйләшүләренә караганда, бая машинага утыр-тып алып киткән хәлсез тоткыннарның юлда очраган беренче чокыр бу-енда ук атылган булуларын әйтте.

Пельманның бу коточкыч хәбәрен ишетүгә, чылбыр аша бөтен ко-лонналарга да: «Арып калучылар машиналарга утырмасын!» — дип боерык бирдек.

Нибары кырык минутлык ялдан соң аяк атлаулары тагы да кыен-лашты. Ачлык, аннан да бигрәк эчәсе килү бәгырьләрне телгәли. Хәле китеп егылучылар һаман күбәя бара. Менә минем алда баручы бик ябык һәм озын буйлы тоткын да егылды. Мин аңа берничек тә булы-ша алмыйм, чөнки үзем кайчан егылырмын икән дип барам. Ә теге тоткынны конвойчы читкә сөйрәп алды да берничә тапкыр башына һәм аркасына резин таяк белән сукты. Тоткын торырга азапланып караса да, булдыра алмады. Аннары конвойчы аңа овчаркасын җибәрде. Эт котырынып таларга тотынгач, җан ачысы белән күпме кычкырса да, ул мескен тоткынның тавышы эт өргән, конвойчылар сүгенешкән тавышлар арасында югалып калды.

Бераз киткәч, артыма әйләнеп карадым. Тоткынны талаган эт инде читкә киткән һәм чыпчык баласына ташланырга торган мәче кебек по-сып, омтылып, хуҗасыннан яңа команда көтеп тора. Юл читендә хәл-сезләнеп егылып калган тагын берничә тоткын күренә иде.

— Аларны нишләтерләр икән, Илларион Андреевич? — дидем Па-новка, берәр җылы сүз әйтмәсме дип өмет итеп.

Юк, өметле сүз әйтмәде.

— Нишләтәселәре билгеле инде, Сәгыйт Абдуллович,— диде ул.— Колонналар үтеп киткәнне генә көтеп торалар да аннары атып калдыралар аларны. Бары тик хәле булмаганлыктан гына атлый алмаган ул мескеннәрне уннарча мең кеше күз алдында атарга куркалар хәзер фашистлар... Стрелков өчен бик борчылам әле мин. Кара, ничек чак-чак кына атлый.

Әйе, Василий Ефимовичның хәле чыннан да шәптән түгел, ахыры. Йөзенә мәет аклыгы йөгергән, сулышын еш-еш ала, аяклары, суелып, кып-кызыл булган. Бер адымын атлавы да аның өчен гаҗәеп авыр икәнлеге әллә кайдан сизелеп тора.

Бераз уйланып барганнан соң, Панов бездән бер рәт алда баручы Бикташевны янына дәшеп алды да:

— Озакламый привал булырга тиеш, Вәли. Шунарчы егетләр белән носилка сыман берәр нәрсә әмәлләп аласы иде бит. Василий Ефимовичны чиратлашып күтәреп барырга кирәк. Колонналар буйлап хәбәр итегез, иптәшләрне ташлап калдырмасыннар! — диде.

Чираттагы привалга туктагач, бер яшь кенә егет — очучы Михаил Никонов — Вишневский янына килде дә:

— Кая алып баралар безне, иптәш генерал? — дип сорады.

Генерал иңбашларын сикертеп куйды:

— Кызганычка каршы, кая алып баруларын миңа әйткәннәре юк шул,— диде.

— Соң безне үтерергә алып баралар бит! — диде Михаил ачыргаланып.— Болай кул кушырып көтеп утырып булмый лабаса. Качарга кирәк. Аңлыйсызмы, качарга кирәк!

— Син качарсың да бит, әнә ул абзаң ничек качар икән, энекәем? — диде ана Панов, ярым һушсыз яткан Стрелковка күрсәтеп.— Икенче тәүлек походта киләбез, аякларыбызны көчкә атлыйбыз бит инде. Шулай булгач, качу турында сөйләргә мөмкинме соң? Сиңа да киңәш итмим, энекәш. Артыннан овчарка җибәреп, хәзер борып алып килерләр үзеңне. Хәер, алып килеп тә тормаслар.

— Барыбер тәвәккәллим мин. Барыбер качам! Хушыгыз, начар яктан искә алмагыз! — диде Михаил һәм шундук халык арасына кереп тә югалды.

Ә тагын бер привал вакытында безнең янга Семен Маляров килеп чыкты. Аның йөзендә курку да, шул ук вакытта тәвәккәллек тә сизелеп тора иде. Бер колоннадан икенче колоннага күчәргә хәтта привал вакытында да рөхсәт ителми. Әмма Семен, гомерен кыл өстенә куеп булса да, батырчылык иткән.

— Очучы Михаилны беләсезме? — диде ул еш-еш сулап.

— Беләбез, әлбәттә. Үткән привал вакытында безнең белән хушлашып, качам дип киткән иде.

— Юк шул! Кача алмаган ул... Качып барганда овчаркалар сизеп алган. Аннары шундук атып үтергәннәр үзен. Үнберенче кеше инде ул бүген. Берәмләп качарга тырышудан мәгънә булмавын яшьләргә аңлатырга кирәк.

— Аңлатып караган идек тә, тыңламады бит,— диде Полянский.

Аннары Семен, ялт-йолт карана-карана, халык арасыннан үз колоннасы ягына таба китте. Ул күздән югалырга да өлгермәгән иде әле, яныбызга Марценюк килеп җитте. Марценюк та Семен белән бер колоннада бара иде, күрәсең, бик кирәкле әйтер сүзе булгандыр — тәвәккәлләп безнең колоннага күчкән.

— Сез игътибар иттегезме икән, иптәшләр,— диде ул, килеп туктауга.— Безне саклап килгән лагерь сакчыларын ополченецлар белән алмаштыра башладылар бит. Үзләре качалар, сволочьлар!

Чыннан да, сакчылар алышына, ә кайбер эсэсчылар, свастикалы мундирларын салып, гади, штатский киемгә кенә башлаганнар иде.

Моннан бер генә төрле нәтиҗә ясарга мөмкин иде: безнең союзникларның гаскәрләре якынлашып килә, шуна күрә фашистлар таю ягын чамалыйлар. Ләкин безне нишләтмәкче була икән соң алар!

Егерме тугызынчы апрельдә Дахаудан килә торган барлык эсэсчы сакчыларны, хәтта аларның начальнигына хәтле, тагын алыштырдылар. Ә без алар белән исәп-хисапны үзебез генә өзмәкче идек. Алайса, булмый инде.

Хәлләр киеренкеләнгәннән-киеренкеләнә бара. Нервыларның кызуы шундый чиккә житкән, чак кына бер сәбәп чыкса — хәзер конвойчыларга ташланырга торабыз. Әмма алар — калдык-постык ополченецлар — үзләре дә бездән шикләнәләр хәзер.

Чираттагы привалларның берсендә штаб членнары иртәгесен восстание күтәрү турында килештеләр. Корбаннар булыр булуын, әмма сакчылар безне автоматлардан атып кыра башлаганны көтеп торуның да мәгънәсе юк бит. Кыскасы, инициативаны үз кулыбызга алырга кирәк дигән карарга килдек.

Колонналарны төнге ялга туктаталар. Егерме тугызыннан утызынчы апрельгә каршы төн иде бу. Тагын тымызык кына вак яңгыр яварга тотынды. Конвойчылар әледән-әле бер-бере белән сөйләшеп-хәбәрләшеп торалар. Овчаркалар улый. Бөтен дөнья юеш, инә төртерлек тә коры жир юк. Шунлыктан я аяк өстендә, я чүгәләп кенә торырга мөмкин. Ә күз кабакларын йокы баса...

Кинәт урман буенда ике көлтә яктылык пәйда булды. Шундук автомашина тавышы ишетелә башлады. Менә машина бөтенләй якынайды һәм колонна каршына килеп, тукталып калды. Ул ачык җиңел машинада колонна начальнигы — гауптман басып тора иде.

— Ахтунг! Ахтунг! — дип кычкырышты конвойчылар.

— Әфәнделәр! — диде гауптман, кинәт урнашып калган шомлы тынлыкны бозып.— Менә минем кулымда Гиммлер тарафыннан кул куелган приказ. Бу приказда әйтелгән: Дахау тоткыннары юк ителеп бетерелергә тиеш, диелгән.— Гауптман шунда туктап, беркавым эндәшми торды да дәвам итте: — Ләкин мин бу приказны үтәмәячәкмен, әфәнделәр, чөнки...

Колонна начальнигы тавышын шул чак безнең өстән үтеп баручы самолетлар гүләве каплап китте. Күрәсең, америка бомбардировщиклары иде алар.

Самолет тавышлары ераклашкач, янадан тынлык урнашты, һәм гауптман:

— ...чөнки союзниклар гаскәрләре Германия территориясендә инде. Таң ату белән елганың аргы ягына чыгыгыз, шунда америкалылар белән очрашырсыз,— дип сүзен тәмамлады. Аннары тиз генә урынына утырды, һәм автомобиль, кырт борылып, килгән юлыннан кире китте.

Иа, хәдир! Шул чакта тоткыннарның ничек шатланышуын күрсәгез иде сез! Кайсы «урра!» кычкыра, кайсы сабыйларча баскан урынында сикерә, кайсылары кочаклаша, кайсылар үбешә! Һәм һәркемнең күзендә яшь, шатлык яшьләре! «Үлем маршы»нда килгән вакыттагы киеренкелек, ачу һәм курку берничә минут эчендә көлүгә һәм күз яшьләренә әверелгән иде.

Без шулай шатлыктан исерешеп торган арада конвойчылардан һәм овчаркалардан жилләр искән иде инде. Кара син ул еланнарны, ә! Кай арада табан ялтыратып өлгергәннәр алар!

Без хәзер, түземсезләнеп, таң атуын көтә башладык. Йокы турында уйлаган кеше дә юк, безнең йокылар күптән качты инде. Яшьләр арасында учак ягып жибәрергә ниятләп йөрүчеләр дә бар иде, әмма Вишневский рөхсәт итмәде.

— Мондый буталыш вакытында андый эш белән шөгыльләнмәгез,

егетләр. Учак — төнлә бик яхшы мишень ул. Аннары, азат булсак та, үз җиребездә түгел бит әле без, фашистлар җирендә! — диде.

Таң сызыла башлау белән барысы да бер-береннән узыша-узыша яр астына, елга аша салынган күпергә юнәлделәр. Ләкин тиздән тукталып калырга туры килде. Күпер миналанган иде. Шулай да минасыз урыннарга баса-баса акрынлап теге якка чыктык.

Аннары генерал-майор Вишневский штаб членнарын җыйды да:

— Ак флаглар әзерләргә кирәк. Күлмәкләрдән булса да ярый. Югыйсә америка гаскәрләре безне немец частьлары дип уйлавы һәм ут ачулары мөмкин,— диде. Аннары миңа, разведчиклар җибәреп, якын тирәдә эсэсчылар һәм чигенеп баручы немец гаскәрләре юкмы икәнлеген ачыкларга боерык бирде.

— Ул эшәке җаннар күзенә чалынмау хәерлерәк,— диде ул.

Тиз арада разведчиклар билгеләп, аларны берничә группага бүлеп, разведкага җибәрдем.

Ә Панов һәм штабның башка членнары тоткыннарга союзниклар янында үзләрен ничек тотарга кирәклекне аңлату эшенә керештеләр.

— Бернинди дә мародерлык эшләмәскә! Америка гаскәрләре алдында көлкегә калмаска! Сез хәзер хокуксыз тоткыннар түгел инде. Сез — совет офицерлары һәм солдатлары хәзер. Шуны онытмагыз! — дип халыкны кисәтеп йөрделәр алар.

Менә бер заман бездән ерак булмаган бер калкулык артында гына бик каты гүләү тавышлары ишетелде. Барыбыз да ни булыр икән бу? дип туктап калдык һәм шул чак горизонтта танклар күренде.

— Немецлар түгелдер бит? — дип кычкырып җибәрде кайсыдыр.

Ә танклар зур тизлек белән безгә таба якынлашалар иде. Качып котылырга теләсәң дә, өлгерә алмыйсың!

Юк! Немец танклары түгел! Әнә аларның башняларына ясалган биш почмаклы америка йолдызлары да ап-ачык күренә башлады. Һәм күп меңләгән халык төркеме:

— Урра! Союзниклар! — дип кычкырып, баш киемнәрен салып, танкистларны сәламләргә тотындылар.

Көнчыгыш яктан кояш чыгып килгән чак иде бу. Зур, кызыл кояш, шатлык кояшы чыгып килә иде. Саумы, Кояш! Моңарчы, 1307 көн буена, мин аның чыгуын чәнечкеле тимер чыбык арасыннан гына күреп яшәдем. Ә бүген, 1945 елның 30 апреле иртәсендә, мин аны азат, ирекле кеше булып каршылыйм!

## Соңгы сүз

Ихтимал, укучыларны бездән соң Дахауда ниләр булуы, анда калган тоткыннарның язмышы кызыксындыра булыр. Алда әйткәнемчә, без чыгып киткәндә антифашистик группаның актив члены генерал-майор Николай Филиппович Михайлов та Дахау ревирында, туберкулез белән авыручылар бүлегендә ятып калган иде. Соныннан ул анда булган хәлләр турында менә нәрсәләр сөйләде:

«Колонналарны Дахаудан алып чыгып киткән көнне кич белән, икенче баракның блок башлыгы аркылы, без немец гаскәрләренең Мюнхенга чигенүен һәм безнең лагерьда калган барлык тоткыннарны юк итеп бетерергә күрсәтмә булганлыгын ишеттек. Ә лагерьда барлыгы кырык меңләп төрле милләт тоткыннары бар иде әле.

Шул ук кичне лагерь эчендәге барлык сакчылар да каядыр китте. Бары тик көчәйтелгән тышкы сак кына калды.

Егерме җиденче апрель көнне иртән безгә бернинди ризык та бирмәделәр, кухня эшләмәде, продукт складлары бикле иде. Бары тик суны гына япмыйча калдырып киткәннәр иде. Ул көнне цехларда да эш туктады.

Иртәнге сәгать сигездә икенче баракка төрле милләт тоткыннарыннан вәкилләр җыелды. Руслар, французлар, бельгиялеләр, чехлар, поляклар, румыннар, немецлар, югославлар, итальяннар, голландиялеләр һәм башка бик күп милләт вәкилләре бар иде анда. Килеп туган хәлне тикшергәннән соң, шул вәкилләр тарафыннан унөч кешелек Интернациональ комитет сайланды. Аның председателе итеп мине, председатель ярдәмчесе итеп инглиз подполковнигын, секретаре итеп бер поляк тоткынын (фамилияләр исемдә калмаган) сайладылар.

Комитет түбәндәге чараларны билгеләде һәм шундук аларны тормышка ашыру эшенә кереште: хәллерәк, сәламәтрәк кешеләрдән сугышчан дружиналар төзеде; баракларда әчке тәртипне саклау өчен милиция отрядлары билгеләде; бөтен лагерь өчен уртак булган тревога сигналы билгеләде.

Егерме җиденче һәм егерме сигезенче апрель көннәре шактый тыныч үтте. Лагерь өстеннән түбәнтен генә очучы инглиз һәм америка самолетлары тоткыннарны тыныч булырга һәм үзләрен азат иткәнне көтеп торырга өндәгән листовкалар ташлап киттеләр.

Егерме тугызынчы апрельдә иртүк артиллериядән аткан көчле тавышлар ишетелә башлады. Ул тавышлар һаман саен якыная барды. Ә көндезге сәгать өчләрдә Мюнхен ягыннан, немецлар тылыннан, танк тупларыннан аткан тавышлар ишетелә башлады һәм, ярты сәгать тә үтмәгәндер, дүрт танк, койманы җимереп, лагерьга килеп керде.

Каланчаларда безне саклап торган немец сакчылары, әчке ак күлмәкләрен салып, аларны автомат көпшәләренә элеп болгыйлар — бирелергә теләүләрен аңлаталар иде.

Бу вакытта аяк атлар хәле булган тоткыннарның барысы да урамга чыккан һәм, шатлыкларыннан нишләргә белмичә, кычкырышалар, елыйлар, кочаклашалар иде. Аннары америка солдатлары, азат ителгән тоткыннар күрсәтүе буенча, элекке сатлык җаннарны һәм немецларга куштанланып йөргән адәм актыкларын атарга тотындылар. «Володя абый»ны да алар атып үтерде. Аны яшүсмер тоткыннар барак чардагына качкан җиреннән табып алып төшкәннәр иде.

Кичке сәгать бишләрдә мине алырга машина килде. Элекке комендатура торган бинага урнашкан америка генералы, Интернациональ комитет председателе булуымны белеп, мине үзе янына чакырган иде. Ул мине бик ягымлы каршылады. Аннары миңа бөтен унайлыклары булган аерым квартирага урнашырга һәм лагерь турында кайгырту эшен өстемә алырга тәкъдим итте.

Мин аның беренче тәкъдимен кире кактым, ә икенчесенә, түбәндәге шартләр үтәлгән тәкъдирдә, риза булачагымны әйттем: «Лагерь тышына америка солдатларыннан сак куелсын һәм алар мин кул куйган пропусклары булмаган бер генә кешене дә лагерьдан чыгармасыннар; ревирга врачлар китерелсен, медикаментлар бирелсен; лагерь азык-төлек белән тәэмин ителсен, каты авыру кешеләр госпитальгә озатылсын»,— дидем.

Минем бу таләпләремнең барысы да канәгатьләндерелде. Хәзер, лагерьның бөтен җирен дә карарга мөмкинлек тугач, анда булган коточкыч хәлләрне тагын да ачыграк күрергә туры килде миңа. Бик күп тоткыннар ябыклыкның соңгы чигенә җиткән һәм аларны инде бернинди медицина да коткарып кала алмаячак иде. Ул көннәрдә өчәр йөз кеше дистрофиядән үлде.

Тимер юл депосы подвалларында мең ярымга якын үле гәүдәләр таптык. Аларны крематорийда яндырырга әзерләп куйган булганнар.

Америкалылар лагерьга күп итеп азык-төлек китергәннән соң, кинәт кирәгеннән артык ашаганлыктан, ашказаннары эшләмәү сәбәпле генә дә бер төн эчендә алты йөзләп кеше вафат булды. Үзе бик күп

тоткыннарны коткарып калу өчен заманында зур ярдәм иткән Николай Матрос та шулай артык ашап харап булды.

Мондый күнелсез хәлләрдән соң Интернациональ комитетка ашыгыч чаралар күрергә туры килде. Киләчәктә дә шундый хәлләр булмасын өчен, баракларда тентү үткәрелеп, артык продуктлар җыеп алынды, врач күзәтүе астында халыкны дөрес ашату-эчертү оештырылды.

Лагерьны һәм анда яшәүче кешеләрне санитария-гигиена таләпләренә җавап бирерлек хәлгә китерү өчен дә күп көч куярга туры килде. Бу бик мөһим эш иде, чөнки лагерьда тиф белән авыручылар бар, әнә шул авыру таралудан сакларга кирәк иде халыкны.

Тәртип урнаштыруга һәм кешеләр арасында иптәшләрчә мөгамәлә булдыруга да зур игътибар бирергә туры килде: лагерьда политик карашлары да, таләпләре дә һәм киләчәк турындагы уйлары да төрлесенеке төрлечә булган җитмеш төрле милләт вәкиле яши иде бит!

Беренче май бәйрәмен бик тантаналы итеп каршыладык. Демонстрация ясадык, зур митинг үткәрдек. Ә өченче майда лагерьга Совет Армиясе вәкиле капитан Щербаков килде. Ул үзе белән Дахаудагы рус хәрби әсирләреннән һәм гражданнарыннан революцион полк төзү турында инструкция дә алып килгән иде. Ул полк бишенче майда төзелде. Аның командиры итеп мин полковник Медведевны билгеләдем».

## Совет властеның 50 еллыгына

*К. Рәхим*

# КӨРӘШ ЕЛЛАРЫ[1]

## «Ура!» тавышлары астында

Вәли абзый Җәббаровны атарга алып чыгып китүләре турындагы шомлы хәбәр авылга яшен тизлеге белән таралып өлгерде. Бәйрәкә крестьяннары йөрәгендә ачу кайнады. Ләкин, авылда баштанаяк коралланган бер полк ак чехлар булганлыктан, берни кыла алмадылар. Ә аклар моңарчы колак ишетмәгән әшәкелекләрне дәвам иттерделәр. Аларга каршы нәрсә булса да әйтергә батырчылык итүчеләрне прикладлар белән кыйныйлар иде. Ак чехлар дистәләрчә крестьянның актык сыерларын суйдылар. Офицерлар кыр үрдәкләре атарга түгел, йорт казлары, йорт үрдәкләре атарга ауга йөри торган булып киттеләр.

Халык арасында кызылларның яңадан-яңа җиңүләре, якын тирәдәге барлык зур шәһәрләрне кулга төшерүләре турында хәбәрләр ишетелә башлады.

Шулай беркөнне Столыпин кулакларыннан гына торган ун йортлык Белов поселогына барып чыккан ак солдатлар бик күп самогон табып кайттылар. Табышны, беренче чиратта, офицерлар үзләре эләктерделәр. Ул көнне исереклар улавы төн уртасына кадәр ишетелеп торды.

Тавышлар тынып бер-ике сәгать үтүгә, авылның көньягында, Урыссу авылыннан килә торган юл өстендә бере артыннан бере дүрт гөрселдәү ишетелде. Снарядлар авыл өстеннән сызгырышып үттеләр дә, тау башына барып җиткәч, ут булып чәчелделәр. Шуның артыннан ук пулемет тавышы ишетелде. Икенче бер пулемет Бөгелмәдән килеп керә торган урам башында да такылдый башлады.

Торган саен пулеметлар саны артты, винтовка шартлаган тавышлар да, ешайганнан ешая барып, тоташ гөрелтегә әйләнде.

Беренче туп тавышы ишетелү белән, безнең сәкедә йоклаган 7 чех солдаты берьюлы сикерешеп тордылар һәм аннан-моннан киенеп чыгып сыпырдылар.

Озак та үтмәде, билгесез кешеләр безнең өйнең ишеген ачтылар. Бернича секундка гына шырпы яктысында өй эченә таба сузылган штыклар күренеп калды.

— Сездә солдатлар бармы? — дигән саф рус тавышы ишетелде.

— Бар иде, чыгып киттеләр, барысы җидәү иде,— диде әти.

— Әйберләре калмадымы?

— Караңгы бит, земляк, әйтеп булмый, чыра яндырып карамадык әле.

— Без земляклар түгел, товарищлар! — дигән сүз безнең семьяга җан кертеп җибәрде. Туплар гөрселдәве дә, урамдагы пулемет тавышлары да безгә куркыныч тоелмый иде инде. Кешеләрне өйдән чыгарып җибәрәсе килмәде. Ләкин «товарищлар» бездә озак тормадылар, ут кабызмаска кушып, чыгып киттеләр.

Озак та үтмәде, безнең өй алдында тагын күн итекле аяклар дөпелди башлады. Әти тагын ишек ачты.

---

[1] Ахыры. Башы 11 санда.

— Сездә солдатлар бармы? — диюгә, эти:

— Юк бит, товарищлар! — дип җавап бирде.

— Бирермен мин сезгә товарищны, сез шул товарищларны көтеп ятасыз икән! — дип җикеренде бер солдат.

Керүчеләрнең аклар икәнен белеп алгач, без куркышып мич аралыгына кереп тулдык. Безнең капка төбендә генә пулемет такылдый башлады. Тәрәзә аркылы өйгә ут яктысы керде. Солдатлар, «ай курде, кояш алды» дигәндәй, бик тиз юк булдылар.

Мәнә бервакыт авылның көньяк өлешендә, аккан көнбатышта кәчле «Ура!» тавышлары күтәрелеп китте. Бу тавышлар авылның урталыгында, аклар штабы урнашкан Гобәйдуллиннар йорты тирәсендә дә ишетелә башлады. Авыл өсте таң алдына кадәр пулемет, винтовка, туп, «Ура!» тавышлары белән гөр килеп торды.

Таң беленде. Мылтык, пулемет тавышлары сирәгәйгәннән сирәгәя барып, ахырдан бөтенләй тынды. Урыссу башындагы туплар Каразиреккә таба чигенеп баручы ак чехлар өстенә соңгы снарядларны атканда, көн яктырып килә иде инде.

Төнге хәллар көн уртасында гына ачыкланып беттеләр. Чехларның авылда эзе дә юк. Байракада бу юлы тагын 25 чех солдатының үләксәсе калды. Шулай итеп безнең авыл җирендә әҗәлләрен тапкан ак чехларның саны 200 гә тулды.

Күмүчеләрнең әйтүенә караганда, аклар арасында пуля тиеп үлүчеләр дә, арка ягыннан өч япьле тимер сәнәк белән чәнчеп үтерелгәннәре дә, хәтта пычак ярасыннан үлүчеләр дә булган.

Ә инде «Ура!»ны, авылга килеп керүче кызылармеецларга ияреп, авыл кешеләре дә кычкырганнар. Алай гына да түгел, әле мәдрәсәдән таралырга өлгермәгән шәкертләр дә, «Ура!» кычкырып, шау-шуны арттыруга зур өлеш керткәннәр.

## Гайникамал җиңги солдатлар белән мунча керә...

Баштагы килүләрендә Кызыл Армия сугышчылары квартирга безнең урам кешеләренә кермәгәннәр иде. Бу юлы безнең урамга да чират килеп җитте. Без аларны кунак итеп каршыладык. Әни хәзинәдә булганы белән тәмле итеп аш пешерде. Шулай, абыйлар күңелле генә аш ашап утырганда, күрше хатыны Гайникамал җиңги хәле бетеп йөгереп килеп керде дә безнең әнине үзләренә чакыра башлады:

— Сабираттәй, безгә кереп кенә чык әле,— дип ялварды,— үзем тел белмим. Заһит олауга киткән иде, солдатлар керде... Кунак сые әзерләдем, ә алар миннән көләләр. Берсе гел әдәпсезләнеп мине кочаклап үбә... Мин: «Моя мужик олау пошул», дип тә карадым. Ул аның саен кылтая, иптәшләре шырык-шырык көлеп торалар.

Безнең әни кече яшьтән Ждановта эшләп үскәнлектән, рус телен яхшы гына белә иде. Шуңар күрә җиңгигә ияреп, әлеге әдәпсез солдатны үгетләргә дип, өйдән чыгып та китте.

Әни күршедә озак тормады, көлә-көлә кайтып керде. Ул эшнең ничек булганын башта кызылармеец абыйларга русча сөйләп бирде. Тегеләр ашый торган җирләреннән кашыкларын куеп рәхәтләнеп бер көлештеләр.

Теге Гайникамал җиңгине кочаклап үпкән матур кызылармеец безнең әнине дә, барып керү белән, кочаклап алган икән. Әни аптырап тормаган, аның үзен аннан да катырак итеп кысып кочаклап алган да бит очыннан суырып үпкән. Чөнки, әни кергәндә шинелен салган булган икән теге, хатын-кыз икәнлеге әллә кайдан күренеп тора, ди.

Гайникамал җиңги шул ук көнне мунча якты. Әлеге матур солдат — Раиса белән, көянтә-чиләкләрен күтәреп, мунчага су ташыдылар.

Мунча өлгергәч, кызылармеецлар икешәрләп, өчәрләп мунча кереп кайттылар. Ә Раиса Васильевна мунчага Гайникамал җиңги белән барманчы икән. Гайникамал җиңги тагын шикләнә башлый. Шуннан соң Раиса Васильевна үзләре белән бер батальондагы татар кызын эзләп алып кайта. Анысы да сайлап алган кебек бик матур бер мишәр кызы. Татарча сөйләп аңлаткач, Гайникамал җиңги дә риза булып, өчәүләп мунчага киткәннәр алар. Ләкин җиңги мунча кергәндә дә тынычлана алмаган. Аз гына бернәрсә шытырдаса да: «Әнә, солдатлар килде!» дип әсәрләнеп кала икән.

— Син нинди солдатлардан куркасың. Менә без инде ул солдатлар! — ди икән Асия.

— Ир солдатлардан куркам.

— Алар бит кешегә тимиләр.

— Ышан син ирләргә!

— Ә бит менә безгә берәүнең дә тигәне юк, айлар буенча бергә фронтта йөрибез.

— Анда сезнең үз ирләрегез бардыр.

— Юк шул. Без әле кызлар. Безнең сәйгән егетләребез бар, әмма алар еракта...

Гайникамал җиңги кызларның тигез, матур, таза мускуллы гәүдәләренә, үргә карап торган тыгыз күкрәкләренә күз текәп, сокланып утырганда, мунча янында гына мыгырданган ирләр тавышы ишетелеп китә.

— Ир солдатларыгыз килә! — дип кычкырып җибәрә Гайникамал җиңги.

Кызлар:

— Булмас, булмас, кызылармеецлар мунча керүче хатын-кызларны куркытып йөрмәсләр! — диләр дә юынуларын дәвам итәләр. Чынлыкта әлеге мыгырданып йөрүче кеше кызылармеец түгел, ә Заһит абый үзе булып чыга. Ул олаудан кайтып атын туарган да өйгә кергән. Керсә — хатыны юк.

— Әниең кая? — дип сорый ул кечкенә кызыннан. Ә кызчык:

— Әнекәй талдат абыйлар белән мынсага китте,— дип тәкелдәп тора.

Кайсысы кырынып, кайсысы хат язып утыручы кызылармеецлар Заһитны игътибарга да алмыйлар.

Заһит абзый мунчаны бер кат әйләнеп чыгып, анда үз хатыны тавышын ишеткәч, мунча чоланына күз төшергән. Ә анда хатын-кыз күлмәге белән бергә хәрби киемнәр: шинель һәм гимнастеркалар эленеп тора икән. Заһит абзый чак һушыннан язмыйча калган. Ул ашыга-кабалана штабка барып жалу биргән. Штабта да моны чынга алмаганнар:

— Берәр аңлашылмау бардыр, үзең яхшылап тикшер. Һәртөрле гаделсезлекләргә, кечләүләргә каршы сугыша торган армиянең солдатлары хатыннар көчләп йөрмәс! — дигәннәр аңар.

Гайникамал җиңги белән кызылармеец кызлар мунчадан чыгарга әзерләнгәндә, Заһит абзыйның кабат кайтып мунча алдында нишләргә белми басып торган чагы икән.

Беренче булып ишекне ачкан Асия:

— Абый кеше, китегез, мин киенәм! — дип кычкырып җибәргән.

Заһит абзыйны танып алган Гайникамал җиңги дә:

— Сиңа әйтәм, без мунчаны кызлар белән керәбез бит. Алар киенеп чыкканчы читкә китеп тор! — дип эндәшкән.

Шуннан соң гына Заһит абзый тынычланган.

Бу часть безнең авылда нибары ике генә көн торганлыктан, без Асия апалар белән якыннан танышырга өлгермәдек. Шулай да Асиянең авылыбызда истәлеге калды. Кешеләр аның бик матур итеп җырлавын ишеткәннәр, бер туктаусыз эшләвен, үз частендагы кызылармеецларның эчке киемнәрен юып бирүен, бер квартирага туры килгән иптәшләренә ашарга әзерләргә дә өлгерүен күргәннәр.

Аңа кадәр безнең Бәйрәкә авылында Асия исемле хатын-кыз бер дә булмаган. Менә шул кызылармеец Асиядан соң, Бәйрәкәдә күпме кыз балага Асия исеме кушылды икән!? Әле хәзер дә бездә Асияларны дистәләп санарга була...

Төнге сугыштан соң авылга бик күп кызылармеец килде һәм шул көнне үк Беренче Петроград дивизиясенең штабы да Бәйрәкә авылына килеп, Зәки Мусин йортына урнашты...

## Якты көннәр килде

Бәйрәкә авылында гражданнар сугышы чорының бер үзенчәлеген искә төшереп үтми булмый. Ул чакларда, авылга Кызыл Армия частьлары килү белән, авыл Советы, Волбашкарма, Ярлылар комитетлары эшкә тотыналар иде. Армия өчен азык-төлек, олаулар кирәк булса, авыл Советы аркылы гына эш итәлә. Хәрбиләрне квартираларга урнаштыру да авыл Советы аркылы башкарыла торган иде.

Авылга аклар керсә, киресенчә, бөтен нәрсәгә хәрби кеч хуҗа була. Алар бертөрле дә җирле властьны танымыйлар, авыл Советлары түгел, патша яки вакытлы хөкүмәт чорында сайланган старосталарны да бар дип тә белмиләр. Бөтен эшне «Талау өчен закон кирәкми» дигән мәкаль буенча хәл итәләр иде аклар.

Дивизия штабы килеп урнашу белән авылда, авыл Советының барлык активлар катнашында, утырыш үткәрелде. Бу утырышта 60 олау хәрби йөкне исән-сау илтеп тапшырганнары өчен Бәйрәкә авылы кешеләренә дивизия җитәкчеләренең рәхмәт язуы укылды.

Ләкин Вәли Җәббаровның исәнме, түгелме икәнлеге эчне бик пошыра иде.

Менә беркөнне, кичкә таба, алама киемле, тишек-тошык чабаталы, хәерче кыяфәтендәге бер кешенең авылга таба килүен күрделәр. Авылның ул ягында дозорлар тора иде әле. Алар бу картны туктатып, турыдан-туры штабка алып килделәр. Аны дивизия штабында беренче булып Насыйр Габделхаков таныды һәм «Вәли абзый!» дип барып кочаклады. Аның күзләрендә шатлык яшьләре мөлдери иде.

Җәббаров соңгы биш көн эчендә үз башыннан ниләр узганын штабта сөйләп бирде:

— Мин үземне атачакларын белә идем,— дип башлады ул сүзен.— Шулай да исән калудан өметне өзмәдем. Капка төбендә ук хәйлә капчыгын каккалый башладым. Мине урманга алып баручыларның берсе рядовой солдат, икенчесе капрал булып чыкты. Үзем русчаны да начар белгәнгә салыштым. Тегеләр чәхчә сөйләшәләр. Шулай да сүзнең ни турында барганлыгы аңлашыла. Капрал мине ату ягында, рядовой солдат: «Карт крестьянны нигә атарга? Ул безгә каршы корал күтәреп сугышканмени?» ди.

Менә урманга барып кердек. Беләсез, аз гына баргач та, бер алан бар. Менә шул аланга кергәч, ат алдыннан бер куян чыгып чапмасынмы. Авылда каз-үрдәк «аулап» өйрәнгән капрал бик дәртле сунарчы икән, куянга төзәп атты да җибәрде. Бичара куян бер егыла, бер тора китеп барды. Ә капрал аны куа китте.

Ул куян куа, мин үз эшемне җайларга маташам. Кесәмнән шырпы кабы зурлыгында гына итеп җыеп-җыеп бәйләнгән кырыгар, алтмышар сумлык «керенка»ларны солдатка сузам. Солдат башта аңламый тора. Аңлап алгач, акчаларны тиз-тиз генә кесәсенә алып тыга. Ул арада капрал да куянны тотып килеп җитте. Без тагын кузгалдык. Урман эчендә бер чакрым чамасы кергәч, зур гына аланга барып чыктык. Ат пошкырынгалый башлады. Атны туктаттым да алга карадым. Юл буендагы ике иманга ике шинель элеп куелган икән. Солдатлар аны игътибарламадылар. Ул арада капрал арбадан төште дә миңа алга таба егерме адым атлап туктарга боерды.

— Мине нишләтмәкче буласыз? — дим.

— Мә, бу көрәкне ал да үзең күпме телисең, шул тирәнлектә чокыр казы.

— Нигә ул чокыр?

— Үзеңне күмәргә. Без сине атабыз!

— Ни өчен?

— Полковник приказы шулай.

— Приказны укып күрсәт син аңа,— диде солдат.

Теге кесәсеннән кәгазь алды да тизләп укып китте.

— Мин чокырны казымыйм,— мин әйтәм.— Беренчедән, үземә үзем чокыр казырга мин дурак түгел, икенчедән, мин Вәли Җәббаров түгел.

— Ничек син Җәббаров түгел? — дип кабарына төште бу.

— Юк, минем беркайчан да Җәббаров булганым юк. Мин Вәлидов Нәби булам. Ә Вәли Җәббаров, без чыгып киткәндә, капка төбендә басып калды. Аның бүреге шундый, туны мондый иде,— дип, кырпулы бүрек, камалы тунны ишарәләп күрсәттем.

Капрал тәмам аптырап калды.

Мин тагын сүзне дәвам иттерәм:

— Әгәр дә минем урында Вәли Җәббаров булган очракта да сез ата алмас идегез.

— Ни өчен?

— Чөнки безнең әйләнә-тирәдә хәзер кызыллар. Аз гына шартлау тавышы чыгу белән, алар безнең өчебезне дә тотып ташлаячаклар. Әнә ул шинельләрне күрәсезме? — дидем.

Капрал тиз генә арбага менеп утырды да:

— Я, нишлибез? — дип пышылдады.

— Бу кешенә калдырыйк. Ә полковникка Җәббаровны аттык, диярбез. Җәббаров барыбер качкандыр инде. Мондагы буталуга без гаепле түгел бит. Ә бу агай кая да булса китеп торсын.

Капрал миңа текәләп карап торгач:

— Согласенмы? — диде.

— Согласен — мин әйтәм — только минем атны староста Ганиев Гарифка кайтарып тапшырыгыз, ул аны минем хатынга илтеп бирер.

Алар шулай китеп бардылар. Ә мин бөтенләй кире якка — Әсәй авылына таба юл тоттым. Анда төнге сәгать уникедә генә барып керелде. Кешеләр танымасын дип, иске-москы киемнәр табып кидем дә икенче көнне Митрәйгә, өченче көнне Урманай, Стәрле авылларына барып чыктым...

Вәли Җәббаров штаб өчен кайбер кирәкле мәгълүматларны биргәннән соң, командирлар, комиссарлар белән кул кысышып күрешә дә, өйннән китертелгән киемнәрне киеп, волость башкармасы йортына китте. Анда аны дистәләрчә кешеләр, совет активлары шатланып каршы алдылар.

Җыелган кешеләргә Җәббаров речь сөйләде. Ул халыкларның бөек юлбашчысы Владимир Ильич Ленинның терелүе турында үзе әле бүген генә дивизия штабында ишеткән шатлыклы хәбәрне әйтте. Аннары Бәйрәкә кешеләренә дивизия штабының соңгы рәхмәтен тапшырды. Ул бик арган булса да, ул көнне караңгы төшмичә өенә кайта алмады.

Иртәгесен, Кызыл Армия сафына ирекле булып китәргә теләүче дистәләрчә батраклар, ярлы крестьян уллары дивизия штабына килделәр. Беренче булып көтүче Хәйретдин Нуретдины, Гариф Зарипов, Мөхәммәдиев, Хаҗи Гание килеп язылдылар.

Шул көнне кичкә таба ирекле булып фронтка китәргә теләп 150 гә якын кеше берьюлы килде. Алар июль аенда аклар тарафыннан мобилизацияләнеп Самарага җибәрелгәч, анда бунт күтәреп, мылтыкларын ташлап кайткан 1894—97 елларда туган яшьләр иделәр.

Әллә штабка бик ашыгыч көнчыгышка китәргә приказ килгәнгәме:

— Сезгә шушы көннәрдә мобилизация булачак, шунлыктан хәзергә кайтып торыгыз,— дип җавап бирделәр аларга.

Яшьләр бераз кәефсезләнебрәк таралыштылар. Ләкин бу уңышсызлык өчен алар үзләрен гаепләделәр, кулга корал эләккәч, бердәм булып акларга каршы сугышмыйча, качып кайтуга үкенделәр...

Төне буе ябалак-ябалак кар яуды. Ә иртән, авылда бер генә взвод кызылармеецны калдырып, штаб көнчыгышка күчеп китте.

Дивизия штабы көнчыгышка күчеп киткәннән соң икенче көндә авылда тагын коточкыч вакыйга булып алды. Дөнья тынычланып җитеп, мәктәпләрдә укулар башланып киткәч кенә, авылның бер очында кабат мылтык, пулемет тавышлары ишетелде.

Укытучыбыз Фазыл абый тәрәзәдән карады да, куркынып:

— Бу дошманнар каян килеп чыктылар тагын?.. Балалар, тәртип белән генә чыгыгыз да өйләрегезгә кайтыгыз! — диде. Үзе дә безнең белән өй алдына чыкты. Ашыгуым белән китапларымны алырга да онытканмын икән, мин кеше чыгып беткәч, мәктәпкә кире кердем һәм өй алдындагы түшәм тишегеннән Фазыл абыйның чормага менеп киткәнен күреп калдым.

Өйгә кайтканда безгә кылыч тоткан, мылтык аскан атлы казаклар очрады.

Без, турыдан-туры өйгә кайтмастан, кешеләр агылган якка таба юнәлдек.

Авыл уртасындагы зур урамда, Наһар Садыйгы дигән кешенең өе турында, бик күп казаклар ике кызылармеецны газаплыйлар. Аларның берсе, без барып җиткәндә, кар өстенә ауган, аның йөзеннән чәчрәгән кан ак карны чуарлаган иде. Икенче кызылармеец баскан килеш тора. Йөзе канга баткан, ике җиңеннән җиргә кан агып тора. Казаклар аның өстенә карап акыралар, җикерәләр, кылыч сырты белән башына, муенына, авызына сугалар.

Без өлкән кешеләрнең сүзләрен тыңлый-тыңлый кайттык.

Кызыл Армия инде Бәләбәйне дә алган икән. Бәйрәкәдәге взвод ялга чыгарылган кызылармеецлар икән. Алар тынычлап мунча кереп ял итеп ятканда, әллә кайдан

казаклар килеп чыкканнар. Бу ике кызылармеец, дошманнарны күрү белән, ата башлаганнар, шуның белән башка иптәшләренә яшеренергә мөмкинлек биргәннәр.

— Үзләре дә гамьсез ятканнар икән! Дозорлары да булмаган, ахры. Разве хәрби кешеләргә шулай ярый,— диде озын буйлы Тимербай абый.

— Казакка аңар көнгә йөз чакрымны уравы бернәрсә дә түгел...

Бер взвод кызылармеец юкка чыкты. Хәзергә, урамнарда күп санлы казаклар йөреп торганлыктан, алар яшеренергә мәҗбүр булганнар. Крестьяннар аларны базларга, чормаларга яшергәннәр. Ә безнең Гарифә әбиләр йортына мунча кергән җиреннән чыгып йөгергән кызылармеец барып кергән булган. Әбиләр аны урынга яткырганнар да өстенә кием-салым япканнар. Казаклар килеп кергәндә, бабай тегенең янында ясин укып утырган була икән. «Больной тифом» дигәч, казаклар чыгып сызганнар.

Казаклар авыл арасында йөреп торганда, урман ягыннан бик күп атлылар килгәне күренде. Озак та үтмәде, озын сөңгеле кызыл казаклар отряды авылга килеп тә җитте. Авылның өлкән ирләре:

— Үзебезнекеләр!.. Кызыллар!.. Донскойлар!.. дип кычкырыша башладылар.

Акларга корырак булып китте. Тиз-тиз генә атларына атланып, авылдан чыгып сыздылар.

Кояш баеп барганда, акларны куа киткән донской казаклар авылга җырлап кайтып керделәр. Атлары ак күбеккә баткан булуга карамастан, кызыл казаклар бик шат иделәр.

Алар акларны Ыкка чаклы артларыннан калмый куып барганнар. Тегеләр әле ныклап катып өлгермәгән боз өстенә кереп киткәннәр. Атлары ни йөзә алмый, ни атлап чыга алмый икән. Менә шунда безнең «донскойлар» тегеләрнең «арт сабакларын укытканнар». Пулеметлардан атып бөтенләй кырып бетергәннәр.

Яшь егетләрдән торган Дон казакларына сокланмаган кеше калмагандыр. Аларның батырлыклары турында ак сакаллы картлар да үлгәнче сөйләделәр. Ә без, малайлар, нечкә озын таяклардан сөңге ясап, таяк атка атланып кызыл казаклар булып уйный торган булып киттек...

Шул вакыттан соң бер-ике көн үткәч, 300 гә якын авыл яшьләре һәм 1893—97 нче елларны туган кешеләрнең бары да урамга чыктылар. Элек тә солдатка алынган яшьләрнең унар-унбишәр кешелек төркемнәргә бүленеп, гармонь уйнап урам буйлап җырлап йөрүләре гадәткә кергән иде. Быел алай булмады: авылдагы барлык яшьләр барысы бергә җыелдылар да бер тавыштан уйнаган берничә гармоньга кушылып йөзләгән кешеләр барысы бергә җырлап йөрделәр:

Без китәбез иртәгә
Шинель салып җилкәгә.
Китмәс идек, һай, иртәгә,
Аклар тия теңкәгә.

Ишек алдым таш кына,
Безгә дошман хассына.
Безгә хассынган буржуйның
Муены — аяк астына.

Безгә буржуйлар кушалар
Кызылармеец булмаска.
Малыбыз түгел, җаныбыз фида
Советский властька!

Һәр куплет җыр җырланып бетү белән, тынлык башлана. Берничә минутка гармонь тавышы гына ишетелеп тора. Ул арада кем дә булса берәү яңа җыр уйлап чыгара һәм җырны бер кат үзе генә җырлап чыга. Тыңлап баручылар җырны шунда ук отып алалар да, болытларга менеп төшәрлек тавыш күтәреп, беравыздан җырлап җибәрәләр.

Менә шулай бере артыннан бере яңа җырлар чыгара-чыгара, базардагы халык исбек зур төркем урам буенча алга бара...

1893—1897 елларда туган кешеләр арасында өйләнеп тормыш итәргә керешүчеләр дә бар иде. Андыйлар: «Өйләнгән кешегә өеннән чыгып йөрергә ярамый», дигән иске кагыйдә буенча урамга чыгып йөрергә читенсенебрәк тордылар.

Әмма көчле җыр, музыка тавышы аларны да яшьтәшләре янына тартып чыгарды. Шундыйларның берсе — мәһабәт озын буйлы, матур ак йөзле, коңгырт сары чәчле Тимербай Шафиков иде. Ул, яше 17 гә җиткәнче, кешеләргә ялланып ашлык сугып йөрде. 17 яшькә чыгу белән, солдатка алынды һәм гренадерлар полкына җибәрелде. Октябрь революциясе көннәрендә ул Кызыл Гвардияче иде инде. 1918 ел январенда аның яшендәгеләр демобилизацияләнеп, өйләренә кайттылар. Йортта авыру әнисе белән әтисе карттан башка кешесе булмаганлыктан, Тимербай өйләнергә ашыкты.

Тимербай урамга чыкты һәм, гадәте буенча, иң алгы сафка барып басты.

Тимербайның өендә карт әтисе, үпкә авырулы әнисе һәм хатыны белән 40 көнлек матур кызы бар. Нәни булса да, ул әтисенә елмаеп күрсәтте инде. Әмма Шафиковның күңелендә фронтка китми калырга диган уй юк. Ул үзенең Совет власте өчен кирәк булса, җанын да фида кылырга тиешлеген белә, чөнки аның ата-бабалары борын-борыннан җирсез интекkәннәр. Бабасы — Сукыр Вәли. Аның уң күзен алпавыт мулла Гобәйдуллин чыбыркы белән сыдырып чыгарган. Ә Тимербайның әтисе белән бертуган агасы Шаһвәли — Вәли Җәббаровның якын дусты, көрәштәше —1905 елгы күтәрелеш вакытында жандармнар тарафыннан атып үтерелгән кеше.

Янгын сарайлары янындагы тар урамнан чыгып барган яшьләргә Вәли абзый Җәббаров очрады.

Арадан берәү:

— Вәли абзый, болай урамда җырлап йөргәнгә сез ачуланмыйсызмы? — дип сорады.

— Ачулану кая ул? — диде Җәббаров.— Мин сезнең болай оешып йөрүегезгә бик шат. Ә җыр ул безнең өчен җомга намазыннан да кадерлерәк. Сезнең болай иркенләп йөрүегез хөррият җимеше бит...

Вәли Җәббаров яшьләрне әдәпле булырга өндәде һәм теге вакыттагы кебек ишәк ватып, кибет басып йөрергә ярамаганлыгын, һәр җирдә совет законнары буенча гына хәрәкәт итәргә кирәклеген аңлаткач, саубуллашып китеп барды.

Җыр дәвам итте.

Йөзләгән кешеләр иртәгә кулга корал алып дошманга каршы китәчәкләр. Алда аларны каты сугышлар, салкын окоплар көтә. Кискен көрәшләрдә бу зур төркемнең бәлки яртысы да калмас. Ләкин авыр көрәшләр, канлы сугышлар шушы кешеләрнең җиңеп чыгуы белән тәмамланыр.

Әле хәзер кемнең кабере кайда булачагы билгесез. Бу кешеләрнең 59 ы Чапаев дивизиясенең 223 нче полкы составындагы татар батальонында оста сугышчылар булып дан казаначаклар. Әнә алда — гармоньга кушылып җырлап баручы Солтангали Муллагалиев. Ул шул батальонда взвод командиры дәрәҗәсенә күтәреләчәк һәм ак казакларга каршы атака вакытында геройларча сугышып үләчәк. Менә, калын тавыш белән җырлап баручы, зур гәүдәле, киң җилкәле Мөҗәһит Латыйпов. Ул быел ук, Уфаны аклардан азат иткәндә, һәлак булачак. Әдһәм Латыйпов, Ибраһимов, Галиев, Шакиров — Урта Азиягә, Врангельгә каршы фронтларга китеп, яңа, тарихта беренче Совет дәүләтен яшәтү өчен үзләрен корбан итәчәк кешеләр бит болар. Әнә Тимербай Шафиков белән янәшәләп баручы яшьтәше Кәримов Кашфетдин. Аның да кечкенә улы Хәмзә бар. Ул да, Чапаев дивизиясендәге Бәйрәкәләр взводында отделение командиры булганы хәлендә, яшь Совет дәүләте өчен башын салачак. Ә Тимербайны, Чапаев үзе сайлап алып, 223 нче полк белән дивизия штабы арасында пакетлар йөртүче атлы элемтәче итеп билгеләячәк. Төсе-бите, буе-сыны белән данлыклы полководецның үзенә охшаган Тимербай бик күп төрле авыр, кыен йөкләмәләрне үтәгәч, Льбищега барып җитәрәк, ак казаклар кулыннан китәчәк...


Әйе, алар алда үзләрен нәрсә көткәнен беләләр, аңлыйлар. Шуның өчен икс-өч җырның берендә:

Малыбыз түгел, җаныбыз фида
Советский властька! —

дип җырлыйлар...

# *Эжен Потьеның тууына 150 ел*

## «ИНТЕРНАЦИОНАЛ» АВТОРЫ



Эжен Потье

*Коммуна җиңелде... ә Потье „Интернационал"ы аның идеяләрен бөтен дөньяга таратты, һәм хәзер ул һәркайчандагыга караганда да тереж.*

*В. И. ЛЕНИН.*

### Сугыш

Сугыш! — Шундук безнең колакларга
Козгын карылдавы ишетелде:
«Алга!» — Исебез китми ләкин моңа:
Чөнки сугыш бара һәр көнне.

Һич югында, каска кигән өрәк
Ат кярләп, чабып уза да
Маскасыннан чыгып, какъ яңагын
Шакылдатып көлә дөньяга.

Ике сыйныф яши борынгыдан
Килешү белмәс сугыш хәлендә:
Бүре базы казыла базарларда,
Семья ызгышлары һәр илдә.

Юк өйдә дә тынгы, юк беркайда —
Каторгага мөмкин китүең.
Талау тыела, налоглары ләкин
Талаулардан бер дә ким түгел.

Канга сусау аңкый һәр төбәктә,
Яңарып кайта кыргый искелек.
Ласенерның[1] пычак кулында гел,
Этлек эшли Кастэнь[2] гел көлеп.

Солдат булган улың — «хөрмәт» аңа!
Һәм полклар, кара, азмы соң?!
Итчеләре сугымлыкка тиздән
Җибәрерләр җыйнап барысын.

Каурый таккан индеецлар кук без —
Рәван җаннар. Ярыш башлыйбыз:
Һәм кырмыска оялары сыман
Илләр таптап, бутап ташлыйбыз.

Арысланнар ерткычлыгы төсле,
Лингез төсле кайный дошманлык.
Инҗил тотып апостоллар йөзә,
Шул упкынга таба юл алып.

Халыкларның ачуын кайнатырга,
Котырталар берсен берсенә.
Көньякта да, төньякта да көн-төн
Шовинистлар чиный речь сөйләп.

Атыла туплар... Яңа башкалалар.
Кан күленә күлләр өстәлә.
Җитәр иде бу кан, бөтен Кешелек
Аны шәрап итеп эчсә дә.

Җиңелгәннең баш очында атлар
Җиңүчене зурлап кешниләр.
Дан-ярканат, җәеп пар канатын,
Оча төтен, ялкын өстеннән.

Сугыш! Сугыш! Кешеләрне тетеп,
Сөякләрен әзер кимерергә.
Үзе көтә язны, табигатьнең
Терелүен. Кабат җимерергә.

*Париж 1857*

---

[1] Ласенер — үтерүче һәм талаучы.
[2] Кастэнь — үз пациентларын агулап үтерүче врачлар.

# Икмәк нәрсә сөйли

Еш кына мин ишетәм шаян сүзләр:
«Киселгәндә, икмәк пычакка
Нәрсә сөйли? Дустын-ашказанын
Мактыйдыр ул бәлки бу чакта?»
Ә икмәкнең агы, карасы да
Була ашау дәртен китергеч.
Беләсеңме, икмәк ни сөйли?
Беләсеңме, имкәк ни сөйли?
«Гомер саклау, — ди ул, — минем эш».

«Алтын уңыш» дигән гади сүзнең
Кемнәр яхшы белә мәгънәсен?
Өсте-башы тиргә баткан агай
Буразнадан килә, күрәмсең?
Байның эшләмичә тамагы тук,
Игелек юк җиргә аңардан.
Беләсеңме, икмәк ни сөйли?
Беләсеңме, икмәк ни сөйли?
«Мине чәчкән куллар — сезгә дан!»

Мәгърифәт ул тиеш интексә дә,
Барлык көчен җирнең ачарга.
Тудырса да кан һәм газап белән,
Бала тудыру — шатлык анага.
Көрәшләрдә яшьләй кем чыныккан,
Шул корычка, ташка тиң икән.
Беләсеңме, икмәк ни сөйли?
Беләсеңме, икмәк ни сөйли?
«Тегермәнче мине он иткән».

Икмәк җирдә күп булырга тиеш,
Һава төсле — көн дә җитешле.
Ә син бөлгенлектә... Тик бу синга
Яңалыкмы, хезмәт кешесе?
Хәерчелек чыңлый чылбыр кебек,
Ростовщиклар аңа өстәлә.
Беләсеңме, икмәк ни сөйли?
Беләсеңме, икмәк ни сөйли?
«Ут көчәя кызган мичләрдә».

Туендыра безне җир сулары,
Тәнгә күчкәч канга әверелә.
Без табигать белән бергә шулай.
Бу бәхетле дуслык — мәңгегә.
Табигатьнең бүләк итүен күреп
Безгә якты акыл, алтын тән.
Беләсеңме, икмәк ни сөйли?
Беләсеңме, икмәк ни сөйли?
«Мин тантана итәм шатлыктан».

*1867*

# Үрмәкүч җәтмәсе

Каплап алган күкне җәтмә белән,
Күренмичә озак яшәмәк.
Кешеләрнең акылын агулый ул,
Җирне черетә, тәссез хәшәрәт.

Сукыр булдык озак, явыз гарип
Каплап торгач шулай күзебезне.
Таш капчыкка җыеп, миебезне
Эчә! Кем ул? Алла! Нәкъ үзе!

Капиталы барга — тырнак биргән,
Тизәгеннән поплар ясаган...
Үрә җәтмә... Кеше, туздыр аны.

Тарт та ерт син. Азар ул һаман,
Явызлыклар эшләр ул күбрәк.
Җәтмәләрен элгән йолдызларга!
Үрмәкүчне тот та сыт тизрәк!

*Нью-Йорк 1875*

# Җиргә ничә яшь

Йөз мең яшьме җиргә? Бер дә аның өчен
Күп түгел бу. Ләкин дөресме соң җавап?
Белеп булмый моны инҗилләрдән карап.
Геологлар гына әйтер безгә дөресен.

Күпме яшь булса да, ул — сырхау лабаса,
Газап үз куенына алган бит бу Җирне.
Социологлар әйтер «Бу — сабыйлык чире».
Поплар, сугыш, чума, биржа — күпме җәфа!

Күпме гасыр инде сөйли карчык-корчык
Алла, шайтаннарны әкиятләргә кушып.
Имеш, дөнья карт ул, җитә ахыр заман...

Гөнаһ, оҗмах, диеп сөйләнәләр алар.
Алтын башак бизи җирнең өстен һаман,
Кояш котлый аны: «Сәлам сиңа, балам!».

*1880*

Ә. БАЯНОВ тәрҗемәләре.

# Язучының иҗат портреты

*Флун Мусин*

## Нык адым белән

Әдәби иҗат дөньясына берәүләр шаулап-гөрләп, гомум игътибарны җәлеп итеп, кайчак хәтта җәнҗал куптарып килеп керәләр. Икенче берәүләрнең әдәбиятка килүе исә күп мәртәбә тынычрак шартларда үтә. Аларның иҗат юлы, гадәттә, бер чиктән икенче чиккә ташланулар, озак эзләнүләр белән характерлы була. Андый язучылар тиз генә зур ачышларга да ирешмиләр. Әмма аларның кечкенә генә уңышы да төпле, нигезле була һәм законлы рәвештә зуррак уңышларга җирлек әзерли. «Модный» авторлар белән мавыгучы тәнкыйть мондый артык күзгә ташланып тормаган иҗат кешеләрен еш кына озак вакытлар күрми кала. Әмма көннәрдән бер көнне моңарчы тәнкыйть игътибарыннан читтәрәк йөргән авторыбыз үзен кинәт көнә сиздереп куя. Һәм без, беренче мәртәбә күргәндәй, аңа гаҗәпләнеп карыйбыз.

Атилла Расих белән дә шундыйрак бер хәл булды бугай. Инде 20 елдан артык иҗат эше белән шөгыльләнсә дә, әдәби тәнкыйть аны үзенең игътибары белән артык иркәләмәде. Күп еллар буе ул, ничектер, әдәбиятны алга әйдәп баручылардан битәр, аңа фон тәшкил итүче авторлар сафында, күләгәдәрәк килде кебек. Ә менә соңгы 3—4 елда аның иҗаты бермә-бер активлашып-күтәрелеп китте, А. Расих җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгенә басты.

Әмма язучының соңгы елларда күзгә күренеп үсүе беренче карашка гына көтелмәгәнрәк бер хәл булып тоелырга мөмкин. Әгәр А. Расихның моңарчы язган барлык әсәрләренә, бөтен иҗат юлына күз ташласаң, аның кыенлыклар аша, әмма нык адым белән әдәбиятта үз урынын табуга килүен күрәсең.

Язучының тормыш юлы гади дә, гыйбрәтле дә. Башта ул ФЗӨ мәктәбендә токарь һөнәренә өйрәнә, аннары Казан дәүләт ветеринария институтында укый. 1940 елда армиягә алынып, Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр алгы сызыкта була, Берлинны яулап алуда катнаша. Сугыштан кайткач, элеге институтта аспирантура бетереп, кандидатлык диссертациясе яклый һәм озак еллар буе укытучы булып эшли. Шул ук вакытта шактый актив төстә әдәби иҗат эше белән дә шөгыльләнә. Язучының беренче хикәясе А. Расих псевдонимы белән 1934 елда «Чаян» журналында дөнья күрә. Һәм шунысы кызык, А. Расихның әдәбияттагы беренче адымнары Муса Җәлил исеме белән бәйләнгән. Бу хакта язучы,

патриот шагыйрьне зур хөрмәт белән искә алып, болай ди: «Ул вакытта Язучылар союзының рәисе булган Муса Җәлил минем беренче хикәяләремә игътибар итте. Ул үзенең миңа өмет баглавы, җылы сүзе белән миндә зур дәрт уятты. Мин соңыннан белдем, минем пионер чакта язган хикәямне дә бастырып чыгаручы шул ук Муса Җәлил булган икән, чөнки ул нәкъ шул елларда «Октябрь баласы» журналында редакторлык иткән. Моны мин үзем өчен бәхет дип саныйм».

Әйтеп үткәнебезчә, язучының әдәбиятта үз урынын табуга килү юлы турысызыклы түгел. Ул каләм көчен төрле жанрларда сынап карый. Иҗатының башлангыч чорында күбрәк сатира-юмор өлкәсендә эшли, иҗат энергиясен тормыштагы һәм кешеләр аңындагы искелек калдыкларын тәнкыйтьләүгә юнәлтә. Бу яктан «Кызыл чүлмәк» хикәясе игътибарга лаек. Кәннәрдән беркөнне сыер абзарындагы чокырдан бер чүлмәк алтын тәңкә табу Шәмсетдин абзыйның тыныч кына аккан тормышын чыгырыннан чыгарып җибәрә яза. Аның күңелендә ике Шәмсетдин үзара ызгыша-тартыша башлый. Аларның берсе чүлмәкне үзендә калдырырга өнди, ә икенчесе гомуми интересларны шәхси интереслардан өстен куярга, алтын тәңкәләрне хөкүмәткә тапшырырга куша. Геройның шушы каршылыклы кичерешләрен автор шактый оста һәм тормышчан итеп күз алдына бастыра алган. Әмма, гомумән алганда, 30 елларда язылган юмористик хикәяләр яшь авторның эзләнүен күрсәтүче өйрәнчек әсәрләр булып торалар. Һәм алар, беренче чиратта, шушы яктан игътибарга лаеклы да. Аерым хикәяләрдә әле авторга әдәби тәҗрибә җитмәве, аның укучыга вәгазь-нәсихәт укырга омтылуы сизелә.

Бөек Ватан сугышы елларында А. Расихның әдәби эшчәнлеге бермә-бер активләшә. Ул үзенең төп игътибарын фронт кырларына, сугышның дәһшәтле вакыйгаларын сурәтләүгә юнәлтә. Монда язучыны барыннан да бигрәк совет солдатының рухи ныклыгы, нинди генә авыр шартларда да туган илгә, социализм идеясенә турылыклы булып калуы кызыксындыра.

Менә «Ютазы егете» исемле хикәя. Язучы биредә сугышка керү белән пленга эләккән яшь солдат Бари турында сөйли. Моңа кадәр немецларның ерткычлыгы турында газетадан укып яки сөйләүләр буенча гына ишетеп белгән бу егет дошманның кансызлыгын үз күзе белән күрә, үз җилкәсендә татый. Әмма солдат намусына тап төшерми.

«Якташларым» хикәясендә беренче карашка ничектер шактый гамьсез күренгән, кәтта хәрби уставка да бик буйсынырга теләмәгән солдатларның — кичәге колхозчыларның — сугыш кырында арсландай көрәшүләре тасвирлана. А. Расихның бу хикәяләре дәһшәтле вакыйгаларның кайнар эзеннән язылганнар. Шунлыктан аларның кайберләрендә беразашыгучанлык, вакыйгаларның тышкы ягы белән чикләнеп калу сизелә, кеше характерын бөтен тирәнлегендә ачу җитенкерәми.

Язучы эзләнүләрен дәвам итә, каләмен яңадан-яңа жанрларда сынап карый. Ул маҗаралы әсәрләр жанрына күчә. «Бәхет орлыклары» һәм «Хәвефле сынау» повестьларын иҗат итә. Мавыктыргыч сюжетка корылган һәм җиңел тел белән язылган бу әсәрләрне укучылар, бигрәк тә мәктәп балалары, зур кызыксыну белән каршы алдылар, һәм алар әле бүген дә әһәмиятләрен югалтмыйлар.

Еллар узу белән язучының каләме шомара, әдәбиятка карашы тирәнәя һәм җитдиләнә бара. Болар барысы аны күләмле эпик формага этәрә. Шулай А. Расихның беренче зур әсәре — «Дустым Мансур» романы туа. Авторның моннан соңгы иҗаты аның чын таланты нәкъ менә эпик жанрда ачылуын раслый да.

«Дустым Мансур» романы —20—30 еллар тормышын татар әдәбияты практикасында үзенчәлеклерәк яктырта торган әсәр. Ул шушы авыр, каршылыклы елларда крестьянның эшчеләр сыйныфы сафларына аяк басуын һәм шушы процесста яшь кеше характерының формалашуын сурәтләүгә багышланган. Күрәсез, бу бик кызыклы һәм әһәмиятле проблема. Романда утызынчы еллар башындагы иске тормыштан аерылып, яңа тормышка күчеп өлгермәгән провинция шәһәре кешеләренең каршылыклы, ыгы-зыгылы тормышын тасвирлауга киң урын бирелә. Иске тормыш фәлсәфәсе, психологиясе һәм принциплары әле кешеләр аңында, яшәешендә үзләрен нык сиздерә. Гражданнар сугышы вакытында аклар ягында торып көрәшкән, хәрби коммунизм елларында мыштым гына йөреп, нэп башлануга тиз арада баеп алган кассапчы Габделбәрләр үткән тормышның кире кайтуына өметләрен өзмиләр. Ярлы һе-

нәрсә Хисам исә һаман да бетәя алмый, әлеккечә кайда пыяла куеп, кайда мич чыгарып, ачлы-туклы яшәвен дәвам итә. Шулай да, яңа чынбарлык акрынлык белән, зур авырлыклар аша, әммә катгый рәвештә һәркемнең көндәлек тормышына, аңына, психологиясенә үтеп керә, тормыш үзенә яңа юл сала. Шушы чын мәгънәсендәге катлаулы, каршылыклы процесс роман битләрендә кеше язмышлары аркылы ышандырырлык итеп гәүдәләндерелә. Габделбарлар, кулак Латыйпларның тамырына балта сугыла, Хисам кебек ярлылар, яңа тормыш төзүчеләр сафына басып, аның тулы хокуклы әгъзаларына әвереләләр. Шушы ук процесста романның үзәк герое — кичәге авыл егете Мансурның характеры ачыла, аның физик һәм рухи үсеше күрсәтелә. Монда автор турысызыклылыктан, декларативлыктан котыла алган һәм геройны күпкырлы характер итеп гәүдәләндерүдә җитди уңышларга ирешкән.

«Дустым Мансур»дан соң А. Расих бүгенге көн вакыйгаларына борыла. Һәм ул — хәзерге вакытта заман темасын әдәбиятта яктырту өлкәсендә иң актив һәм нәтиҗәле эшләүче авторларыбызның берсе. Ә заман темасы әдәбият өчен һәрвакыт иң актуаль һәм иң авыр мәсьәләләрдән берсе булып торды, һәм ул бүген дә үз көченде кала.

Соңгы елларда безнең әдәбиятның да, тәнкыйтьнең дә эстетик базасы тирәнәя төште. Шулай да заман темасын ачыклауга өстән карау бетмәгән әле. Кайбер авторлар бүгенге тормыш турында аның эчке каршылыклы үсеш процессларын иҗади ачу юлы белән түгел, бәлки бары партия карарларына формаль нигезләнеп фикер йөртүгә омтылалар. Һәм бу хәл андый авторларны кайчак шактый кыен хәлгә куя. Әйтик, әлеккерәк елларда тормышның объектив үсеш законнарын искә алмыйча, бары субъектив карашларга гына нигезләнеп, кайбер карарлар чыгарылды. Алар болай да артта калып килгән авыл хуҗалыгының рәтләнүенә булышмадылар гына түгел, киресенчә, бу өлкәдә өстәмә кыенлыклар тудырдылар. Партия үзенең соңгы еллардагы пленумнарында һәм XXIII съездда бу кимчелекләрне бөтен дәрәҗәсе белән ачып салды. Һәм безнең ул елларда чыккан кайбер әсәрләрне хәзер кире карап чыгарга, аларның тормыш дөреслегеннән читтә торуларын инкарь итәргә туры килә.

Безнең әдәбиятта шундый бер мәзәк хәл булып алды. 20 съездан соң авыл темасына язылган кайбер әсәрләрдә авыл чынбарлыгы ясалма рәвештә капма-каршы ике периодка бүленә. Беренче периодта, ягъни 20 съездга кадәр авыл хуҗалыгында зур кимчелекләр, җитешсезлекләр булган, кешеләр дә авырлыклар кичереп яшәгәннәр икән, ә менә 20 съездан соң инде боларның бөтенесе берничә карар чыгару белән бетерелә. Мондый хәл, аерым алганда, М. Хәсәновның «Саф җилләр» романында чагыла.

Чын заманчалыкны тормышның тышкы факторларыннан түгел, барыннан да элек чынбарлыкның эчке потенциаль тенденцияләреннән, кешеләр психологиясеннән, уйфикерләреннән, үзара мөнәсәбәтләреннән эзләргә кирәк. Заманның иҗтимагый-рухи йөзен ахыр чиктә кешеләрнең аң-белем дәрәҗәсе, дөньяга карашы, җыеп әйткәндә, аларның рухи дөньясы билгели. Иҗтимагый идеялар, омтылышлар бары тик кешеләрнең көндәлек иҗади хезмәте белән тыгыз бәйләнгәндә генә тормышка ашырылырга мөмкин. Ул идеяләрне, омтылышларны һәм планнарны тормышка ашырганда, кешеләрнең психологиясе, дөньяга карашы, үз-үзләрен тотышы ничек үзгәрә — әдәбият заманчалыкны менә шушы процессны ачу юлында эзләргә тиеш.

А. Расих үз әсәрләрендә бу мәсьәләгә дөресрәк килә кебек. Чөнки ул төп игътибарны нәкъ менә кеше психологиясенә юнәлтә. Автор хәзерге чынбарлыкны тирәнтен аңларга, аның эчке катлаулы, каршылыклы үсеш процессларын геройлар арасындагы конфликтларда, аларның үзенчәлекле язмышлары аркылы чагылдырырга омтыла. Бу нәрсә А. Расихның соңгы вакытта чыккан «Язгы авазлар» романында да нык сизелә. Үзенең «Язгы авазлар»ында А. Расих соңгы еллар авылында барган яңалык процессын, аның бөтен авыл тормышында һәм кеше күңелендә үзгәрешләр тудыруын реалистик чаралар белән күрсәтә. Романда колхоз хуҗалыгы белән яңача, иҗади җитәкчелек итү өчен, догматизм һәм бюрократизмга каршы башта яшертен, аннары ачыктан-ачык көрәш күрсәтелә. Шушы планда ике лагерь вәкилләре үзара бәрелешә. Монда шунсы куанычлы: уңай һәм тискәре геройлар бер-берсенә ак һәм кара тибындагы бер төсле трафарет геройлар рәвешендә каршы куелмаганнар. Һәр ике як вәкилләрен дә автор бик уйланып, аларның рухына тирәнтен игътибар биреп сурәтли. Романда А. Расихның үзгә бер кешелек һәм художниклык сыйфаты аеруча күзгә таш-

лана. Ул геройга, аның кем булуына карамастан, кешеләрчә карый, аңа үз идеяләрен кәчләп такмый. Киресенчә, үзенчә уйларга, фикер йөртергә һәм хәрәкәт итәргә тулы ирек бирә. Моны уңай персонажлар Солтан Фәхретдинов, Аллаһияров, Фатыйма, Шмит образларына карата гына түгел, ә тискәре типлар турында да әйтергә мөмкин. Райком секретаре Халиков һәм Баһави элекке еллар әдәбиятындагы кайбер шундый ук типлардан үзләренең кешечән табигый, кабатланмас һәм җанлы характер итеп бирелүләре белән аерылып торалар. Мәнә шуңа күрә дә, аерым алганда, райком секретаре Халиков элекке еллар тискәре тибының традицион калыбына берничек тә сыя алмый. Ул таштай каткан кире тип түгел. Аның кайбер уңай сыйфатлары да бар. Герой каршылыклы уй-хисләргә, кичерешләргә бай булган тормыш белән яши. Аны һич тә социалистик авыл хуҗалыгының дошманы яки корткыч итеп карарга ярамый. Киресенчә, ул күңеленнән бары яхшылык эшләргә тели. Халиков — үз эшенә бирелгән кеше. Ул партия линиясен үткәрәм, дәүләт интересларын яклыйм, Солтан белән Ифрат йөзендә исә партия һәм дәүләт дисциплинасын бозучыларны фаш итәм дип уйлый. Халиков образында автор массалардан, реаль тормыш таләпләреннән аерылып, бары югарыдан җибәрелгән инструкцияләр һәм циркулярлар буенча гына эш итүче җитәкченең рухи драмасын күрсәтә. Бу кеше тормыш агымын тоймый, заман белән бергә атлый алмый. Романда вакыйгалар үсеше законлы рәвештә Халиков кебек җитәкчеләрнең, аларның җитәкчелек стильләренең һәм методларының бүгенге чынбарлык тарафыннан һәлакәткә хөкем ителгәнлеген исбатлый. Шуның аркасында һәртөрле искелекне җиңә-җиңә алга баручы тормыш агымы әсәр битләрендә тагын да ачыграк булып күз алдына баса. Икенче тискәре персонаж — колхоз председателе урынбасары Баһави образында автор кеше тормышының иҗтимагый һәм шәхси өлкәләрен үзара тыгыз бәйләнештә күрсәтә. Озак еллар буе председатель булып эшләү дәверендә Баһави закон бозуларга юл куйган, үз тирәсенә төрле куштаннарны җыйнаган. Геройның политик яктан таркалуы аны мораль бозыклыкка китерә. Өйдә ул үзен деспотларча тота, бертуктаусыз хатынын җәберли, дәрәҗәсеннән файдаланып, авылның тол хатыннарын кимсетә.

Романның тискәре персонажларына киңрәк тукталуның сәбәбе шул: бу образлар тулырак һәм нигезлерәк ачылганнар, шуңа күрә аларның ышандыру көче дә зуррак. Уңай геройларның кайберләренә исә нәкъ менә шушы сыйфатлар җитенкерәми.

Роман үзәгендә партоешма секретаре Солтан Фәхретдинов тора һәм ул әсәрнең төп идея йөкләмәсен күтәрә. Электәге кебек, соңгы елларда да безнең әдәбиятта бу геройны тасвирлауга зур игътибар бирелә, шул ук вакытта аны гәүдәләндерүдә аерым үзгәрешләр дә күренә. Элекке еллардагы кайбер әсәрләрдән аермалы буларак, язучылар үз роман-повестьларында партия җитәкчесен һавадан җиргә төшерергә, аны кешечәрәк, җанлырак итеп сурәтләргә тырышалар. Үткәндәге кайбер язучыларга полемик рәвештә каршы чыгып, хәзерге авторлар бу геройны күп кырлы характер итеп, бер үк вакытта иҗтимагый-социаль һәм шәхси-интим планда тасвирларга омтылалар. Бу, билгеле, дөрес юнәлеш. Әмма еш кына монда бер чиктән икенче чиккә сикерү кебек нәрсә дә сизелә. Элеккерәк елларда бу геройның шәхси тормышы бик коры сурәтләнсә, хәзер геройны һавадан җиргә төшерү, җанландыру еш кына аны шәхси тормышында аксату, төрле кимчелекләр, йомшаклыклар тагу юлы белән башкарыла. Әйтик, геройның семья тормышы барып чыкмый, ул мәхәббәттә бәхетсез була. Солтан Фәхретдинов та шундый ук язмышка очрый. Геройның иҗтимагый эшчәнлеге, чыннан да тормышчан детальләрдә һәм укучыны ышандырырлык итеп күрсәтелә. Ул колхоз хуҗалыгындагы реаль авырлыкларга каршы көрәшеп яши, шул көрәш дәвамында аның характеры ачыла. Ә менә геройның шәхси тормышына күчү белән, автор ничектер иске, тапталган юлдан китә. Романда кешенең җәмгыять алдындагы бурычы белән мәхәббәте арасында конфликт туа һәм ул мәхәббәтнең җимерелүенә китерә. Солтан шундый дилемма алдында кала: иҗтимагый бурычын үтәү өчен аңа хатынынннан, мәхәббәтеннән баш тартыргамы, әллә инде авылны ташлап, мәхәббәте артыннан кире шәһәргә китәргәме? Ахырда ул авылда калырга дигән карарга килә. Ә хатыны Суфия кайтып китә. Әгәр Суфия бер мещанка, эгоистка булса, мәсьәлә аңлашылыр иде әле. Әмма ул бик акыллы, тирән фикерле хатын, автор да аны бары уңай яктан тасвирлый. Безнең көннәрдә мондый ситуацияне күтәреп чыгу, безнеңчә, үзен акламый.

Ә мена тол хатын Фатыйма образында автор кеше мәхәббәтенә дәресрәк якын килә. Фатыйма — шактый кимсетелгән, кыерсытылган кеше. Бу хәл аның уй-хисләренә, тормышка һәм кешеләргә мөнәсәбәтенә дә билгеле бер эз сала башлаган. Стендаль мәхәббәтне «әхлак медицинасы» дип атаган. Ягъни мәхәббәт — кешене мораль савыктыру чарасы. Чыннан да, инде кешеләргә ышанмый торган, бозыклык юлына баса башлаган Фатыйма өчен саф мәхәббәт кешене авырудан савыктыру чарасына әверелә. Солтанны чын күңелдән сөю бу ялгыз хатынны мәгънәсез сеяркә тормышыннан баш тартырга, аңарда кешелек горурлыгы хисе уянуга һәм аякка басып яңача, кешеләрчә яши башларга ярдәм итә. Шулай итеп язучы бу образда кеше мәхәббәтенең гүзәл мәгънәсен, аның зур максатларга, батыр хезматка чакыручы көч булуын гаять тәэсирле итеп ача алды.

Гомумән, романда авылның гади, тыйнак кешеләре образлары тормышчанрак чыкканнар. Мисал өчен романтик табигатьле, шагыйрь күңелле яшь егет Шмитны алыйк. Шмитның яшьләрчә каршылыклы һәм катлаулы характеры, аның ялгыша-ялгыша һәм сөртенә-сөртенә тормышта үз юлын табуга килүе тормышчан детальләрдә гәүдәләндерелә. Геройның «шәһәр чибәре» Җамилага романтик мәхәббәтен язучы үзгә бер эмоциональ көч һәм күңел җылылыгы белән сурәтли. Яшь коммунист Шакир, колхоз хисапчысы Сабир, Баһавиның хатыны Марьям образлары да күңелдә җылы тәэсир калдыралар. «Язгы авазлар» романы хәзерге авыл тормышында бара торган мөһим иҗтимагый-рухи процесслар, җир кешеләре турында заманча объектив һәм нигезле фикер йөртергә омтылучы әсәрләрдән исәплəнә.

А. Расих — үзенчәлекле язучы. Ләкин аның үзенчәлекле язучы булуы нидән гыйбарәт икәнен бер-ике сүз белән генә әйтеп бирүе дә кыен. А. Расихның иҗат үзенчәлеге турында сөйләгәндә, күрәсең, барыннан да элек аның безнең әдәбияттагы мәгълүм бушлыкларны, хәл ителмәгән мәсьәләләрне тирәнтен сиземләвен һәм үзенең игътибарын әнә шул бушлыкларны «тутыруга» юнәлтүен истә тотарга кирәктер.

А. Расих иҗатында, безнеңчә, үзара аерылгысыз бәйләнгән ике моментны аеруча ассызыклап күрсәтергә кирәк. Иң әүвәл язучы әсәр өчен тема, ул теманы ачарлык тормыш күренешләрен, кеше образларын сайлауга бик уйланып, үзенчә килергә омтыла. Шунлыктан, аның әсәре әдәбиятка билгеле бер яңалык алып килә. «Дустым Мансур»да, мәсәлән, ул 30 еллар тормышын үзенчә яктыртты, бу чынбарлыкның әле безнең әдәбиятта чагылмаган яңа якларын ачып салды. «Язгы авазлар»да да автор таныш сукмакларны, формаль чишелешләрне нигездә читләтеп үтә һәм соңгы еллар авылы турында үзенчә сөйләп бирә.

Инде менә «Ике буйдак»ка килик. Бу романның темасы, эчтәлеге, анда күтәрелгән мәсьәләләр шулай ук яңа, үзенчәлекле. «Ике буйдак» әдәбиятыбызның тормыш офыгын киңәйтергә булышты. Бу әсәре белән А. Расих әдәбият дөньясына бүгенге фән кешеләрен алып килде. Романда авторның үз геройлары тормышын һәм хезмәтен тирәнтен белүе аеруча күзгә ташлана һәм бу бик табигый хәл. А. Расих, әйткәнебезчә, озак еллар үз геройларының прототиплары белән бергә эшләде — ул Казан ветеринария институтында укытты. Биредә авторның тормыш материалын, герой профессиясе спецификасын белүенә басым ясауның үзгә сәбәбе бар. Эш шунда: кеше эшчәнлегенең үзенчәлекле өлкәләренә багышланган кайбер әсәрләрне, әйтик, медицина кешеләре, музыка әһелләре яки нефтьчеләр турында сөйләүче аерым роман-повестьларны укыганда, авторларның бу тормышны, аның үзенчәлекле мәсьәләләрен өстәнрәк һәм йомшаграк белүләрен тоясың. Нәтиҗәдә, мондый әсәрләрдә хезмәт бары коры фон гына булып кала, ул геройның характер үзенчәлеген билгеләми. Һәм ул геройны бик җиңел генә заводка да, колхозга да яки берәр фәнни учреждениега да «күчереп утыртырга» була. Моңардан аның характерына бернинди дә зыян килмәячәк. А. Расих геройлары мондый «пропискасыз» персонажлардан нык аерылып торалар. Биредә хезмәт герой характерына, уй-фикерләренә сизелерлек эз салган.

А. Расих үз әсәрләрендә совет әдәбиятының иң төп максатларыннан берсе — тормыш дөреслеген чагылдырырга омтыла. Бу сыйфат аның 30—40 еллар хикәяләрендә үк күзгә ташлана. Ләкин анда әле тормыш дөреслеге бөтен тирәнлегендә ачылмый, кайбер хикәяләрдә ул теге яки бу вакыйганы чынбарлыкта ничек булса шулай сөйләп чыгу рәвешендә генә бирелә. Икенче төрле әйткәндә, чынбарлык күренешләре тирән эстетик анализ аша үткәрелмиләр иде. 50—60 елларда язылган күләмле әсәр-

парда исә, язучының тормыш дәреслеген аңлавы тирәнәйгәннән-тирәнәя бара. Хәзер инде ул реаль вакыйгаларны түкми-чәчми тасвирләп чыгу белән генә чикләнми. Язучы тормыштагы яңалыкларны коры сөйләп чыгу юлы белән түгел, бәлки герой образларында, аларның үзара бәрелешләрендә калку итеп, зур көч белән чагылдырырга омтыла. Шунлыктандыр, ахры, А. Расих романнарында геройның тормыш юлын кешенең үзенчә катлаулы һәм каршылыклы язмышы рәвешендә сурәтләргә әңрүчә басым ясала. «Ике буйдак»ның кайсы гына персонажын алмыйк — яшь галим Шәйхерамовмы ул, доцент Заһид Сафичмы яки зоотехник кыз Мәдинәме — һәркайсының үз язмышы, үз юлы бар. Мисал өчен Рәхим Шәйхерамовны гына алыйк. Аның образында төрле-төрле авырлыкларны, каршылыкларны җиңә-җиңә фәнгә килүче кешенең катлаулы һәм гыйбрәтле язмышы күрсәтелә. Сөйгән хатыны үлгәч, ул ике яшь бала белән авылдан Казанга килә. Әмма бу авылны яратмыйча, шәһәргә качу түгел. Рәхим — үз эшен бик яратып башкарган, тырыш хезмәте белән райондашларының ихтирамын казанган кеше. Аның тормышы да әйбәт бара. Әмма ул, боларның бөтенесен калдырып, шәһәргә китә һәм гади лаборант булып институтка урнаша. Ни өчен? Моңа аны фәнгә мәхәббәт, үзенең күптәнге хыялларын тормышка ашыру теләге мәҗбүр итә. Яңа урында аны берсеннән-берсе зуррак авырлыклар, каршылыклар көтә. Институтта эшли башлавының беренче көннәрендә үк ул хайваннарның калкансыман бизләре эшчәнлеге белән карындагы микрофлора арасында бәйләнеш барлыгын раслый. Бу исә Рәхим үзе эшләгән физиология кафедрасы мөдире, танылган профессор Филипповка каршы чыгу, шул ук вакытта аның күптәнге көндәше — Харьков профессоры Борисов линиясен якпап чыгу дигән сүз. Болар барысы Рәхим тормышында һәм хезмәтендә тагын да зуррак кыенлыклар тудыралар. Менә шулай геройлар язмышы җитди тормыш киртәләре, авырлыклары белән бәрелешә. Болар барысы әсәр идеясен ачуда конфликтның ролен бермә-бер күтәрә, аның тормышчанлыгын һәм ышандыру көчен арттыра. Бу моментка аеруча басым ясарга кирәк. Чөнки безнең кайбер роман-повестьларда чын мәгънәсендә нигезле һәм тәпле конфликт тудырылмый, ул ясалма чыга һәм шунлыктан үз вазифасын да тиешенчә үти алмый.

А. Расих әсәрләрендә сюжет-композициянең тыйнак һәм төзек булуы күзгә ташлана. Анда һәр персонажның, һәр детальнең үз урыны бар. Шул ук вакытта алар үзара тыгыз бәйләнгәннәр һәм бер максатка юнәлдерелгәннәр. Ягъни алар төрле юллар белән үзәк конфликтка килеп тоташалар, аны үстерү һәм чишүгә хезмәт итәләр.

«Ике буйдак»ның үзәк конфликты фәндәге бер-берсенә капма-каршы ике юнәлешнең, ике омтылышның бәрелешеннән гыйбарәт. Башта ул Рәхим һәм профессор Филиппов арасында туа, аннары, тагын да катлаулырак һәм көчлерәк булып, Заһид Сафич белән мөнәсәбәтләрендә чагыла. Башка персонажлар исә төрле-төрле планда шушы үзәк геройларның характерларын ачыкларга булышалар.

Геройның рухи йөзен, характерын ачуда диалогның роле зур. А. Расих диалогларны гаҗәп тормышчан һәм тирән мәгънәле итеп төзи белә. Аның диалогына эчке динамизм һәм киеренкелек хас. Моны, аерым алганда, Заһид Сафич белән Рәхимнең үзара бәхәсләрендә күрергә мөмкин. Диалог белән беррәттән, «Ике буйдак»та эчке монолог зур урын алып тора. Ул геройның каршылыклы уй-кичерешләрен чагылдыра. Заһид Сафичның, Рәхимнең яки Мәдинәнең эчке монологлары беренче чиратта шул яктан әһәмиятлеләр.

Роман геройлары күпкырлы характерлар итеп бирелүләре белән аерылып торалар. Язучы герой образында иҗтимагый һәм мораль моментларны үзара бәйләнештә күрсәтергә омтыла. Үзәк геройларның фәнгә карашын ул аларның кешелек сыйфатлары белән, тормышка мөнәсәбәтләре белән нигезли. Гомуми интересларны һәрвакыт шәхси интереслардан өстен куйган Рәхим үз эшенең халыкка практик файда китерүе өчен көрәшә. Гәрчә Шәйхерамов образында фәнне беркадәр утилитар мәгънәдә аңлау яки фәнгә карата практицизм үзен сиздерсә дә, тормышка һәм хезмәткә гаять актив мөнәсәбәте белән герой укучы күңелендә җылы хис калдыра. Заһид Сафич исә бөтенләй икенче характердагы кеше. Ул фәнне ялтыравык фразага, демагогик сүз куертуга кайтарып калдырырга омтыла. Романда геройларның характерларын, хезмәткә карашларын ачыклаучы шундый бер кызыклы эпизод бар. Бервакыт Заһид Сафичның гыйльми эше турында сүз кузгалгач, Рәхим бу хакта болай ди:

— Минемчә, ул бәрнинди дә юнәлеш алмаган, тегәлләнергә дә тормый. Чөнки мин күрәм: сезне ул әз генә дә дулкынландырмый, уйландырмый, төн йокыларыгызны качырмый. Сез артык тыныч. Ә тыныч кына яшәп, фән кешесе булып булмый, минемчә.

Заһид Сафич моңа гамьсез генә җавап кайтара:

— Сез артык пафос белән сөйләшәсез, ә фән аны яратмый, ул Олимп тынычлыгын сөя.

— Мөнә бусы белән килешә алмыйм. Фән бары дәртлеләрне һәм темперамент белән яшәүчеләрне генә ярата. Фән кешесе нөнем дип түгел, денем дип яшәргә тиеш!

Рәхим кешене дулкынландыра, төн йокыларын качыра торган эшкә омтыла, ә Заһид Сафич, киресенчә, кабинет тынлыгын, борчусыз, мәшәкатьсез тормышны идеал итеп куя. Аннары язучы белән укучы өчен дә Рәхим тормышта үзенең олы матур хыялы булуы, кыләчакка кыю карап яши белүе белән кадерле. Заһид Сафичның исә тормышта да, фәндә дә олы максаты, үз линиясе юк. Ул вак интереслар белән, «кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырла» дигән принцип буенча яши. Тыштан ялтыраучы бу кешенең эчке йөзен, рухын автор менә ничек тасвирлый: «Аның беркайчан да алга чыгып юл күрсәтүче буласы килми. Ул әзер юл буйлап, бер дә хәвеф-хәтәргә тармыйча, тыныч кына, сак кына барырга тели. Ә нәрсә дигән сүз соң ул читкә киту? Тагаен, берәр яшь институтта эшләү дигән сүз. Ул — бәхәсләр корып, хәтта ызгышып, үзеңне кайчак дошманнар арасына куеп яшәү дигән сүз. Ә нигә кирәк ул? Нигә тыныч башыңны хафага салырга? Ни өчен?»

Бу инде тулы бер тормыш фәлсәфәсе. Һәм ул һич тә автор фантазиясендә генә тумаган, ул чынбарлыкны тирәнтен өйрәнүдән хасил булган. Гомумән, «Ике буйдак»-та тормышны, кеше характерларын игътибарлы өйрәнү сыйфаты күзгә ташлана. Шуңа күрә бу роман әдәби иҗатка бик кирәкле сыйфатларны — характер үсешенең эчке логикасын, күңел диалектикасын алып килә. Болар барысы авторга схематизмнан, штамптан качарга, җанлы характерлар тудырырга ярдәм итә. Романның иң уңышлы образларыннан берсе — доцент Заһид Сафич безнең әсәрләрдә әледән-әле күзгә чалынучы штамплашкан тискәре геройларга полемик рәвештә каршы тора. Сер түгел, кайбер авторларыбызның сурәтләвендә тискәре герой җанлы кеше булудан мәхрүм булып, явызлыкның шартлы символына әверелә. Бу герой гадәттә бик берьяклы, бары кара буяулар белән генә тасвирлана. Мондый күңелсез күренешнең тамыры язучының үз геройларын гәүдәләндерүгә бары шәхси фантазиясеннән генә чыгып һәм баштан ук әзерләнеп куелган калып белән килүендә. Бездә геройны тасвирлауда, күрәсең, шушы хәл белән бәйләнгән бер кимчелек үзен әледән-әле сиздерә. Ул түбәндәгедән гыйбарәт. Геройның нинди кеше булуын, аның характерын автор алдан ук укучыга белдереп куя. Әсәр дәвамында исә аның баштан ук мәгълүм характер сыйфатлары төрле-төрле шартларга һәм ситуацияләргә куелып сынау үтәләр. Ягъни әсәр сюжеты уңай геройның яхшы, ә тискәресенең начар кеше икәнлеген исбатлау максатына буйсындырыла. Билгеле, мондый хәл персонажларның үзара мөнәсәбәтләрендә дә, әсәр конфликтында да ясалмалылык һәм схематизм тудыра.

А. Расих үз романында мондый кимчелектән котыла алган. Герой характерын ул бик җентекләп, такт белән һәм дәвамлы рәвештә ача. Бу сыйфат үзәк геройлар Рәхим һәм Заһид Сафич образларында да, икенче дәрәҗәле персонажлардан Габдуллаҗан абзый, Зәбәрҗәт h. б. образларда да ачык чагыла. Монда бигрәк тә Заһид Сафич образы игътибарга лаеклы. Башта аны һич тә кире тип дип уйламассың. Романның беренче бүлекләрендә ул укучы алдына бары уңай сыйфатларга ия булган мөлаем кеше рәвешендә баса. Ул кешеләр турында кайгырта, кирәк чакта ярдәм кулы сузарга тора, уйлана, борчыла, каршылыклы кичерешләр белән яши. Әмма доцентның чын йөзен бу уңай сыйфатлар гына билгеләми. Инде тормыш тынычлыгы бозылып, шәхси интереслар куркыныч астында калу белән, Заһид Сафич бөтенләй икенче кеше булып гәүдәләнә. Баштарак авторитетлы фән әһеле, финер иясе, гомуман, бары уңай бәягә лаеклы кеше булып күренгән Заһид Сафич соңга таба тормыш белән бәрелешләрдә вак җанлы кызганыч бер бәндә булып күз алдына баса. Хәзер инде ул нинди дә югары материялар, зур идеаллар турында сөйләми, ә бары

үзенең вак максатлар белән яшәвен, омтылыш-хыялларының түбән булуын төрлечә акларга тырыша, моның өчен сәбәпләр эзли. Ахыр чиктә ул болай ди:

— Минем идеалларым юк. Идеаллар алар нинидер романтик шагыйрьгә кирәк. Мин фәннең тыйнак бер хезмәтчесе.

Чыннан да, Заһид Сафичның тормышта берниндн ышанычы, таянычы юк. Шуңа күрә ул һәрнәрсәгә шикләнеп карый, теге яки бу мәсьәлә буенча конкрет карарга килергә базмый. Мисал өчен аның яшь тол хатын Зөбәрҗәткә карашын гына искә төшерик. Бу хатынны ул әле якын күрә, әле читкә этәрә. Әмма һич тә аңа өйләнергә батырчылык итми. Ләкин А. Расих Заһид Сафичның характерын, тормыш фәлсәфәсен табигый рәвештә ачу белән генә канәгатьләнми. Ул мондый кешеләрнең барлыкка килү сәбәпләрен табарга тели. Кеше даһи яки надан булып тумый. Аның характер сыйфатлары дөньяга карашы үсү, чыныгу процессында күп төрле объектив һәм субъектив факторлар белән билгеләнә. Заһид Сафич белән дә шундый хәл була. Мәстәкыйль тормышка аяк басканда, һәр яшь совет кешесенеке кебек, аның да олы максатлары, матур хыяллары булган. Ул җәмгыятькә файдалы кеше булырга теләгән. Ләкин культ тәртипләре тудырган шартлар аның характерында уңай башлангычның үсүенә тоткарлык ясаганнар, аңарда эгоистик сыйфатларның көчәюенә китергәннәр. Шунлыктан, язучы, бу геройның тормыш фәлсәфәсен, яшәү принципларын кискен рәвештә фаш итү белән бергә, аның көчле рухи фаҗигасен дә күрсәтә.

Җыеп әйткәндә, Заһид Сафич һәм Рәхим Шәйхерамов образлары «Ике буйдак» романының төп уңышын тәшкил итәләр һәм алар соңгы еллар әдәбиятының үзенчәлекле образлары рәтенә керәләр. Шуның белән бергә А. Расих бу әсәрдә үзенең икенче дәрәҗәдәге образлар аша да олы фикер чагылдыра алуын күрсәтте. Бу яктан бигрәк тә Рәхимнең туганы Габдуллаҗан абзый һәм яшь тол хатын Зөбәрҗәт игътибарга лаеклы. Романның икенче дәрәҗәдәге персонажларыннан исәпләнсәләр дә, алар әдәбиятка мәгълүм бер идея-эстетик яңалык алып киләләр. Бу геройлар йөзендә автор шактый үзенчәлекле һәм гаҗәп тормышчан кеше характерларын тудыра алган. Шунлыктан аларга зур ышандыру көче хас. Габдуллаҗан абзый образында гасырлар буе сакланып килә торган вак милекчелек фәлсәфәсе чагылдырыла. Зөбәрҗәт образы исә шәхси тормышында күп кыенлыклар күргән кешенең каршылыклы психологиясен һәм язмышын гәүдәләндерә. Мондый кешеләрне тормышта еш очратасың.

Язучыга сентябрь аенда 50 яшь тулды. Иҗат кешесе өчен бу аз да түгел, күп тә түгел. Аннан соң бит кайчак шулай да була. 50 яшьтә инде бераүләр иҗади эшчәнлекләрен түгәрәкли башлыйлар: сәнгатьчә әйтәсе сүз әйтелгән, языласы әйберләр язылып беткән була, ә икенче бераүләр өчен бу яшь әле җиң сызганып киң колач белән иҗат итү чоры. А. Расих менә шушы соңгы язучылар рәтенә керә. Ул үз юбилеен нык адым белән алга үтеп барышлый, иҗат кырында яңа үрләр яулап каршылады. Быел гына ул мавҗаралы повестьлар җыентыгы чыгарды, «Ямашев» һәм «Каһарманнар юлы» исемле яңа романнарын тәгаллап килә.

А. Расих — тынгысыз күңелле кеше, үзенә таләпчән художник. Ул ирешелгәннәрдә тукталып калмый, алга карап, яңа иҗат планнары белән дәртләнеп яши. Күңелгә һич тынгылык бирми торган бу катлаулы хезмәт юлында язучыга яңадан-яңа уңышлар телисе килә.

## *Галимҗан Ибраһимовның туууына 80 ел*

# ИЛҺАМ ЧЫГАНАГЫ

*Галимҗан Ибраһимовның романнарын һәм хикәяләрен электән яратып укый идем. Ленинград Сәнгать академиясенең соңгы курсларына җиткәч, аның әсәрләренә иллюстрацияләр ясап карау дәрте уянды. Әдипнең күп санлы әсәрләре арасыннан игътибарны аеруча җәлеп иткәне «Безнең көннәр» романы булды.*


*Зур иҗтимагый хәрәкәтләрне җанландыруга багышланган бу романга рәсемнәр ясау, Галимҗан Ибраһимов тасвирлаган типларны, шул чордагы татар тормышын җанлы картиналарда күз алдына китерү өчен, күп эзләнергә туры килде. Әсәрнең үзен кат-кат укудан тыш, Казандагы завод-фабрикаларда булдым, Татарстан дәүләт музее фондларын өйрәндем, халык арасында йөрдем. Нәтиҗәдә, шактый материал тупланды һәм мин, «Безнең көннәр» романындагы вакыйгаларга иллюстрация рәвешендә, юка агачында пычак белән кисеп, 20 ләп гравюра эшләдем.*

*Романның эчтәлеген, аның гомуми пафосын һәм эчке рухын никадәр дөрес чагылдыра алганмындыр — ул кадәресен укучылар әйтер.*

**ТАВИЛ ХАҖИӘХМӘТОВ**



«Ләкин мена революция килде дә яшь йөрәкләрне үз дулкыннары эченә суырып алды. Юк, хәзер берсе дә юк, берсе дә калмады. Күзгә алдында сокланып каралган озын зифа буй хәзер инде кара платьега төрелгән. Күңелнең һәммә катлаулары революция ялкыннары белән кайныйлар. Буй зифамы, тән матурмы, иреннәр кызарып тулышаламы — була бирсеннәр, болар хәзер күзгә алдында кыйланмаслар... Кыз шулай уйланды...»



«Ләкин сугышка җитми, почмакта, көтелмәгән бер вакыт, кайдандыр кызыл байрак күтәрелеп җибәрелә, аның җилфердәвен күреп, киң масса шунда таба дулкынланып каерыла. Кызыл байрак кузгала, аның артыннан эшче халык, яшьләр, шәкертләр, приказчиклар, һөнәрчеләр, үзләренең юлын бүгән полиция белән талашып, солдат штыгы, казак камчысы астында шаулашып, кычкырышып, шул кузгалган байрак ягына таба агылалар».


«Калын, таза пристав тагын яман котыра, шул басурманнан сүз әйттерә алмауның хурлыгы аның миен каплый, йөрәген кайната, ул тагы шашып, җенләнеп, тоткынның битенә, күкрәгенә итек белән биергә ташлана».

(123 нче бит. Өстә.)

«...Парткомның бүгенге җыелышы Булат өчен дә, Гәрәй өчен дә әеруча үткен бер мәсьәлә булып көтелгән иде».

(123 нче бит Аста.)





# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ЯҢА ТАБЫЛГАН ХАТЫ

*Галимҗан Ибраһимовның бу хаты «Гасыр» нәшриятының хуҗасы, «Аң» журналының нәшире һәм мөхәррире Әхмәтгәрәй Хәсәнигә (1883—1933) язылган. Эчтәлегеннән һәм конверт тышындагы штемпеленнән күренгәнчә, хат 1915 елның 16 декабрендә язылган булырга тиеш. Хатның оригиналы Ә. Хәсәнинең тормыш иптәше Зәйнәп ханым Хәсәновада саклана.*

*Хатта кыскартылып язылган сүзләрнең дәвамы квадрат җәяләр эчендә бирелде. Язылып, автор кулы белән сызылган сүзләр төшерелеп калдырылды һәм андый урыннар түгәрәк җәяләр эчендәге өч нокта белән күрсәтелде. Галимҗан Ибраһимовның бу хатын матбугатка О. Кадыйров әзерләде, барлык искәрмәләрне, аңлатмаларны ул язды.*

## ӘХМӘТГӘРӘЙ ХӘСӘНИГӘ

Гәрәй иптәш,

җибәрелгән китапларны алдым. Ләкин «Аң»[1] һаман килми. Син бу хатны алгач та миңа быелгы «Аң»нарны беренче номерыннан ук башлап җибәрергә куша күр әле. Әдәбият дәресләрендә кирәкләре булгалый. Дәхи түбәндәге әсәрләрне җибәрсеннәр иде:

1) (...); 2) Шәриф Камалның хикәяләр төркеме; 3) Галимҗан Ибраһимовның моңарчы чыккан барлык әсәрләре; 4) Галиәсгар Камалның «Дәҗҗал»ы; 5) «Мөстафадел әхбар»ның беренче җилде;[2] 6) Риза Казыйның «Әсма» белән «Сәлимә»се; 7) Акъегетзадә Мусаның «Хисаметдин мулла»сы; 8) Заһир Бигиевнын «Мавәраэннаһергә сәяхәт»е; 9) Укмасыйның «Алданма, кызым, алмага»сы һәм халык җырлары вә көйләре хакындагы беренче бәйләм китаплары; 9) Газиз Гобәйдуллинның «Олуг кешеләре һәм аларның әсәрләре»[3]; 10) (...) Хәсәнгата Казыйның «Төрек тарихы»; 11) Һади Атласыйның «Казан ханлыгы», «Сибирия тарихы», «Сөембикә» дигән өч китабы; 12) Гайнетдин Әхмеровның «Казан тарихы» һәм «Сөембикә»се; 13) Галиәсгарнең «Уйнаш»ы; 14) Солтан[4] тәрҗемәсе, «Борис Годунов», «Алеко — чегәннәр»; 15) Толстойдан «Хаҗи Морат», «Тере мәет», «Сурат каһвәханәсе»[5]; 16) Андреевтан тәрҗемә: «Асылган җиде кешеләр»[6]; 17) Гаязның «Остабикә»се, «Мөгаллимә»се, «Зиндан»ы да.

«Аң»ның 1915 елда чыккан номерларының һәммәсен җибәрүне тәкрар үтенәм. Болар миңа бик матлуб. Бу хатны берничә көн элек башлап та бетерә алмый куйган идем. Хатыңны алгач, яңадан тотындым.

Башлыйк матбугат юбилееннан[7] һәм «Аң»ның дәвамыннан. Казанда вакытта үзең белән сөйләшкәндә дә «Аң»ның тукталу ихтималыннан бик тәәссеф итүемне әйткән идем. Дәвами хәбәре хакыйкатән дә шатландырды. «Аң» тукталса, әдәбият белән яшь мәдәни фикер хакыйкаттә бер органсыз калачак, яшь истигдатлар[8] өчен дә зур мәхрүмият булачак иде. Дәвам иттерергә карарыңда фәүкылгадә исабәт иткәнсең[9].

Бу — бер минем түгел, күпләрнең фикеredер.

Насыйп булса, һәр номерга булмаса да, еш-еш язарга тырышачакмын һәм башкаларны да димләячәкмен. Һәр хәлдә башланган эшеңдә дәвам вә сәбатыңны ихлас күңелдән тәбрик итәм.

Матбугат юбилее бик тиеш нәрсә. Мин ул хакта, әлбәттә, язырга тиешле күрәм. Ләкин Уфа шундый бер каһәрле кала ки, монда кирәк материалны вакытында табарга кыен. Иске газеталар, иске журналлар кирәк. Боларны Уфада табып булырмы — белмим. Көтепханәдә дә, хосусый кулда да күренмиләр. Һәр хәлдә тырышачакмын. Һәм иң соңга калганда да декабрь 27 ләреннән калдырмаска иҗтиһат итәрмен.

Болар шулай.

Бар яңа бер мәсьәлә. Мин теор[ия] словес[ности] ны «Галия»дә укытып, тәҗрибә

кылып, күп төзәттем. Дәхи шундагы дәресләр тәҗрибәсендә (татар теленең методикасы) методика родного языка эшләнеп барыла. Мин бу нәрсәләрне быел кышта бастырырга тиешле идем.

Сина сүз ачуым түбәндәге сәбәптән: моңарчы синең белән эшләп килдек. Сина бурычлар да бар. Әсәрләремнең бер наширда булуын күңелем бик тели. «Гасыр»ның матур басуы да күңелемә бик охшый. Шунлыктан мин ул ике дәреслегем хакында да «Гасыр» белән киңәшеп үтми торып, мондагы наширларга бирергә йөрәгем тартмый. Сез ничек уйлыйсыз, «Гасыр» шул ике нәрсәне басырга быел имкян табамы, юкмы?

Минем дәреслекләрем моңарчы да чыкканы бер мәктәпләргә кирә барды. Боларда тәҗрибә дә кушыла. Боларның мәктәп вә мәдрәсәгә керүе хакында сөйләргә дә хаҗәт юк. Әгәр дә быел кыш бастыра алабыз дисәгез, мин гыйнварда Сезгә ул әсәрләрне җибәрә алам. Шартлары хакында сөйләшә башларга ярый.

Кәгазь юкмы, башка манигъ бармы, ни дә булса, бастыра алмасагыз да, миңа бер хәбәр яз. Чөнки мин, бәлки, мондагы наширлар белән сөйләшмәммe дигән бер фикердәмен. Әле катгый түгел, шулай да сез баса алмасагыз, я үзем бастыру, я болар белән сөйләшеп карау ниятендәмен. Миңа аларның быел дөньяга чыгуы күп җәһәттән бик матлуб. Шул хакта кичекми бер хәбәреңне көтәм [10].

«Аң»да быел барлыгы биш мәкалә булды. 1. «Уфа мәҗлесе карарлары» [11]. 2. «Хезмәт һәм әдәби җинаять» (Шакирның китабы [12] хакында тәнкыйть). 3. «Татар имлясында яна агымнар». 4. «Мәдрәсәи «Галия» хакында» [13]. 5. «Татар сарыфлары».

Син, шуларның һәммәсен хисаплатып, тиешле акчасын җибәртсәң иде. Болар хисабына илле сум алынган. Тагын шул чамадан артыграк тиярга тиеш. Үтенәм, хисапларын дөрес карасыннар иде. Кайбер вакытта мөсаһәлә була [14]. «Гасыр»дан китаплар алдырдым. Югарыдагы китапларны җибәрергә куша күр. Үтенәм, ул китапларны минем «Гасыр»га булган бурычларым хисабына кушсыннар. «Аң»дагы мәкаләләр гонорарына аны катнаштырма әле. Әгәр алай мөмкин булса, китапларны җибәрмәвең үк матлуб.

Уфада хаят күңелле генә үтә. Күп эшлим, бугай. Мәдрәсәи «Галия» дә бераз вакытны ала. Анда кайсы көндә ике, кайсы көндә өч сәгать дәрестә булам.

Казанда ни хәбәрләр? Аны бер дә язмагансың. Матбугат юбилеена газеталарда ник язмыйлар? Аңа бит башка якларның да кушылуы матлуб.

Сораганнарга сәлам сөйлә.

Хәзергә башка хәбәр юк.

Хат, перевод вә китаплар көтеп калам.

Галимҗан.
Декабрь 16 — Уфа.
Адресым әүвәлгечә.

---

1 «А ң» — 1912—1918 елларда Казанда чыгып килгән әдәби, фәнни һәм сәяси-иҗтимагый журнал.

2 «Мөстафадел әхбар» — Ш. Мәрҗәни әсәре.

3 9 нчы номерны Ибраһимов ялгыш ике мәртәбә куйган.

4 Солтан — Солтан Рахманколый (1888—1916) язучы, тәрҗемәче.

5 «Хаҗи Морат» — повесть, М. Мәрҗәни тәрҗемәсе; «Сурат каһвәханәсе» — хикәя, Х. Әбүзәров тәрҗемәсе.

6 «Асылган җиде кешеләр» — Леонид Андреев (1871—1919) хикәясе, татарчага Ф. Әмирхан тәрҗемә иткән.

7 Сүз татар матбугатының 10 еллыгы (1915) турында бара.

8 Истигдатлар — талантлар.

9 Фәүкылгадә исабәт иткәнсең — бик дөрес эшләгәнсең.

10 Язучының үз әсәрләрен бастыру турындагы сөйләшүләре нәтиҗәсез калган булса кирәк. Чөнки хатта әйтелгән китапларны «Гасыр» нәшрияты түгел, ә бәлки «Әдәбият дәресләре» һәм «Татар телен ничек укытырга» (телебезнең методикасы хакында бер тәҗрибә) дигән исемнәр белән 1916 елда «Сабах» нәшрияты чыгарган.

11 «Аң» журналы, 1915 ел, 15—16 саннар. (Г. Ибраһимов «Аң» журналында басылган кайбер мәкаләләренең исемнәрен тулысынча язып бетерми. Ул мәкаләләрнең исемнәре искәрмәләрдә тулысынча китерелде һәм журналның кайсы санында басылганлыклары да күрсәтелде.)

12 Сүз Шакир Мөхәммәдъяровның «Сәүдә законнары» исемле китабы турында бара.

13 «Мәдрәсәи «Галия» вакыйгасы хакында берничә сүз», «Аң», 1915 ел, 20 сан.

14 Мөсаһәлә — салкын карау.

# ЕРАК ГАСЫРЛАРНЫҢ ШИГЪРИ АВАЗЫ

Сәйфи Сараи һәм аның «Китабе Гөлстан бит-төрки»се турында татар матбугатында беренче сүзне филология фәннәре докторы Әмир Нәҗип әйтте [1]. Ул шулай ук шагыйрьнең Голландиядә Лейден университетында саклана торган кульъязмасының Мәскәүгә алдырылган фотокүчермәсеннән бер данәсен СССР Фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтына җибәрде. Без шул күчермәдән файдаланабыз. Кульъязма 371 биттән тора. Аның 355 бите «Төрки Гөлстаны»ннан, ә калган өлеше Сараиның замандаш шагыйрьләренең лирик шигырьләреннән һәм аларга Сараи язган назыйрәләрдән, шулай ук аның мөстәкыйль лирик әсәрләреннән гыйбарәт. Бу кульъязманың ачылуы борынгы Идел буе төрки әдәбияты, борынгы татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны шактый баетты. Элек безгә һич мәгълүм булмаган сигез шагыйрьнең исемнәре һәм әсәрләре билгеле булды. Болар: Сәйфи Сараи үзе, Мәүля Казый Мөхсин, Мәүляна Гыймад Мәүләви, Әхмәд Хуҗа әс-Сараи, Габделмәҗит, Тугъли Хуҗа, Хәсән углы. Арада тагын Харәзми дә бар. Ул элек мәгълүм булган «Мәхәббәтнамә» әсәренең авторы булса кирәк дип исәп ителә. Әлбәттә, бу шагыйрьләрнең һәммәсе дә Идел буеннан булмаса кирәк. Аларның кайберләре кырымлы, кайберләре әзербәйҗанлы, ә кайберләре харәземле. Әмма Сәйфи Сараиның үзе һәм Әхмәд Хуҗа әс-Сараи, исемнәре үк күрсәтеп торганча, һичшиксез, Идел буе, Сарай шәһәре кешеләре. Калган алты шагыйрьнең дә кайберләре Идел буеныкы булырга мөмкин. Шулай да болар һәммәсе дә — XIV йөзнең төрки шагыйрьләре. Аларның барысын да бергә берләштергән төп сыйфатлар ачык күренеп тора. Әйтергә кирәк, мондагы әсәрләренә карaганда, болар һәммәсе дә яхшы мәгънәсендәге дөньяви һәм шигырьгә оста шагыйрьләр. Без бу кыска мәкаләдә аларның иҗатына төпле һәм киң анализ ясарга җыенмыйбыз. Моның өчен күп эшләргә, тикшеренергә кирәк булыр әле. Хәзергә укучылар игътибарын тик Сәйфи Сараига гына юнәлдереп үтәсе килә. Моның җитди бер сәбәбе дә бар. «Гөлстан» әсәренең бетем өлешендә Сараи болай ди:

> Мөддәти һиҗрәт йиди йөз туксан өч
> Ел иде кем...
> Әүвәле шәүвал иде кем, и газиз,
> Хәтем улды бу «Гөлстан» нәмәмез.

Сараидагы һиҗричә еллар исәбен хәзерге безнең исәпкә күчерсәк, аның «Гөлстан» әсәрен 1391 елның октябрь аенда язып бетергәнен белербез. Димәк, 1966 елның октябрендә Сәйфи Сараиның «Гөлстан» әсәре язылып бетүгә төгәл 575 ел тулган була. Бу безнең өчен үзенчә бер культура бәйрәме, без аны билгеләп үтәргә тиешле.

«Гөлстан»ны тәмамлаганда шагыйрьгә 70 яшь булган. Димәк, ул 1321—22 еллар тирәсендә Сарай шәһәрендә туган. Әсәрен тәмамлап, 2—3 ел үткәч тә ул әле исән булган, бу турыда мәгълүматлар бар.

Ул замандагы төрки дөньяга чыккан шагыйрьләр, язучылар һәм галимнәр үзләренә остаз итеп гарәп, фарси әдип һәм галимнәрен дә алганнар. Бу бик аңлашыла да: безнең эраның беренче мең елы ахырларында һәм икенче мең елның башларында иң алга киткән фән һәм әдәбият гарәпләрдә һәм фарсиларда булган, алар борынгы грек фәне һәм сәнгатенең казанышларын үзләштереп, антик традицияләрне алга үстергәннәр. Рудаки, Фирдәүси, Хәйям, Насыйр Хөсрәү, Әбугалисина, Низами, Сәгъди кебек шагыйрь һәм галимнәр шушы җирлектә үсеп чыкканнар. Төрки шагыйрьләренең аларны остаз итеп алулары, алардан өйрәнүләре шул заман өчен иң прогрессив мактәп булган, чөнки Европа ул заманда әле дин караңгылыгы астында басылып яткан.


Идел буе шагыйрьләре дә шул ук гарәп, фарси даһиларына юнәлеш тотканнар. Үз туган телләрен белү өстенә алар гарәп һәм фарси телләрен дә бик яхшы белгәннәр. Әкирәк булса, ул телләрдә сокландыргыч шигъри әсәрләр дә яза алганнар.

Сәйфи Сараи әнә шундый әдипләрнең берсе. Аның иҗат эшчәнлегендә беренче булып өч тармак күзгә ташлана: тәрҗемәчелек, назыйрәчелек һәм баштанаяк мөстәкыйль иҗат.

---

[1] «Совет әдәбияты», 1957 ел, № 4, 12.

Сараи, ул замандагы Идел буе укымышлыларының күбесе шикелле, Иделдән Нил буйларына — Мисырга, андагы төркиләр—мәмлүкләр арасына барып чыккан. Бер даирә галимнәр арасында утырганда, галимнәрнең олысы аңа: «Шәйх Сәгъди «Гөлстан»ын төрки тәрҗемә кыйлсаң», иде дип, киңәш биргән. «Ул газизнең мөбәрәк нәфәсен кабул иттем»,—ди шагыйрь. Ләкин Сараиның әсәрен, Сәгъдинең «Гөлстан»ы белән чагыштырып карасаң, бу безнең хәзерге мәгънәдәге тәрҗемә генә түгел икәнен күрәсең. Монда иҗатның Сараига хас өч тармагы да гәүдәләнә. Сәгъди үз әсәрен 1258 елда язган, һәм әсәр халык массаларының феодаль стройга протестын чагылдырган, гуманизм идеяләре белән сугарылган.



Сараи кульязмасыннан бер бит.

Әсәр үзе патшалар тормышы, дәрвишләр әхлакы, булганга канәгать итү, кеше сөйләгәндә телеңне тыеп торуның файдасы, гыйшык һәм яшьлек, картлык һәм зәгыйфьлек, балаларга тәрбия бирүнең тәэсире, әңгәмә алып бару кагыйдәләре кебек сигез бүлектән тора. Һәр бүлек темага караган кыска-кыска кызыклы прозаик хикәяләрдән төзелгән. Проза белән сөйләп бара торгач, Сәгъди шигырьгә күчеп китә, аннан тагын прозага кайта, яисә хикәянең йомгагын шигъри сөйләм белән тәмамлый. Нәтиҗәдә, «Гөлстан» проза һәм шигырь үрелмәләреннән гыйбарәт әсәр булып әверелә.

Сараи әсәрнең проза өлешен буйдан-буйга төгәл тәрҗемә иткән. Шигъри өлешкә килгәндә, эш башкачарак: монда шигырьләрнең бер өлеше шулай ук төгәл тәрҗемәдә бирелгән, әмма ул кайбер шигырьләргә иҗади үзгәрешләр керткән — назыйрә иткән, ә инде күп кенә урыннарда шигырьләрне баштанаяк үзеннән язган.

Шагыйрьне нәрсәләр дулкынландыра? — Әлбәттә, аны бик күп, бик күп нәрсәләр дулкынландыра. Без монда кайбер эрерәк мәсьәләләрне генә искәртеп үтик. Мәсәлән, рәгыйят (илнең гади халык массалары) белән дәүләт башлыгы (солтан, патша, мәлик) арасындагы мөнәсәбәтләр аның игътибар үзәгендә тора. Сәгъди, һәм аңа кушылып Сараи, бу турыда күп уйлана. Ул чорда хәтта иң зирәк акыл ияләренең дә дәүләт белән идарә итүдә республика формасын алга сөрүе күренми. Алар илдәге халык массаларының хокук һәм материаль хәлләре дәүләт башында торган шәхеснең, патшаның нинди кеше булуына бәйләнгән дип уйлыйлар: теге яки бу дәүләттә халыкның хокуксыз җәберләнүе, төрле салымнар, мәҗбүриятләр белән интектерелүе, аларча, патшаның кешелексез һәм мәгърифәтсез булуыннан килә икән. Шуыннан алар хыялында кешелекле һәм мәгърифәтле патша идеалы туа, язучылар, шагыйрьләр үз әсәрләрендә шушы идеалны аерым образларда гәүдәләндереп бирергә тырышалар. Алар хыялдагы нәрсәне чынлык итеп күрсәтергә телиләр. Сәгъди «Гөлстан»ында да патшалар шушы ноктадан тасвир ителгән: аларның беришесе явыз, рәхимсез, мәгърифәтсез, икенчеләре идеаль сыйфатлар белән бизәлгән. Алтын Урда ханнарының ерткычлыкларын күреп торган Сәйфи Сараи күңелендә дә ханнарга карата нәфрәт тойгысы кайнавын сизеп була. Ул Сәгъдинең солтаннар, патшалар кешелексезлеген фаш иткән шигырьләрен зур илһамлану белән кабат иҗат итә. Шундый чакта ул ханнар белән халык арасындагы килештереп булмас каршылыкларны, бетмәс үчләшүне яктыртып ташлый: солтан гади халык бакчасының бер алмасын өзеп ашаса, үч итеп, һәрбер кол солтан бакчасының йөз алмасын юк итәр; солтан нәүкәрләрен һәр кешедән бишәр йомырка алырга кушып җибәрсә, болар һәр казыкка егерме казны тотып кадар. Шагыйрьнең халыкны җәберләүче солтаннарга нәфрәте дә чәчрәп тора:

Кем золым әлен озатса,
Солтан булырмы? — Булмас!

Куйларга корт һәргиз
Чубан булырмы? — Булмас!

---

Әл — кул. Корт — бүре. Чубан — көтүче.

Икенче урында автор болай яза:

Бу рәгыяткә мәлик чубан ирәр,
Ул ничә кем күп вилаятьне биләр.
Куй дәгел чубан өчен, и зуфөнүн,
Бәлки чубан куйлара хезмәт өчен.

«Ярлы халыкның илен-көнен туздырып, солтан хәзинәсен ишәйтүче» дәрәҗәле хезмәткәрләргә, күп явызлыклар эшләгәннән соң, тәүбә иткән булып, «изге» йортка бикләнеп, халык җәзасыннан котылган жуликларга шагыйрь нәфрәтен белдерә. Әлбәттә, Сәйфи Сараиның кешелекле һәм мәгърифәтле патша турында хыялланулары да чын ихластан. Ул мондый патшада мәгърифәт һәм кешелеклелек белән бергә чын гражданлык, халыкка рәхимле булу, ил өчен сугыш була калганда сугышның алгы сафында батырлык эшләү сыйфатларын күрергә тели. «Гөлстан»ны ул Мисыр министрлары башлыгы Тайхас биккә багышлаган. Шагыйрь бикне үзенең әнә шундый сыйфатлары булган герое итеп күрә:

Бәдре дәүләт галәмә котлы йөзен,
Кем белек бәхре үзең, җәүһәр сүзең,
Сәнсең ул ләшкәрдә сафлар өзгән ир,
Ирдәмендә ир дәмен күргүзгән ир.

---

Бәдре дәүләт — илнең ае. Белек бәхре — фән диңгезе. Ләшкәр — гаскәр. Ирдәм — һөнәр, белем. Ирдәме — ир рухы, бу урында ирләрчә холык, характер.

Шулай да Сәйфи Сараи читтән мәҗбүр ителмәгәндә сугышны кирәксенми. Аның идеалы иминлек, үз хезмәтең китергән нигъмәтләрдән файдаланып тыныч яшәү. Ике кардәш турындагы хикәя кызыклы: аларның берсе — солтанда гаскәри, икенчесе — үз хезмәте белән көн күргән һөнәрче. Болар бәхәсләшеп китәләр. Гаскәри һөнәрче туганына эшен ташларга, гаскәри хезмәткә керергә киңәш итә. Һөнәрче болай ди: «Сән ничән эшләмәссән? — Кем (гаскәри) хезмәт хурлыкыннан котылгайсән. Галимнәр мәсәле торыр кем: үз өеңдә утырып, коры итмәк йейсә яхшы андан кем, биленә алтын кылыч баглап (гаскәри) хезмәт өчен торгай.

Тимер туккән беләк мең корла яхшы
Ул әлдән кем, куксендә — биккә каршы».

Ягъни тимерне төйгән беләк хуҗа каршында күкрәккә кушырып торган куллардан мең өлеш яхшы, ди шагыйрь. Монда аның талау сугышлары белән иҗади хезмәткә мөнәсәбәте бик ачык гәүдәләнгән.

Һәрбер чын сәнгать әсәрендәге шикелле «Төрки Гөлстаны»ның да үзәгендә кеше, шәхес күрсәтелгән. Аның холкы-фигыле, уй һәм хыяллары, ният һәм идеаллары төрле хәлләрдә күп яклап ачылган. Бөек гуманистларның шәкерте буларак, Сараи кешене ярата, аның яхшы, күркәм сыйфатларының үлемсезлегенә тирән ышана, шунар күрә аның иҗатын буйдан-буйга оптимизм нуры яктыртып бара. Кешене ятканга күрә дә, ул аның гомере мәгънәле үтүен, киләчәк буыннар яхшы сүз белән искә алырлык эшләр калдыра алуын тели. «Игү эше» ядкяр булып калган «ир үлмәс»:

Игү аты калса ирнең яхшырак
Сонра калгынча тулы алтын рәвак,—

---

Рәвак — чатыр, бина.

ди ул. Кеше гомере тормышның бик катлаулы төрле вакыйгалары уртасыннан юл яра. Ләкин кеше нинди генә кыен хәлләргә тарыганда да якты киләчәктән өмет өзмәскә тиеш. Бу тирән философик идеяне Сәйфи Сараи сигез юллык шигырьгә сыйдырып ачып сала:

Гаһ йомылыр, гаһ ачылыр
Баг вә бөстан гөлләре,
Гаһ булыр горьян агачлар,
Гаһ киярләр гөл сыйфат;
Гаһ килеп кайгы китәр,
Булса фәрах — булма мәлүл,
Кем карангылык эчендә
Табылыр абехәят.

---

Гаһ — кайчак. Горьян — шыр ялангач. Фәрах — шатлык. Мәлүл — канәгать, ваемсыз. Абехәят — тереклек суы.

Сараи боларның баштагы ике юлын гына Сәгъдидән алган, калган өлешендә — гел үз иҗаты. Бу юлларны укыгач, зиһенең күз ачып йомган тизлек белән дүрт гасырны үтеп, бу заманга таба кайта һәм колак төбендә А. Пушкинның 1825 елда язган юллары яңгырый:

Если жизнь тебя обманет,  
Не печалься, не сердись!  
В день уныния смирись:  
День веселья, верь, настанет...

Бу ике шигырь арасында йөз еллар, тарихның әллә нинди дәһшәтле вакыйгалары ятса да, гуманизмның бу ике җырчысы бер-берсенә искиткеч якын, бер-берсенә кардәш һәм туган.

Кешенең үзендә аңлы рәвештә өзлексез үстерергә тиешле бик әһәмиятле сыйфаты, Сәйфи Сараича, дөнья һәм кеше тану, белем алу, мәгърифәт эстәү. Бу мәсьәләгә ул әледән-әле мөрәҗәгать итә. Түбәндәге шигырь генә дә ни тора:

Гәр теләсәң кем гараиплар тамаша иткәсән,  
Тикмә бер көн бер яңа йиргә кирәк кем еткәсән;  
Тор, тәфәррөж кыйл җиһанның төрле-төрле таңнарын,  
Күз йомып аннан борын кем бу җиһаннан киткәсән.

---

Г а р а и п — мажара. Т и к м ә — һәрбер. Т ә ф ә р р ө ж к ы й л у — гизү. Т а н — таң калдырырлык хәл.

Акча, мал байлыгы туза, бетә, ә белем байлыгы беркайчан да югалмый; Шам илендә фетнә чыгып, бөтен дәүләт, ил-көн туздьг, бөлде, ди шагыйрь:

Халкы китте хан вә маның тәрк итеп,  
Йиттеләр үзгә вилаятькә китеп,  
Тапты ирдәмле кеше анда шәрәф,  
И ничә ирдәмсез ир булды тәләф!  
Булды ирдәмле фәкыйрь углы вәзир,  
Калды ирдәмсез вәзир углы фәкыйрь.

---

Х а н в ә м а н — ил-көн. Т ә р к и т ү — ташлау. И р д ә м — һөнәр, белем. Ш ә р ә ф — дан.

Шулай да галимнәр белән хакимнәр арасы тиң түгел. Шагыйрь кызыклы бер хикәя китерә: Мисыр тәхетендә гаять надан (белексез) солтан утырган чак булган. Корылык башланган. «Игенчеләр килеп, шикаять кыйлдылар (зарландылар) ки: «Нил якасында мамык иктек, вакытсыз ягъмур килеп тәләф кыйлды». Солтан әйтте: «Йон икмәк кирәк идеңез кем, ягъмур зыян кыйлмагай иде».

Хикәяне автор түбәндәге шигырь белән тәмамлый:

Килер булса белек берлә сәгадәт,  
Белексез һәйкәле булгай шәкавәт.  
Вәли әбләһ батыптыр кәнҗ эчендә,  
Белекле — хур вә мөфлис рәнҗ эчендә.  
Биреп мөлк, ул[1] берене кыйлды солтан,  
Йөретер бу берене ач вә горьян.  
Җиһан бөньядыны буйлә салыптыр,  
Бу эшкә гакыйль ир хәйран калыптыр.

---

Б е л е к л е — галим. С ә г а д ә т — бәхет. Ш ә к а в ә т — бәхетсезлек, бәла. В ә л и ә б л ә һ — дәрәҗәле ахмак. К ә н җ — хәзинә. М ө ф л и с — бөлгән кеше. Г о р ь я н — ялангач. Б ө н ь я д — нигез, төзелеш. Г а к ы й л ь — акыллы.

Таҗлы ахмакларның хәзинә билән, галимнең ач һәм ялангачлыкта михнәт чигүен — бу иҗтимагый гаделсезлекне — шагыйрь алладан күрә һәм монә үзенең протестын сиздерә. Автор бу мәсьәләгә әледән әле мөрәҗәгать итә һәм һәр даим бу гаделсезлекне фаш итеп бара.

Әсәрнең уртасыннан балкып бара торган темаларның берсе — мәхәббәт. Шагыйрьнең бу темадагы әсәрләре дә кешегә тирән хөрмәт, аның матурлыгына соклану хисләре белән сугарылган. Бер шигырь китерик:

---

[1] Ул — алла.

Җиһанда кемдер ул. җана,
Бу гыйшкың утына көймәс,
Висалын күрмәгә бер дәм
Сәне һәҗрең тотар, куймас.
Килер хәйфем назар кыйлса(м)
Йөзенә һәр ки туйгынча,
Йәнә әйтермен: ул йөзгә
Нича бакса, кеше туймас.

Висаль — кавышу. Һәҗр — аерылып тору. Назар кыйлу — карау.

Сәйфи Сараиның бик кыйммәтле тагын бер сыйфаты — гадәттәге тормыш, көнкүреш картиналарын тасвирлавы. Аның «Карый булдың...», «Яше йитмешкә җиткән бер карый ир...» дип башлана торган әсәрләре — чын мәгънәсендә борынгы реализм үрнәге. Бу әсәрләрдәге халык көнкүреше детальләре, «печин вакты килеп, богдай йеткән» урак өсте, кызны кияү янына җиңгәләренең китерүе кебек соңгы заман татар халкы тормышы өчен дә бик хас булган күренешләр хәзер дә әле укучыда җанлы кызыксыну уята алалар.

Сәйфи Сараины табигатьнең үлемсезлеге, аның һич картаймый, язлар килгән саен яңадан яшәреп, матураеп торуы сокландыра. «Гөлстан»ның башына ук ул, баштанаяк үзеннән иҗат итеп, яз җырын урнаштырган: «чичәкләрдән һәрберсе таҗ үренгән ботаклар», «мең төрле моң белән» сайраучы сандугачлар, язгы нур белән өртелгән таулар — яз җырында тасвир ителгән бу күренешләр шагыйрьнең табигатькә тантаналы мөнәсәбәтен ачып салалар. Шунда да аерым кеше, аерым шәхес гомере чикле, әмма аның каравы җирдә кешеләр токымы, кешелек — үлемсез. Табигать белән кешелек язлардан язларга, буыннардан буыннарга яшәрә-яшәрә мәңге уртак бәйләныш белән барырлар. Үлеп калган шәхес үзенең киләчәк буыннар күңеленә күчеп яшәячәк күркәм истәлеге, күркәм ядкяре белән үлемсез. Кабер ташы өчен язылган шигырь гыйбрәтле:

Шат булыр күңел ничә күрсә
Җөмлә сәхрә йөзен чәчәк тотмыш,
Килсәң, и дус, күргәйсән: әлек яз
Тупрагым өстенә яшь үт бөтмеш.

Ягъни: бөтен сәхрә йөзен чәчәкләр каплап алганын ничә генә күрсәң дә күңел сөенер, син дә, дустым, (каберемә) иртә язларда килсәң, туфрагым өстенә яшь үләннәр үскәнен күрерсең.

Күренә ки, шигырь иясе дөньяда яшәп калган дуслары күңелендә үзенең истәлеге үлем белән түгел, тормышның язлар килгән саен тантана иткән мәңгелек матурлыгы белән бәйләнеп саклануын теләгән. «Гөлстан»ны шагыйрь үзе турында әйтелгән түбәндәге юллар белән тәмамлый һәм бу юкка гына түгел:

Ул куеп китте җиһанда ядекяр
Бу «Гөлстан»ны тари чөн нәүбәһар.

Язлар килгән саен яңадан яшәрсен өчен ул бу «Гөлстан»ны истәлек итеп дөньяда калдырып китте, ди шагыйрь.

Идел буе төрки поэзиясенең жанрларын үстерү ягыннан да Сәйфи Сараиның хезмәте зур. Аңарда без философик лириканы да, мәхәббәт һәм табигать лирикасын да, гражданлык идеяләре белән сугарылган оданы да, шигъри кыска хикәя дә, мәсәл дә, ике юлда әйтеп бетерелгән шигъри хикмәтләр дә күрәбез. Ул шулай ук назыйрәнең зур остасы. Әлбәттә, аның теле турында да бик күп яхшы сүзләр сөйләп булыр иде. Әмма кыска гына бер мәкаләдә барысын да әйтеп бетереп булмый. Шагыйрьнең үзе һәм иҗаты турында махсус зур тикшеренүләр эшләнергә тиеш.

Сараи әсәрләренең ачылуына 10 елдан артыграк вакыт үтеп китсә дә, аларны бастыру, укучыларның киң катлавына җиткерү буенча эш аз эшләнгән әле. Беренче башлап бу әсәрләрнең фотокүчермәсе моннан 10 еллар чамасы элек төрек галиме Фәридүн Нәфиз Үзлүк тарафыннан чыгарылды. Соңрак, 1963 елда Венгрия Халык Республикасы Фәннәр академиясе Сараиның назыйрәләрен һәм аларга бәйләнешле башка шагыйрьләрнең әсәрләрен бастырды. Бирелә шагыйрь кулъязмасының фотокүчермәсе, күчермәнең венгр алфавиты нигезендәге транскрипциясе һәм инглизчәгә юлга юл тәрҗемәсе бирелгән. Шунда ук А. Бодроглигетиның инглиз телендә аерым мәкаләсе урнаштырылган һәм мәкаләдә Сараи әсәрләренә кызыклы анализ ясалган. Безгә кардәш ил галимнәренең бу бик зур хезмәте. Хәзер бездә Сараиның әсәрләрен тулы килеш бастырып чыгару өчен әзерлек алып барыла.

Без түбәндә Сараи әсәрләреннән үрнәкләр бирәбез. Болар СССР ФА Казан тел, әдәбият һәм тарих институтындагы фотокүчермә буенча Зәйнәп Максудова белән шушы юлларны язучы тарафыннан әзерләнде. Шигырьләрнең исемнәре шартлы рәвештә куелды. Сул баганада шигырьләр Сараиның үзендәгечә, янәшәдә — уң баганада шигырьләрнең хәзерге телгә юлга-юл күчермәсе бирелде.

ХАТИП ГОСМАН.

*Сәйфи Сараи*

# КИТАБӨ ГӨЛСТАН БИТ-ТӨРКИ

## Язылу тарихыннан

Элек яз көннәрендә бер көн, бөстан эчендә гөлләр арасында бернечә зариф галимләр белән утуруб, инша гыйлмендән бәхәс кыйлып, әбьятө гарип вә әшгарә гаҗип укудум исә, ул галимнәрнең олусы гаруз гыйльмендән бер мөшкил бәетнең тәкътигын сөал итте. Филхал җавабын ишетеп, әйтте: «И әдибе гарип, сәңа бер муафикъ нәсыйхәтем бар. Кабул кыйлсаң, хәер булгай». Әйттем: «Боюрун!» Әйтте: «Шәйх Сәгъди «Гөлстан»ын төрки тәрҗемә кыйлсаң, бер сахибө дәүләт ир атына мисраг ядкярең җиһанда калсын дип...» Ул газизнең мөбарәк нәфәсен кабул итеп... тәңригә тәвәккәл кыйлып. Һиммәт билен рәгъбәт әле белән баглап, башладым, тәмам булгай...

| | |
|---|---|
| ...Төркигә кыйлыб гаҗәмдән, бу китап<br>Мәгърифәткә ачты сәккиз төрле бап. | Бу китап фарсичадан төркигә күчерелеп,<br>Мәгърифәткә сигез төрле бүлек ачты. |
| ...Тикмә бер җанга мөфәррих булмага,<br>Тикмә хатыйрне мөшәрриф кыйлмага. | Һәрбер җанын сөендерер өчен,<br>Һәрбер күңеленә олылык алыр өчен |
| Бу «Гөлстан»га тамаша кыйлган ир<br>Дәмбәдәм мәгънә емешен тазә йир... | Бу «Гөлстан»га килгән ир килгән саен<br>Яңа пешкән мәгънә җимешеннән туйганчы сыйланыр. |

---

Зариф — зирәк, сүзгә оста. Әбьятө гарип — мажаралы әдәбият. Мөшкил — читен. Тәкътигъ — шигырьне ритмик буыннарга бүлеп күрсәтү. Филхал — шунда ук. Сахибө дәүләт — дәүләт иясе. Һиммәт — тырышлык. Рәгъбәт — теләк, омтылыш. Гаҗәм — фарси теле.

## Яз җыры

...Янә саба еленең фәррашына боюрды кем, ер йөзенә яшел атлас бисат түшәгәй. Дәгый элек йаз болытының даясенә фәрман кыйлды: чәчәк кызларыны ер бишекендә бәсләгәй, дәгый агачларга рәбигъ хилгатен кидереп, әлләренә кызыл, ак, сары чичәкләр биргәй.

| | |
|---|---|
| Янә киде яңы әшҗаре хилгат, | Агачлар тагын яңа зиннәтле киемнәрен киделәр, |
| Бизәнеп баг вә бөстан тотты зиннәт, | Баглар-бакчалар бизәнеп зиннәтләнделәр. |
| Ботаклар алды бөстандан янә баҗ, | Ботаклар бакчалардан тагын өлеш алдылар, |
| Чичәкләрдән үренеп һәрбере таҗ. | Һәрберсе чәчәкләрдән таҗ киде. |
| Бәнәфшә буйнын игде гөлгә каршы,<br>Ачып гамбәр күзен сөнбелгә каршы. | Миләүшә гөлгә каршы башын иде,<br>Ганбәр гөле, күзләрен ачып, сөнбелгә текалде. |
| Булып мотриб гөлстанларда былбыл, | Сандугач, бакчаларның җырчысы булып, |
| Кыйлур мең төрлү нәгъмә берлә голгыл. | Мең төрле моңнар яңыратырга керешге. |
| Янә фирдәвес әгъла тик булуп баг, | Бакча да гүзәл фирдәвес булып әверелде, |
| Зөмәррәд рәнгеи алды тикмә бер таг. | Һәрбер тау зөбәрҗәт төсенә керде. |

---

Саба — иртәнге йомшак җил. Фәрраш — хезмәтче. Бисат — келәм, палас. Дая — сөт анасы, тәрбияче хатын. Бәсләү — туендыру. Әл — кул.

## Гөл һәм туфрак

Мәңа хәммам эчендә бер йөзе ай
Бу көн сонды мөфәррах гөл кеби кил.

Мән ул килгә сөал иттем ки: «Нәйдән
Булур хуш рәйхаңдән сәкәр хасыйл?»

Ул әйтте: «Элек идем бер хар тупрак,

Вәли гөл берлә булдым берничә ел.

Әсәр кыйлды мәңа гөлнең җәмалы;

Юк исә мән ушул тупрак мөни бел!»

Ай йөзле берәү миңа бүген мунчада
Хуш исле чәчәктәй сабын балчыгы суздЫ.

Мин ул балчыктан сорадым: «Нидән
Син исертер дәрәҗәдә хуш исле?»

Ул әйтте: «Мин элек каты туфрак кына идем,

Ләкин берничә ел гөл белән бергә булдым.

Аның матурлыгы миңа тирән тәэсир ясады;

Югыйсә мин әлеге шул ук туфрак».

## Беренче баб

### Үчкә үч

Рәгыййят багының солтан
Алып йисә бер алмасын.
Йөз армудын йигәй бер кол,
Берине илмәен тешкә.

Боерса биш йомыртканы
Алурга көч белә солтан,
Нәүкәрләре тотуп санчар
Екерме казны бер шешкә.

Гади кеше бакчасының солтан
Бер алмасын алып ашаса,
Бер кол солтанның йөз грушасын ашар,
Тешенә дә агылмас.

Солтан халыктан биш йомырка
Көчләп алырга кушса,
Хезмәтчеләре бер казыкка
Егерме каз тотып кадар.

**Җөмлә хәйванат әгъласе — арслан, дәгый әднасы ишәк торур. Иттифакы хәлкъ бу торур кем: йөк китүргән ишәк яхшырак ул арсландан, кем адәмине ерткай.**

Ничә кем фәһме йук мискин ишәкнең,
Күтәрмәк берлә йөкне кыйммәте бар.
Ишәк ул адәмидән яхшырак, кем

Кыйлур даим кешенең күңлен азар.

Мескен ишәкнең зиһене булмаса да,
Йөк йөртүе белән кыйммәтле.
Кеше күңлен бер өзлексез газаплаучы адәмнән

Шул ишәк яхшырак.

---

Иттифакы хәлкъ — халыкның уртак фикере. Әдна — түбән.

## Икенче баб

### Алланың игътибарсызлыгына гаҗәпләнү

Ничә килсә саба еле сәхәр гаһ

Йөзем ергә сөреп әйтүрмән: аллаһ,
Онытмам бер нәфәс һәргиз сәне мән,

Аңармисән бу колны, и гаҗәпсән!

Таң вакытларында иртәнге җил килгән саен

Йөземне җиргә орып әйтермен: алла,
Мин сине бер генә сулышымда да истән чыгармыйм,

Ә син бу колны искә дә алмыйсың, гаҗәп син!

### Дәрәҗәгә менгәч һәм дәрәҗәдән төшкәч

Качан бер мохтасар диван
Булуп гаммал, олыгайса,
Тәкәббердән белешләргә
Күрүбән илтифат итмәс.

Янә төшсә гамәлдән ул,
Килеп юксул белешләргә,
Күңул дәрден ятып сүзләр,
Сөрәр булса(н) торып китмәс.

Вак чиновник,
Хезмәткә кереп, күтәрелсә,
Масаюыннан танышларын
Очраганда күрмәмешкә салынып.

Инде ул хезмәтеннән чыгарылса,
Ярлы белешләренә килеп,
Күңелендәге кайгысын ятып сөйләр,
Кусаң да торып китмәс.

## Тормыш кайгысы һәм гыйбадәт турында гади кешенең әмиргә әйткәне

Әя әһле дөнья вә сахибе гаял,
Аягың тозагы угыл-кыз ирур.

Ничә кем тере сән, болар буйнына
Хәмаил булубән сәне йилдерер.

Ул әйтте: «Кичәләр гыйбадәт өчүн
Торурда күңүлгә бу сагыш килүр

Кем «Иртә угыл-кыз торуп ни йигәй?»
Аның тагате бәс ничүк төз булур?

Угыл-кыз җәфасы — йимәк кайгусы —
Мәләк сирәтендән сәне кайтарур».

Әй дөнья әһелләре һәм семья иләре,
Бала-чагаларыгыз аягыгызны тышаулаган,

Гомерегез барында алар муеныгызга
Йөк булып, сезне җилдерерләр.

Ул әйтте: «Кичләрен гыйбадәткә ниятләнгәч,
Күнеленә, иртәгә бала-чага

Торып ни ашар икән? дигән уй килгән кешенең
Гыйбадәте ничек дөрес булсын?
Бала-чага җәфасы — ашау кайгысы —
Сине фәрештәләр дөньясыннан кайтарыр»

## Өченче баб

## Түбәнсенмәс

Хикаят. Бер фәкыйрь ир юксуллык утына көеп, хиркасен тегеп, хатирен бу нәүбәт белән тәсалли кыйлур иде.

Коры итмәк ашап, хирка
Кияргә чөн канагатмен.
Халаикъ миннәтен бары
Күтүрмәктән фәрагатмен.

Коры икмәк ашап, сәләмә
Киеп йөрсәм дә канәгатьмен,
Тик бүтәннәргә баш июдән генә
Азат булыйм.

Бер кеше аңа әйтте: «Ни утурурсән кем, фәлән хуҗа кәрәм элен ачып, фөкара хидмәтенә билен баглаб торур. Дәгый даим күңүлләр ишекендә утурур». Әйтте: «Тик торгыл кем, юксуллык утына көйеп көймәк андан яхшырак кем, бер кеше катына барып, хаҗәт теләгинчә».

Илтифат итмәс күрүп, ач ултуруп сабир фәкыйрь
Ниґъмәте күп хуҗаларның малына вә багына:
Гариф иргә, бел, җәһәннәмнең газабы берлә тиң
Кермәке кукшы аягы берлә җәннәт багына.

Ач булса да, сабыр ярлының азыктөлеге күп
булган хуҗалар малына һәм бакчасына исе китмәс:
Җәннәткә күрше аягы белән керү,
Бел, аңлы ир өчен җәһәннәм газабы белән бер.

## Дүртенче баб

## Белекле сүзен бүлдермә

Хикаят. Хәкимләрдән бер хәким әйтүр: һич кем ирсә үз җәһленә икърар кыйламас. Әмма ул вакыт мәгълүм булыр кем, бер кеше сүз башласа, сүзе тәмам булмаен, беркем ирсә дәгый уртага сүз китүргәй,— ул галиммәтү җәһел торур.

Мәҗлесдә утурган ир сүзенең,
Белүрсән, әүвәленең ахыры бар.
Качан сүз башласа сохбәтдә бер ир,
Китермә уртага сүз анда, зинһар:
Сүзүң ул ердә сүзләр һәр белекле,
Ки сакит булгай анда җөмлә гөфтар.

Мәҗлестә утырган ир сүзенең,
Беләсең, башының ахыры булыр.
Әңгәмә вакытында бер ир сүз башласа,
Бүлдереп, арага, зинһар, сүз кыстырма
Һәрбер галим үз сүзен тик барысы да
Тынып калган урында гына сөйләр.

---

Хирка — сәләмә кием. Хатир — күңел. Тәсәлли — юату. Кәрәм — юмарт. Хәким — хикмәт һәм акыл иясе. Җәһел — надан лык.

# Бишенче баб

## Коллык һәм мәхәббәт

**Хикаят.** Бер хуҗаның надирелхөсн колы бар иде. Хуҗасы тарикә мөвәддәт вә гайне мәхәббәт белән назар кыйлур иде... Чөн гашыйк вә мәгъшук бер йиргә килде, хуҗалык, дәгый коллык уртадан китте.

Бар иде бер хуҗаның уздан колы,
Ул иде мәхбүбе, яры, шәнгөле,
Чөнки сәүде хуҗа җандан колны бик,
Хуҗасы кол булды, колы булды бик.

## Үпкәләшү һәм үкенү

Әла я күркүзеп җәүр-ү-җәфаны,
Ничөн киттең бозып гаһд-ү-вәфаны?
Сагындым мән сәне, ярө вәфадар,
Вәликин белмәдем буйла җәфакяр.

Килүр булсаң янә, әһлән-вә сәһла!

Катымда мәртәбәң барчадан әгъла.

Җәбер-җәфа күрсәтеп,
Вәгъдә-иман бозып, ничөн киттең, әй?
Мин сине сагындым, җан дустым,
Ләкин бу хәтле дә җәфаларсың дип белмидер идем.

Қабат кайтыр булсаң иде, «хуш киләсең!» дияр идем,

Синең мәртәбәң минем каршымда барчадан өстен!

## Шагыйрьлек өйрәттең

Сәңа бу шивәләр берлән
Күңел алмак кем үгрәтте?
Җәмалыңны күреп, заһид
Тотуп гыйшкың, юлын кисте.

Мәнем каүме-кабилемнең
Камусы галим ирделәр,
Сәнең бу гыйшкың остазы
Мәңа шагыйрьлек үгрәтте.

Бу наз-иркәлекләр белән
Күңел алдарга сине кем өйрәтте?
Матурлыгың күреп, суфый да
Гыйшкың тотып, юлыннан язды.

Минем нәсел-нәсәбемнең
Һәммәсе дә галимнәр иде,
Синең гыйшкың остазы
Миңа шагыйрьлек өйрәтте.

---

Надирелхөсн — сирәк очрый торган матур. Назар — караш.

## Синсез дөньяны күрмәгәй идем

**Екетлек әйямында бер кем ирсә белән мәхәббәт баглап идем кем, күземнең кыйбласы аның җәмалы, дәгый гомеремнең расмалы аның висале иде.**

Көнәш йөзле иде ул лотф кани,
Сүзе мәүзүн, үзе гошшакый җани.

Ул гүзәллек чишмәсе кояш йөзле,
Нәфис сүзле иде, үзе гашыйклар җаны иде.

Җиһанда юк, мәгәр җәннәттә булгай,
Аның тик сурәте мәгъни җиһани.
Нагоһ(ан) вөҗүдинең аякый
Әҗәл балчыкына батты фиракый.

Дөньяның, аның кебек, рухияттән торган заты
Җирдә булмас, җәннәттә генә булыр.
Көтмәгәндә аның тереклек аягы
Әҗәл балчыгына батты — ул аерылды.

**Утына бәгърем янып, күзләрем йөрәк канын акытты; тупракы өстенә ләил вә нәһар мөҗавир булып, бу бәетне укур идем:**

Мән кирәк үлгәй идем,
И гөл бәдән, сәндән борын,
Та күзем сәнсез җиһанны
Күрмәгәй иде бу көн.

Миңа, и гөл тәнле, синнән
Элек үләргә кирәк булган,
Бу синсез дөньяны
Күзләрем күрмәгән булыр иде.

**Дөньяны бөйлә вафасыз күреп, дәгый гомерне илә бәкасыз белеп, әйттем:**

Гөлләрне кайгусында куймаен бер сәгать
Ул, кем оюмас иде, җиһандан китте.

Гөлләрне бер генә дә ялгыз калдырмас өчен
Йокысын йокламас җан — ул дөньядан китте.

| | |
|---|---|
| Дәуран-у-заман йезе гөлене тукубән, | Заман барышы йөзенен чәчәкләрен коеп, |
| Тупракы үзә аның тиканләр бөтте. | Туфрагы өстенә тигәнәкләр үстерде. |

Әййам — көннәр. Висал — кавышу. Ләйл вә нәһар — төн-көн. Мөҗавир — сакчы. Бәка — мәңгелек.

## Үз гаебенә күзе сукыр

| | |
|---|---|
| Алар кем гаебенә хәммал ирүрләр | Җилкаләренә үз гаепләрен төяп йөрүче, алар |
| Ничөн үзгаләргә тәгъна орүрлар? | Ничөн башкаларга төртмә сүзләр белән ташланалар? |
| Күзәтүр үзгә гайбен, сән аны күр:<br>Мәгәр үз гайбенә даим күзе күр. | Кара син аны: үзгәләрдән гаеп эзли,<br>Ә үз гаебенә — һәрвакыт күзе сукыр. |

## Алтынчы баб

## Бер картның үләр алдыннан әйткәннәре

| | |
|---|---|
| Теләдем бер заман күрсәм җиһанны,<br>Дәрига! Булды күзем бәбәке хәс; | Бер вакыт дөньяны күрим дидем,<br>Ах, күзләремнең бәбәкләре алдады! |
| Бер-ике хуш нәфәс ормак теләдем,<br>Нәфәс юлы тотылды, булдым әхрәс. | Бер-ике рәхәт сулыш алырга теләдем,<br>Сулыш юлым буылды, телсез калдым! |
| Җиһан ханиның әлван ниггъмәтендән | Дөнья табыны ниггъмәтләреннән<br>Биш-алты кабым авыз иттем. «Җитте!» диделәр. |
| Биш-алты лөкъмә йидем, әйттеләр: «Бәс!» | |

## Ана һәм бала

Хикаят. Бер көн Рөстәм анасына катты сүзләде. Аның күңле агрыб, еглап әйтте: «Мәгәр кечелекне оныттың кем, олуглык итәрсән».

| | |
|---|---|
| Анасы әнҗинеб Рөстәмгә әйтте:<br>«Әй күргән үзен гайрәтле арслан,<br>Әгәр булса иде ядыңда ул көн<br>Кем, әлемдә идең бер яшәр углан,<br>Бу көн бәйлә маңа җәүр итмәс идең,<br>Ки сән бер пәһлуан, мән бер карчык жан!» | Анасы үртәнеп Рөстәмгә әйтте:<br>«Әй үзен гайрәтле арслан күрүче,<br>Әгәр кулымда бер яшьлек бала чагың<br>Исеңдә булса иде,<br>Бүген мине, картайган кешене,<br>Җәберләмәс идең син, бер пәһлеван». |

## Дөньядан туймаган

Карп булдың, екетлектән әлең ю,
Белүрсән кем, янә кайтмас акар су.

Екетлекне екетләргә куеп кит,
Бу көн таңда өчен күп игүлек ит.
Печин вакты килеп, богдай йитиптер,
Күзең ач уйкудан кем, таң атыптыр.

Бизәнеп бер карп хатун, теше аз,
Буяп сачын карага, күп кыйлур наз.
Мән әйттем: «И озын яшьле ана, кәл,
Йитәр, кыска кыйл имди хәйләдән әл.

Киселле йөк котүргән көч биленлән,
Китепдер назик ирдәмләр әлендән.
Белүрсен кем, кыйлып бер хәйләне йөз,
Билең бөкрилеге булмас янә төз.

Җәмалың багы гөлзары сулыптыр,
Озын гомрең дагый ахыр булуптыр»...
Ул әйтте: «Раст әйттең и екет, сән,
Нидәем кем, җиһандан туймаеп мән!»

Әлең ю — кул селтә. Танда өчен — иртәге көн өчен. Назик ирдем — нәзакәтле һөнәрләр. Гөлзар — чәчәклек.

## Сигезенче баб

### Кисәтү

Эчерепиләгә кашык берлә шурпа,
Чүмеч сабы белән күзен чыгарма.

### Юмартлык пальмасы

Канда кем сахиб кәрәм
Тикте сәхавәт нәхлене,
Күкләрә чыкты ботаклары
Аның рәфгат белән.

Гәр йимешендән теләсәң
Кем алып зәукъ итмәгә,
Ормагыл пычкы аягы
Өстенә миннәт белән.

Юмартлык чәсе кайда
Юмартлык пальмасын утыртса,
Шунда аның ботаклары
Биеклеге белән күкләргә сузылды.

Әгәр син аның җимешләреннән
Авыз итәргә теләсәң,
Үз өстенә бурыч алып,
Кәүсәсенә пычкы сала күрмә.

### Уйлап ат

Тере ирне иңән асан
Орып ук берлә үлтүрмәк,
Вә ликин бер үлүне мең
Кем ирсә тергезә белмәс.

Әя ук аткучы, яхшы
Сакышлап әлек, андан ат:
Белүрсән, ук качан ядан
Чыкар булса, янә килмәс.

Тере ирне ук атып,
Үтерү бик ансат,
Ләкин бер үлене мең
Кеше дә терелтә алмас.

Әй укчы, башта
Яхшылап уйлап, аннан ат:
Беләсен ич, ук җәядән бер
Чыгып китсә, кире кайтмас.

### Үз туның газиз

Хикмәт. Солтан хилгате ничә кем газиз исә, һәрбер кешегә үз туны андан газизрәк.

Никаләр кем бикләр ашы
Татлы булса, и кунак,
Ярлы-юксулга кору
Итмәке андан яхшырак.

Хилгать — зиннәтле халат. Итмәк — икмәк.

## ӘХМӘД ХУҖА ӘС-САРАИ ШИГЫРЕНӘ НАЗЫЙРӘ

### Сәйфи Сараи әйтүр

Дилбәремнең зөлфе сөнбел,
Чәһрәсе гөлзар ирүр,
Буена гашыйк санаубәр,
Йөзенә гөл зар ирүр.

Агзы фестук, күрке тансук,
Үзе мөшфикъ яр ирүр,
Хөсненең җавы Хита вә
Чин эчендә бар иоуо.

Сөйгәнемнең чәче сөнбел,
Йөзе — чәчәклек,
Буй-сынына нарат гашыйк,
Йөзенә гөл зар булыр.

Авызы пестә, күрке тансык,
Үзе шәфкатьле яр,
Матурлыгының нуры Чин
Һәм Кытайда балкыйдыр.

Аслы Алчин, сүзләре чын,
Күзләре татар ирүр.
Мең яшәр һәр кем дудагы
Шәрбәтен татар ирүр.

Гыйшкының илчесенә күңлем
Мөнаккаш дар ирүр.
Зөлфенә төшкән күңелләрнең
Мәкаме дар ирүр.

Ничә кем гыйшкы уты
Бу җан эчендә бар ирүр.
Кәһрөбә үзрә күземдән
Дәмбәдәм дөрбар ирүр.

Шәһд сүзе, гариф үзе
Вакыйфи әсрар ирүр.
Васлы бөстанында хуш
Гашыйкларын асрар ирүр.

Васфына Сәйфи Сараиның
Эше ишгар ирүр.
Андан үзгә берлә гашика
Язак әшгар ирүр.

Үзе Алчин, сүзләре чын,
Күзләре татар.
Аның иреннәренең балын
Татыган кеше мең ел яшәр.

Аның гыйшкы илчесе өчен күңлем —
Зиннәтле сарай,
Ә инде аның чәч бөдрәләренә
Капкан күңелләрнең соңгы урыны —
дар.

Бу бәгъремдә аның
Гыйшкы уты булганга,
Күзләремнән гәүһәр бөртекләре
Бер-бер артлы түгелер.

Сүзе бал, үзе акыл иясе,
Үзе серләрне белүче,
Үзе ягымлы гашыйкларын
Кавышу бакчасында асрый.

Сәйфи Сараиның эше
Аның сыйфатлары турында хәбәр бирү.
. . . . . . . . . .
. . . . . . . . . .

# МӘҮЛЯНА ИСХАК ШИГЫРЕНӘ НАЗЫЙРӘ

Тәгалә аллаһ зиһи сурәт,
Зиһи мәхбуби рәүхани.
Кем аның хөсни шәүкындан
Күңелләр булды нурани

Мөфәррих шивәле дилбәр
Теле тутый, сүзе шәккәр,
Киек күзле, камәр манзар,
Малахәт мөлке солтани.

Күңел алыр күзе али,
Фәрех бирүр ине али,
Буедыр сәрвинең тали,
Йөзе җәннәт гөлстани.

Көнәш тик билгеле шәһид,
Җәмалы каүлемә шәһид,
Кичәр хәсрәт белән зәһид
Еракдан күрмәгә ани.

Әла и дилбәри мәнзур,
Бу күркенә булып мәгъруp,
Күңелләр кыйлмагыл рәнҗүр:
Кичәр бу хөсне дәүрани.

Бу мөддәтне ганимәт бел,
Бу форсатда вафалар кыйл,
Бу гыйззәт берлә бул күп ел,
Хәлаикның сәвәр җани.

Кашың чөн бәйрәм аедур,
Җиһан хөснең гыйдаедүр,
Колың Сәйфи Сараидур,
Бу көн ул сөнгы хәйрани.

Я ходай, нинди сын!
Нинди гүзәл рухани мәхәббәт!
Аның чибәрлеге дәртеннән
Күңелләргә нур тула.

Назлы кыланышы белән шатландыручы
яр,
Теле тутый, сүзе шикәр аның,
Киек күзле, айдай күркле,
Гүзәллек иленең солтаны.

Күзләренең уйнавы күңелне билә,
Битләренең алы сөендерер,
Буе — сәрвинең яшь талы,
Йөзе — җәннәт бакчасы.

Кояштай билгеле танык,—
Бу сүземә матурлыгы шаһит.
Хәсрәт белән үтә зәһид
Еракдан күрмәгә аны.

Әй өметем, сөйгән ярым,
Бу күркенә мәгъруp булып,
Күңелләрне газаплама:
Бу чибәрлек заманың үтәр;

Бу вакытыңның кадерен бел,
Бу форсаттан файдаланып кал,
Бу даның белән күп еллар яшә
Син, халыкның сөяр җаны.

Кашың бәйрәм ае кебек,
Дөнья — матурлыгыңа интизар.
Бу Сәйфи Сараи — колың:
Ул бүген ходайның бу сәнгатенә хәйран

# ТАЛӘПЧӘН ХУДОЖНИК

*«Һәр сүз өчен
Шагыйрь гомеренең
Минутлары корбан итела».*
*Зыя МАНСУР.*

„Зыя Мансур шигырьләрен никтер «Бөтнек чәчәкләре» белән чагыштырасы килә. Алар да артык күзгә бәрелмиләр, кайдадыр читтәрәк үсеп утыралар, таптыңмы — тиз генә аерыла алмыйсың».

Зыя Мансур поэзиясе турында уйланганда, Сибгат Хәкимнең шушы сүзләре искә төшә. «Бөтнек чәчәкләре» шигыренең авторына бу сыйфатлар чыннан да хас иде бит. Тыйнаклык, хисләрнең сафлыгы, үзенчәлекле шигъри аһәң, җыйнаклык һәм табигыйлек — Зыя Мансур кеше буларак та, шагыйрь буларак та шундый иде.

«Язгы ташкыннар», «Омтылу», «Казан җыры», «Ләйсән», «Уйланулар», «Сайланма шигырьләр», «Кырлар сулышы», «Ак розалар»... Болар — З. Мансурның шигырь җыентыклары. Күпме байлык! Ә бит безнең арабыздан киткәндә аңа әле 49 яшь тә тулмаган иде. Озак елларга сузылган каты авыру да аның иҗат энергиясен кимәтә алмады, искиткеч эшчәнлеге, тырышлыгы белән ул чын мәгънәсендә батырлык үрнәге күрсәтте.

Соңгы елларда Матбугат йортыннан әйләнеп кайту да аңа гаять авыр була иде. Ул туктап ял итә-итә генә йөри иде. Ләкин иҗатта ул тукталуны да, ялны да белмәде. Ул туктаусыз язды, туктаусыз эшләде, эзләнде. Ул, әйтерсең лә үзенең бөтен күңел байлыгын, бөтен хисләр тирбәлешен шигырьгә күчереп калырга ашыга иде. Соңгы шигырьләреннән берсендә:

**Юк!**
**Каләмнән башка яши алмыйм,**
**Мең кат артты аңа якынлык,**
**Килгән картлык әйдә килә бирсен,**
**Җырламаска минем хакым юк! —**

дип, ул үзенең тормыш белән тыгыз бәйләнештә яшәвен ачык әйтте. Һәм бу дөрес иде. Зыя Мансур чын күңелдән куанып, һәр яңалыкта, тормышның һәр күренешендә шигырь күреп яшәде.

Ул үзенең әсәрләрен укучы күңеленә барып җитәрлек дәрәҗәдә эшләү өчен күп көч куйды, үзенә дә, иптәшләре иҗатына карата да искиткеч таләпчән һәм кайгыртучан булды. Аның зур поэзияне яклаган чыгышлары, рецензия һәм мәкаләләре, образлы итеп әйткәндә, ут чәчеп торалар иде. Зыя Мансур күп яшь каләмнәрнең ныклап аякка басуына чын күңелдән ярдәм итте.

Зыя Мансур язлар һәм чәчәкләр турында гына җырлаучы шагыйрь булудан ерак торды. Ул көрәшче шагыйрь иде. Тормыштагы якты, матур якларны күреп соклану белән бергә, һәр бозыклыкка, кара эчлелеккә, һәр кимчелеккә каршы ул үткен сатира уты ачты. «Сүз» дигән бер генә строфалы шигырендә аның бу сыйфаты гаять төгәл чагыла:

**Урагым шул минем,**
**Чүкечем шул.**
**Зурлыйм да мин аны,**
**тыңлыйм да.**
**Дус иңенә салган кулым да шул,**
**Дошманымны кырган**
**тубым да.**

Мәхәббәте дә, нәфрәте дә чын шигъри төгәллек белән, күңел түрендә туган саф хис белән сугарылган иде аның. Зыя Мансурның шигырьләре безнең белән бергә яшәүләрен дәвам иттерәләр. Аның иҗаты танылганнан танылa бара. Зыя Мансур иҗаты — хисләргә дә, төсләргә дә бай. Ул зур мәкаләләрдә җентекләп өйрәнүгә лаек.

З. МӘҖИТОВ.

## Түгәрәк өстәл тирәсендә

*Гариф Гобәй*

# МИНЕМ ҖАВАПЛАР

I

Журнал битләрендә укучы хатларына җавап бирү гадәткә кереп бара. Бу бик әйбәт яңалык.

Г. Әпсәләмов, Ш. Маннур. Инде редакция миңа «Коръән серләре» турындагы хатларга җавап бирүне тәкъдим итте һәм мин бу эшкә рәхәтләнеп алындым.

Билгеле булганча, минем әсәр һәркем ихтирам итә торган фидакарь совет врачлары турында түгел, һәркемнең горурлыгы булган патриот шагыйрь турында да түгел. Минем әсәрнең максаты — ана телебездә булмаганга күрә генә хәзергә кадәр күпләр өчен изге саналган Коръәннең серләрен ачу. Әлбәттә, монда һәркемнең ихтирамын яулауга, һәркемнән рәхмәт ишетүгә исәп тоту — сабыйларча оптимистлык булыр иде. Мин бу китап өчен ниндирәк кешеләрдән җилкәмә тукмакның нинди төшәсен белеп керештем. Җир Коръән һ. б. дини китаплардагыча яссы түгел, бәлки түгәрәк дигән өчен генә дә динчеләрнең Коперник, Бруноларны тереләй утка салганнарын белә идем мин.

Маркс белән Ленинның: «Дин — халыклар өчен әфиюн», «Дин — җәмгыять өчен хурлык, дин — җәмгыятьнең палачы», дигәннәре өчен рәхмәт ишетмәгәннәрен белә идем. Гомәр Хәйям, Насыйр Хөсрәү, Әбугалисиналарның алла исеменә юнәлтелгән әче сатира уклары өчен ничек эзәрлекләнгәннәрен белә идем. Бөек Тукай, Сәгыйт Рәмиев, Кәрим Тинчурин, Нәкый Исәнбәт һ. б. һ. б. бик күпләрнең дингә каршы әсәрләре өчен ничек каһәрләнгәннәрен белә идем. Үземнең адресыма да кимендә шуны көттем, һәм ялгышмадым.

Әсәрнең бер өлеше «Азат хатын»да пәйда булу белән, минем исемгә усал хатлар ява башлады. Мин аларны өч төркемгә бүлеп, өч папкага салып куйдым.

Беренче төркем. Болар — Коръәнне, кайчандыр мәктәптә мулла укытканча, әби-бабасы сөйләгәнчә, дип белүчеләр. Укый белә алар аны. Әлхәм, Ясин, Тәбәрәк кебекләрне яттан белә. Ә мәгънәсен — юк. Белүне кирәк тә санамыйлар. Һәр хәрефе изге, бу турыда шик булырга да мөмкин түгел... Иманнары аз гына да какшамаган, заманыбызның теләсә кайсы мулла яки мөфтиенекеннән көчле. Мөфтиләрнең шәригать гамәлләренә җиңеллек кертүләренә дә шикләнеп карыйлар. Урыс картузы, тар чалбар кигән мөселманнар янынннан әле дә әстәгъфирулласыз узмыйлар. Битен томаламаган, ир-ат алдында тел яшермәгән хатын-кызны чәйнәп ташларлар иде.

Диннәр тарихында шундый вакыйга мәгълүм. Безнең гасыр башында Кавказ мөселманнары дуңгыз кылыннан бәйләнгән пумала белән агартылган икәне белленгәч, мәчетләренә ут төртәләр. Мин әйткән агайлар да, әлбәттә, шуны ук эшләр иделәр. Андыйлар, әлбәттә, «Коръән серләре»н кулларына да алмаганнар. Ә колакка кергән... Шундыйларның берсе (имзасы юк, Нәмәгълүм агай дип атыйк) миңа менә нәрсә яза:

«...торганы ялган бит, кабахәт бәндә. Имеш, пәйгамбәребез Мөхәммәт Мостафа саллаллаһи галәйһиссәләм гарәпләрне иман китертергә теләгән, ә аллаһ тәгалә вә тәбәрәкә вә тәгалә хәзрәтләре каршы килгән... Кемне ышандырмак буласың, тәмуг кисәве!»

Һәр укучыны, шул җөмләдән Сезне дә, Нәмәгълүм агай, Хәрәкәле гарәп хәрефләрен күргәч, бәлкем, игътибар итәрсез дип, Коръәннең Сезне миңа нәгърә орырга

мәҗбүр иткән мәсьәләгә караган берничә урының тәкъдим итәм. Сездә шик калмасын өчен, аятьләр Коръәннен революциядән соң түгел, 1787 елда басылганыннан күчерелде. Алла (ә безнеңчә Мөхәммәт үзе) әйтә Мөхәммәткә:

ان تحرص على هديهم فان الله لا
يهدى من يضل وما لهم من
نصرين ۞

«Син аларны тугыры юлга кертергә телисең. Ә алла үзе аздырган бәндәләрне туры юлга кертми. Аларга ярдәмче юк».

*(Коръән, «Нәхл» («Бал кортлары») сүрәсе, 39 нчы аять.)*

واذا قرات القران جعلنا بينك
وبين الذين لايؤمنون بالاخرة
حجابا مستورا ۞ وجعلنا على
قلوبهم اكنة ان يفقهوه وفى
اذانهم وقرا

«Син Коръән укыганда кыямәт көнгә ышанмаучылар белән синең арага без пәрдә корабыз. Алар Коръәнне аңламасын өчен без аларның йөрәкләрен томалыйбыз, колакларын чукракландырабыз».

*(Коръән, «Әсра» («Бәни Исраил») сүрәсе, 47—48 нче аятьләр.)*

ومنهم من يستمع اليك وجعلنا
على قلوبهم اكنة ان يفقهوه وفى
اذانهم وقرا

«Алар арасында синең сүзгә колак салырга теләүчеләр бар. Ләкин, Коръәнне аңламасыннар өчен, без аларның йөрәкләрен томалап куйдык. Колакларын ишетмәс иттек...»

*(Коръән, «Әнгам» («Хайван») сүрәсе, 25 нче аять.)*

ونقلب افئدتهم وابصارهم
كما لم يؤمنوا به اول مرة ونذ
رهم فى طغيانهم يعمهون ۞

«Иман китермәсеннәр өчен, без аларның йөрәкләрен һәм күзләрен әйләндерәбез, сукыр килеш бозык юлда йөртәбез...»

*(Коръән, «Әнгам» («Хайван») сүрәсе, 110 нчы аять.)*

Хакыйкать әнә шундый, Нәмәгълүм агай.

Алланың мәзәге монын белән генә бетми әле. Кешене шул рәвештә бозык юлда йөртә-йөртә дә, ник туры юлда йөрмәдең дип, кул-аякларын богаулап, җәһәннәмгә олактыра.

Минем максатым, Нәмәгълүм агай, Сезгә бу аятьләрне фәкать күрсәтеп китү генә иде. Авызны бер ачкач, туктап буламени... Әйдәгез, уйлап карыйк әле. Әгәр алла чыннан да булса, шундый хаинлекне эшләр идеме?

Әйтергә кирәк, Коръәндә мондый аятьләр булуга Нәмәгълүм агай кебекләр генә түгел, диннәре менә сүнәм, менә сүнәм дип торганнар да, хәтта дин белән алыш-биреше күптән өзелгән иптәшләр дә ышанып бетми. Ләкин, рус әйтмешли, что написано пером, не разрубишь топором. Мөхәммәт мондый аятьләрне гомеренең азагына кадәр дәвам итә.

مثلهم كمثل الذى استوقد نارا
فلما اضاءت ما حوله ذهب الله بنو
رهم وتركهم فى ظلمت لا يبصرون ۝

«Алар (ялгыш юлдагылар — Г. Г.) гүя учак кабызучылар. Ут учакның әйләнә-тирәсен яктырта, ә алла утларын алып китеп, аларны караңгыда калдыра. Алар күрми».

*(Коръән, «Бәкарә» («Сыер») сурәсе, 16 нчы аять.)*

Һәм алла (безнеңчә, Мөхәммәт) кешеләрне шул рәвешле ялгыш юлда йөртүен менә ничек аклый:

ولو شئنا لاتينا كل نفس هديها
ولكن حق القول منى لاملئن
جهنم من الجنة والناس اجمعين ۝

«Әгәр теләсәк, без бөтен кешеләргә туры юл күрсәтер идек. Ләкин, Минем җәһәннәмне җеннәр һәм кешеләр белән тутырачакмын дигән хак сүзем бар».

*(Коръән, «Сәҗдә» сурәсе, 13 нче аять.)*

Бу хаинлекнең җир йөзендә, әлбәттә, тиңе юк. Җир шартларына күчереп, чагыштыру өчен аны ясарга гына мөмкин. Патша үз халкының күзләрен бәйләп, колакларын томалап ялгыш юлда йөртә-йөртә дә, ник туры юлда йөрмәдегез дип, зинданга куып кертә. Ник? Чөнки, ул әллә кайчан бөтенесенә җитәрлек итеп зиндан салып куйган икән. Буш тотмас ич инде!..

Бу төркемдәге хатлар арасында Воркутадан язган Фәрхенур ханым Нигъмәтуллина хаты бераз йомшаграк. Шулай да, аның минем исемгә иң мөлаем сүзе: «Гайбәтче карчык».

Ул да, билгеле, Нәмәгълүм агай кебек сукыр ышанучы, Коръәнне ата-бабадан ишетү буенча гына изге китап дип белә. «Нигә пәйгамбәрләребезнең тарихларын бозып яздың», ди ул. «Мәрьям ана кечесенә чыкканнан соң мамык белән сөртү аркасында корсакка кала. Ни өчен сез дөреслектән качып язасыз!» һәм башкалар.

Менә нәрсә, Фәрхенур ханым. Мин нәкъ Коръәндәгечә яздым. Тәфсир, Кассас-әл-әнбия һ. б. дин китапларының Коръән аятьләре белән расланганнарын гына файдаландым. Ә сез сөйләгәннәр, беренче чиратта, һәм Коръәнгә, һәм Тәуратка, һәм Инҗилгә каршы киләләр.

Менә нинди юл белән корсакка кала Мәрьям ана:

فناديها من تحتها الا تحزنى قد
جعل ربك تحتك سريا ۝

«Алла Мәрьям астыннан эндәште: Кайгырма, Мәрьям, аллаң синең астыңа чишмә агызды».

*(Коръән, «Мәрьям» сурәсе, 24 нче аять.)*

والتى احصنت فرجها فنفخنا فيها

من روحنا وجعلنها وابنها اية

للعلمين ۝

*«Үзенен кызлыгын саклаган кызга без үзебезнен рухыбызны өрдек...»*

*(Коръән, «Әнбия» сурәсе, 91 нче аять.)*

Менә шулай, Фәрхенур ханым, Коръәнне якларга алынган икәнсез, мисалларны әбиләр әкиятеннән түгел, Коръәннең үзеннән алыгыз Сез.

Сафа иптәш Сөләйманов та Фәрхенур ханым кебек үк Коръәндә бөтенләй булмаган хорафатларны тыңлап үскән булса кирәк. Шуларны яклап бугазга бугаз килергә әзер. Ләкин аңлагыз, Сафа туган, динчеләр уйлап чыгарган әкиятләр Коръән түгел әле алар. Аларның тик Коръән белән аваздаш булганнары гына игътибарга лаек. Сез ишеткән әкият буенча, туфан вакытында Мөхәммәт тә була. Шуны яшереп калганым өчен сез минем кулларым коруын телисез. Юкка көчәнү! Алла булса да догагызны кабул итмәс иде. Киресенчә, үзегезгә берәр җәза бирер иде ул. Чөнки Сез дә, Фәрхенур ханым кебек үк, Коръәнгә каршы киләсез. Коръән өйрәтүләре буенча, Нух белән Мөхәммәт арасында аз дигәндә ике дистә пәйгамбәр килеп китә. Чынлыкта исә, ике дистәсе дә миф.

Коръән, дини китаплар Фәрхенур ханым белән Сафа иптәш канына шулкадәр сеңгәннәр ки, бу китаплар кап-караны ак диләр икән, болар шуна да ышана. Мәсәлән, тормышта талау, алдау, дошманга хезмәт итү кабахәт дигәндә дә кабахәт эш. Ә менә Иосыф пәйгамбәр кяфер патшаның баш министры булып хезмәткә керә дә ачлык елларында тирә-юньдәге халыкларны, шул исәптән хак диндәгеләрне дә, талап ята. Шул бәндә, Фәрхенур ханым белән Сафа ага карашынча, изге дигәндә дә изге зат!

«Нигә син, фәлән-фәсмәтән кеше, тел тидерәсең шундый изге затка!» — ди Сафа иптәш. Тагын: «Нигә син, язучы, бу изгеләрнең тарихын бозып күрсәтәсең? Зөләйха башта бер сукыр карчык була бит. Иосыф алдында битен ачып җибәргәч, шундый сылу кызга әйләнә...» «Изге китапны пычрату нигә кирәк! Коръәнгә үрелгән кешенен куллары корып бетәчәген ничек оныттыгыз!?»

Минем өчен шунысы куанычлы. Ул моны журналдан «Коръән серләре»нең икенче кисәген укыгач язган иде. Менә аның китапны бөтенләй укып чыккач, минем хатка язган җавабыннан өзекләр:

«...Хатың кыска булса да, кызыклы хисләр уятты... Сез минем хатым өчен кәефегезне бозмагыз... Сезгә зур уңышлар телим... Соңгы рәсемегезне җибәрегез...» — Менә нәрсә язды Сафа иптәш китапны укып чыккач...

Мин Фәрхенур ханымны да дингә иң бирелгән фанатиклар төркеменә кертсәм дә, Нәмәгълүм агай кебек үк өметсез күрмим. Анарда да хакыйкатьне белергә теләү төсмерләнә. Һәм мин, өметсез шайтан дигәндәй, кайчан да бер бу ханымның да дин турында фикерләре уңай якка үзгәрәчәген өмет итәм.

## 2

Укучыларның бик күбесе «Коръән серләре»ндәге әдәпсез сүзләрнең, шулай ук Мөхәммәт үрнәгендә бозыклыкка өйрәтә торган аятьләрнең Коръәннән күчерелгән идекләренә ышанмыйлар. Бу төркем укучыларның минем исемгә иң ягымлы сүзләре «кабахәт» тә «ялганчы», «тәмуг кисәве». Имзасыз бер хат авторы белән Ташкент картлары исеменнән язган Зөһрә ханым Хәмитованың эпитетлары тагын да «ягымлырак».

Шулай да бу кешеләр минем ачуымны китерми генә түгел, шатландыралар. Мөхәммәтнең Мәккә кяферләрен иман китертергә теләве, ә алланың моңа каршы килүе турындагы, Мөхәммәтнең Мәдинәгә күчеп килгәч, христиан, яһүд, ислам диннәре арасында аерма күрмәве турындагы һ. б. шуның кебек аятьләргә укучыларның ышанмаулары мине шулай ук шатландыра. Менә ни өчен. Болар, диннәре көчле булса да, Коръәндә нәрсә язылган — шул дөрес дип караучылар түгел, үзләре дә сизмәстән, Коръәнгә тәнкыйть күзе белән карау юлына баскан кешеләр.

Мондый иптәшләрнең Коръәнгә булган мөнәсәбәтләрен үзгәртү өчен, Нәмәгълүм агайга күрсәткән кебек, мина сүзләремне Коръән аятьләренең гарәпчәләрен төртеп күрсәтү юлы белән дәлилләргә генә кала.

Рәхим итегез.

ولا تكرهوا فتيتكم على البغاء ان
اردن تحصنا لتبتغوا عرض الحيوة
الدنيا ومن يكرههن فان الله من
بعد اكراههن غفور رحيم ۞

«...Гыйффәтле килеш яшәргә теләгән кол кызларны бозык эшкә көчләмәгез... инде тотып алып көчлисез икән, алла көчләүчеләрне гафу итүче. Шәфкатьле бит ул алла...»

*(Коръән, «Нур» сүрәсе, 33 нче аять.)*

Мөхәммәт, асрамага алган улының хатынын тартып алгач, янәсе аңа алладан шундый вәхи килә:

فلما قضى زيد منها وطرا
زوجنكها

«...Ул хатын белән Зәет үзенең теләген үтәгәч, без аны сиңа өйләндердек...»

*(Коръән, «Әхзаб» сүрәсе, 37 нче аять.)*

نساؤكم حرث لكم فاتوا
حرثكم انى شئتم

«...Хатыннар — сезнең чәчү җирләрегез, үзегезнең ул чәчү җирләрегезгә теләсәгез кайчан барыгыз...»

*(Коръән, «Бәкарә» сүрәсе, 223 нче аять.)*

«Коръән серләре»ндә телгә алынган аятьләрнең бөтенесен шул рәвешчә күрсәтеп бирергә булыр иде. Моны Зөһрә ханым кебекләр генә түгел, дин мәсьәләсендә уйлы-шуйлы иптәшләр дә, динсезләр дә, хосусән, атеист-лекторлар үтенеп сорый. Ләкин типографиядә гарәп хәрефләре юк, ә һәр хәрефнең клишесын ясау — ифрат мәшәкатьле эш, аннан моның өчен журналның мәйданы да тар. Шуңлыктан гафу үтенү белән чикләнергә туры килә.

Әдәпсез аятьләр турында тагын мондый караштагы динчеләр бар. Алар бу аятьләрнең Коръән сүзләре булуларына ышанмау белән бергә, китапка керткән өчен мина нәгъре оралар: «Оятсыз сүз! Җирәнгеч сүзләр!..» Ә үзләре шул оятсызның, җирәнгеч сүзләрнең гарәпчәсен бөтен дөньяларын онытып укыйлар. Мулла мәчеттә, аш мәҗлесендә укыганда эреп утыралар. Мәет өстендә укыганда елый-елый иреннәрен лепелдәтәләр: Амин, хәзрәт, амин, хәзрәт... Хәзрәт күбрәк, тәэсирлерәк, кычкырыбрак укыса, садакага адарынган саргылт кәгазьне яшеле алмаштыра...

Минем максатым, күңелләрегезне эреткән, сезне елаткан сүзләрнең нәрсә икәнен фаш итү, муллага нәрсә өчен бәлеш ашатуыгызны, нәрсә өчен садака бирүегезне күр-

сәтү. Бәс Коръән сүзе булгач, оятсыз, җирәнгеч булса да әйбәт диючеләр бар икән, андыйларны бирәү дә кечләми, рәхим итеп дәвам итә бирсеннәр.

Мондый әдәпсезлекне балаларыбызга ничек күрсәтергә, ди Коми АССРдан имза куймый язучы бер иптәш.

Беренчедән, бу китап балалар өчен түгел. Ә олылар китабында нәрсәләр генә булмый!.. «Декамерон», «Хыянәтчел һәм хыянәтсез хатыннар», «Мең дә бер кичә»нең тулы басмасы, «Батыр солдат Швейк» һ. б. шундый бик күп китапларны хәтерләгез. Әлбәттә, аларны балаларга күрсәтмәскә тырышу хәерле. Ә моны, «Коръән серләре»н, курыкмагыз, күрсәтегез, һәм әйтегез үзенә: менә без, син өйрәнә торган дөнья гыйлеме урынына шуларны ятлап миебезне черттек, революция булмаган булса, син дә бүген шуларны ятлап утырыр идең, диегез.

Балагыз, бераз кызарса да, дөрес тәрбия алган булса, бу әдәпсез сүзләрнең китапка ни өчен кертелгәнен аңлар, сезнең заяга үткән гомерегез өчен көенер, үзенең бүгенге хәленә сөенер.

3

Хатларның икенче төркеме иманы керәле дә чыгалы иптәшләрдән. Алар инде шәригатьнең мәшәкатьле гамәлләрен, сәламәтлеккә зыян итә торганнарын, бигрәк тә адәм мәсхәрәсе диярдәйләрен әллә кайчан ташлаганнар. Болар сукыр ышанучы түгел.

Ураза фарыз. Ягъни аны тотмаган кеше мөселманлыктан ваз кичә. Ә «керәле дә чыгалы», кепка козырегын артка каратып киеп гаетенә барып кайта да, шуның белән вәссәләм.

Намаз бигрәк тә фарыз. Аны хәтта сугыш кырында да калдырырга ярамый. Фәкать искәртмәстән дошман гаскәре килеп чыгып әсир итү, кырып ташлау куркынычы булганда гына берникадәр льгота бирелә. Андый чакта кыскартып укырга рөхсәт. Бер төркем укый, икенче бер төркем коралын тотып сакта тора. Аннары болары укый, тегеләре сакка баса. Хәтта әнә шунда да намазны калдырырга ярамый.

*(Коръән, «Ниса» («Хатын-кыз») сурәсе, 102—103 аятьләр.)*

Ә «керәле дә чыгалы»ның намаз сугыш кырында түгел, өендә дә ике ятып бер төшенә керми.

Коръән буенча, дуңгызның гына түгел, агүзе-бисмилласыз суелган сарык итенең дә никадәр хәрам ризык икәнен белә ул. Ә ял йортларында, курортларда, ашханәдә нәрсә ите дип сорап та тормый.

П ә р ә н җ ә турында китабымда аятьләрне күп китердем. Бу турыда Коръән аеруча каты куя. Мөслимә урамга чыкканда үзен танытмаслык итеп пәрәнҗә бәркәнеп чыгарга тиеш. Ә «керәле дә чыгалы» хатын-кызлар инде яулыкны да ташлады. Әбиләр башында күренгәли әле, алар да күбрәк арттан бәйләгән. Ә ир мескен бүрек, кәләпүшне әллә кайчан ташлаган. Урыс кәпәче, яисә ялан баш. Ә менә гомергә бер килә торганнарын үтәп бара. Баласын өйләндергәндә беренче нәүбәттә никах. Ныгына — сөннәт. Вакыты җиткәнне сизенсә, иң беренче васыяте — кәфенләп күмегез, хәзрәт Коръән чыксын...

«Керәле дә чыгалы» иптәш фән белән бераз таныш. Шунлыктан Коръәннең күп урыннары белән килешми. Шуңар күрә автоога Нәмәгълүм агай, Фәрхенурлар кебек үк нәгърә ормый. Мондый иптәшләр дә күбрәк имза куймый язалар. Шундыйлардан берсе, Коръәннең табигать һәм «табиплык гыйлеме» турындагы урыннарына карата: «Ул заман кешесенең б е л е м е ш у л д ә р ә җ ә д ә б у л г а н б и т, нигә бәйләнәсең?» ди.

Хикмәт тә шунда шул — кешенең. Бу мәсьәләдә кешегә (Мөхәммәткә) безнең дәгъва юк. Ул шулай дип белгән, шулай язган. Ләкин сез Коръәнне, кеше түгел, Мөхәммәт түгел, алла язган дип барасыз бит. Бөтен дөньяны юктан бар итүче, аның бөтен серләрен белүче кодрәт иясе язган дип беләсез. Алайса, нигә соң аның ул заманда «белеме шул дәрәҗәдә булган», үзе ясаган галәм турында ялгыш мәгълүмат биргән, нигә хәзер безнең 7—8 класс белемле булган балаларыбыз белгәнне дә белмәгән? Һич югында, Җирнең палас кебек яссы түгел, түгәрәк икәнен, Кояшның һәр кич Җирдәге сасы суга төшеп баемаганын, Кояшның гомумән баемаганын һәм баюы мөмкин дә булмаганын белергә иде ана. Баланың бер аталык орлыгыннан гына яратылуы мөмкин түгел икәнен белергә иде. Уйлап карагыз әле, шулай түгелме?

Тагын. Алла чыннан да булып, Коръән аның сүзе булса, әлбәттә, ул үзенең бу изге китабын менә мондый әкәмәтләр белән «бизәп», үзен бөтен галәм алдында көлкегә калдырмас иде.

وَإِنَّ لَكُمْ فِى الْأَنْعَامِ لَعِبْرَةً نُّسْقِيكُم
مِّمَّا فِى بُطُونِهِۦ مِنۢ بَيْنِ فَرْثٍ وَدَمٍ
لَّبَنًا خَالِصًا سَآئِغًا لِّلشَّٰرِبِينَ ۝

«Сезнең өчен мал-туарда да гыйбрәт алыр нәрсә бар. Без сезгә аларның корсакларындагы каннары белән тизәкләре арасыннан саф һәм тәмле сөт савып эчерәбез».

*(Коръән, «Нахл» сүрәсе, 68 нче аять).*

4

Дине «керәле дә чыгалы»лардан Фәйрүзә ханым (адресы юк) Коръәнне берничә мәсьәләдә, аерым алганда, пәйгамбәрләрнең кыргый вә әхлаксыз мажараларын акларга тырышып яза. Аныңча, Ибраһим пәйгамбәр — Сара абыстай — асрау кыз арасындагы романның гаеп итәр җире юк. Аныңча, бу хәтта изге роман. Абыстай бала таба алмагач нишләсен, җирдә пәйгамбәрнең нәселен калдырырга кирәк ләбаса... Аныңча, Лут пәйгамбәрнең кунак егетләрен көчләргә килгән бозык ирләргә үзенең сөекле кызларын тәкъдим итүе дә гаеп түгел, хәтта изге. Кунак кадерен белгән, янәсе.

Әйтегез әле, Сез, Фәйрүзә ханым, үзегез шундый «кунакчыллык»ны эшләр идегезме? Юк бит? Әлбәттә, сез бу очракта да, заманы башка булган, диярсез. Берләнән, кызларын шәһәрнең азгын ирләренә мәсхәрә иттерер дәрәҗәдә ук «башка» булмаган, икенчедән, Коръән — шәһәр Советы карары түгел, шул заман өчен генә чыгарылмаган. Аның хөкеме кыяматкәчә үзгәрмәскә тиеш.

Ибраһим пәйгамбәр — Сара абыстай — асрау кыз арасындагы романны аклавыгыз шулай ук нигезсез. Биредә дә сезнең үзегезгә беренчесе кебек ук гади сорау. Сез үзегез бу эшкә барыр идегезме? Икенчедән, Сара абыстай асрау кыздан соң, ягъни 90 яше өстенә янә күпмедер яшь өстәлгәннән соң бала табу сәләтенә ирешә ич. Дөрес, ул кадәресе пәйгамбәр алладан сорагач була. Ә нигә көн саен, без үзебезнең начальникларыбыз белән очрашкан кебек, алла белән очрашып-сөйләшеп торган Ибраһимга Сарасына бала табу сәләтен Һаҗәр белән йоклап чыкканчы сорарга ярамаган?

Ө ч е н ч е т ө р к е м х а т л а р. «Дин юк бит инде», «Нигә кирәк бу китап?..».

Мондый хатлар өлкән сыйныф укучылардан, яшүсмерләрдән килә. Комсомолецлардан, хәтта коммунистлардан.

Нижний Тагильдән язган «рабочий класс» имзалы хат белән Мамадыш районы Түбән Тәкәнеш авылы кешесе Шәйдуллин хаты шундыйлардан. «Бездә мәчет-чиркәүләр турында (дин турында — Г. Г.) уйлаган кеше дә юк. Казан үзе муллалар укытып чыгара. Бу китапны шуларга бирегез».

Казан шәһәре Журналистлар урамы 11—34 нче йортта торучы Хәсәнова, Закиров, Касыймов, Шакиров, Шәрифуллин (а), бөтенесе унбер кеше кул куйган хатта шундый юллар бар: «Без к о м м у н и з м т ө з ү ч е л ә р. Без Коръәнне укый белмибез, укыганны ишеткәнебез дә юк... «Казан утлары» «Коръән повесте»на юл куйса, гомере кыска булыр... Безгә тормышка өндәүче матур әдәбият кирәк...»

Менә нәрсә, иптәшләр. Сез аны үзегез дә беләсездер, һәркемгә яраган әйбер табигатьтә юк. Иртән әз генә яңгыр сибәләп китте ди. Шәһәр өчен шул җитте. Пляжда анысының да кирәге юк. Ә авыл өчен? Сезнең Журналистлар урамы буйлап, җир селкетеп, тәрәзә пыялаларыгызны зыңгылдатып трамвай уза. Якын тирәдә эшләүче Гали өчен ул бер афәт кенә. Ә Вахитов заводында, яки меховойда эшләүче Вәли өчен ансыз мөмкин түгел. Ә бит икесе дә к о м м у н и з м т ө з ү ч е л ә р. Әдәби әсәрдә бигрәк тә шулай. Сезгә, әйтүегезгә караганда, дин турындагы әдәбиятның кирәге юк, ул хәтта сезне ярсыта. Ә икенче берәүләргә ул матур әдәбияттан болай кирәк. Коммунизм төзүчеләр, коммунизм өчен фидакарь хезмәт итүчеләр моны аңларга тиеш иделәр. Аннан дин коммунизм төзергә ифрат дәрәҗәдә комачаулый бит. Коммунизм төзүчеләр моны да белергә тиешләрдер дип уйлыйм.

Журнал битендә җыелышлардагы кебек кара-каршы утырып сөйләшеп булса, сез бәлкем хәзер, «дин тотучы бетте» дигәнегезне төзәтеп, «бетмәсә дә әз калды», алар өчен генә кагазь пычратып тору урынсыз дияр идегез. Ул чакта мин сезгә шундый бер мәгълүмат китерергә тиешмен.

1965 нче елда күп кенә авылларда исем куштыру, сөннәткә утырту 40—50 процент булды, никах укыту 55—60 процент, дини йола белән күмү 90 процент.

Чаллы районы Түбән Ләҗә (?) авылында яшәүче Газизҗан исемле карт менә нәрсә яза.

«... Күп коммунистлар мәет булган ата-аналары рухына Коръән багышлаталар. Күбесе яшерен никах укыталар, мулладан азан әйттереп исем куйдыралар. Бәгъзе коммунистлар, бик нык чирләп, хәлен белергә баргач, хәлем аллага шөкер, шәһә-

дәт кәлимәсен укып ята идем әле, дип ычкындырып ташлый... Бу хатымны коммунистларның яшерен рәвештә дин саклауларына пошынып яздым».

Авылларда шул хәл, ә Казанның үзендә шундыйлар юкмы? Исемнәрен матбугатка күтәреп чыгып хур итәсем килми, мәүлет укытучы, авыз ачтыручы, дини йолаларның берсен калдырмый үтәп баручы, хәтта корбан чалучы коммунистлар, комсомолецлар да очрый әле Казанда. Коммунизм төзүче унбер иптәшне, һич югында аларның коммунистларын, бу хәл бераз борчырга тиеш түгел микән?

Аннан соң «Казан утлары»на карата дәгъвагыз принципиаль дөрес түгел. «Казан утлары» әдәби журнал гына түгел бит, титул битеннән күренгәнчә, әдәби-иҗтимагый-политик журнал. Димәк, «журнал «Коръән серләре»нә юл куйса, гомере кыска булыр» дип өркетүегез бөтенләй урынсыз.

Озын сүзнең кыскасы, Корәъннең чын йөзен фаш итә торган әсәрләр Нәмәгълүм агай яки Фәрхенур ханым кебекләр өчен генә түгел, күрәсең, бик күпләр өчен кирәк әле. Аларның кирәклеге, мин әйтер идем — зарурлыгы безнең гасыр азагында бетсә, бу ленинчыл атеизмның зур уңышы булыр иде.

Бу юлда эшләү хәтта сезнең, коммунизм төзүче унбер иптәшнең дә уртак бурычлары түгел микән? Ленин бабай менә нәрсә ди бит:

«Партия наша есть союз сознательных, передовых борцов за освобождение рабочего класса. Такой союз не может и не должен безразлично относиться к бессознательности, темноте или мракобесничеству в виде религиозных верований... Мы обосновали свой союз (РСДРП) именно для такой борьбы против всякого религиозного одурачивания рабочих».

*(10 том, 67—68 битләр.)*

Мин бу китапны язарга керешкәндә аның Нәмәгълүм агайлардан алып унбер иптәш кебек Корәънне беләселәре дә килмәгәннәргә дә кирәк икәнен аңлап керештем. Шулай ук балаларга, әби-бабасы итәгендә дини тәрбия белән агуланып үскәннәренә генә түгел, бөтенесенә дә кирәк икәнен исәпкә алып керештем.

Комсомол Үзәк Комитетының беренче секретаре С. П. Павлов Ленин комсомолының XIV съездында болай дигән иде:

«Мәктәп баласы дин турында бернәрсә дә белми икән, аны бөтенләй динсез дип уйлыйлар, күрәсең. Шулай булмаганда, хәтта табигать фәннәренең программаларында, уку китапларында атеистик положениеләр, нәтиҗәләр булмауны ничек аңларга? Педагогик Фәннәр академиясенең укытучылар өчен чыгара торган пособиеләрендә дә мәктәп баласын фәнни атеизм рухында тәрбияләү мәсьәләсе куелмаган. Мондый «динсез укыту» позициясе белән килешеп булмый».

Аннан «Коръән серләре»н язудан максат — динчеләргә хак сүз җиткерү генә түгел бит. Бу китап зур бер милләтнең — гарәп халкының борынгы тарихы, аның иҗтимагый тормышы, көнкүреше, уйлары, хисләре, диннәрнең ничек барлыкка килүе, аларның халык аңына ничек йогынты ясавы, колларны, ярлы-ябагайларны изү өчен сыйныфлар кулында ничек корал булуы турындагы документаль публицистик повесть. Мин ышанам, аның танып белү ягыннан әһәмияте диннәр беткәч тә калачак. Инде кем дә булса, синең ул танып белүең нигә кирәк мина дия икән, әйттем исә кайттым, Фонвизин Митрофанушкасына математика белән география дә кирәк булмаган.

5

Инде укучы хатларындагы аерым замечаниеләргә карата.

1. «Коръән серләре» «Казан утлары»нда басыла башлаганчы ук мине һәм редакция эшчеләрен сәяси сукырлыкта гаепләүче иптәшләр булды. «Анда гарәп К о р ъ ә н т о т ы п с о ц и а л и з м т ө з и, сез монда шул Корәъннең яман атын сатарга җыенасыз...»

«Коръән тотып социализм...»

Иптәшләр гафу итсен, гарәп дөньясында хәл бүген бүтәнчәрәк бит. Башта шуны әйтеп үтим, К о р ъ ә н т о т ы п с о ц и а л и з м т ө з ү мөмкин түгел. Мин моны китабымда Коръән аятьләре, хәдисләр нигезендә исбат иткән идем инде. Коръән, хәдисләр баштанаяк мәдәният, тәрәккъыят дошманнары, алар гарәпнең алга омтылган таза-сау акыллы улларын гасырлар буена чабуларыннан тотып тордылар. Инде тәмам буыла башлагач кына Коръән, хәдисләрне бер якка куеп, ачыграк итеп әйткәндә, Коръән кануннарына, Мөхәммәт боерыкларына каршы барып, ханнарны, солтаннарны бәреп төшерделәр дә, Җир йөзендә беренче социалистик илдән үрнәк алып, социалистик юлга бастылар.

Моның аеруча ачык мисалы — Берләшкән гарәп иле. Һәм биредә Коръән үзенең чын йөзен тагын бер мәртәбә күрсәтте. Реакцион кара көчләр Корәънне эшкә куштылар. Үзләренең әләмнәренә Коръән аятьләрен, хәдисләрне шигар итеп, революциягә каршы күтәрелделәр. Радиостанцияләрне яндыру, яңа төзелешләргә шартлаткычлар салу, хезмәт ияләре күп яши торган кварталларга яндыргыч бомбалар ташлау, Гамәл Габделнасирга һөҗүм... Һәм болар бөтенесе ниндидер стихияле чыгышлар түгел, зур реакцион оешма тарафыннан әзерләнде. Бу оешманың исеме «Мөселман туганнар». Гамәл Габделнасир аны бик тапкыр рәвештә «Кан эчкеч туганнар» дип атады.

«Кан эчкеч туганнар» Бөек Ватан сугышы елларында Гитлерга гелән матди һәм мораль ярдәм итеп тордылар. Аны хәтта Мәһди дип игълан иттеләр. Тиздән безгә дә килеп житәчәк, Коръән кануннарын, пәйгамбәр боерыкларын бозучыларны кылычтан үткәреп, илдә тигезлек, гаделлек урнаштырачак, диделәр.

«Мәһди» дөмекте. «Советская Татария»нең 23 нче август санын карагыз, «мөселман туганнар» да дөмекте. Ә берләшкән гарәп илләре алга баруын искиткеч тизлек белән дәвам итә.

Бу мәсьәләдә Ямән иле шулай ук характерлы. Мөхәммәтнең: «Ханнарны саклап торыгыз», «Ханнар алланың жирдәге күләгәләре», «Дөньяга күңел куйсагыз, ахирәтегезгә зарар итәрсез» дигәннәре белән исәпләшеп тормаган халык нибары бернично дистә ел эчендә тәрәккыяттә 14 нче гасырдан 20 нче гасырга сикерде. Әлбәттә, анда да шул ук «мөселман туганнар», аятьләр, хәдисләр, террор, төрле юллар белән тәгәрмәчкә таяк тыгу... Ләкин аларны да шул ук язмыш көтә.

2. Диничеләрнең иманнарына бер дә кырау тимәгәннәрен әйткән дә юк, табигать законнары, фән белән азмы-күпме танышлары да Коръәндә унай яклар булмауга ышанмый. Шактый укымышлы коммунистлар арасында да андыйлар юк түгел. Бәгъзе берәүләр турыдан-туры киңәш бирә: аларын да язарга иде, гадел булмый бит...

Менә Мәскәүдән Мөхәммәтжанов хаты. Укымышлы, мәдәниятле кеше булса кирәк. Дин белән дә алыш-биреше юк кебек. Ул киңәш биреп кенә калмый, менә нәрсә ди ул:

«Язучының нияте Коръән серләрен ачу түгел, Коръәнне һәм Мөхәммәтне пычракка буяп, бик начар итеп күрсәтү. Ничек инде, Коръән һәм Мөхәммәт гел начар да начар булсын!..»

Бу хат мине 1928 елга алып кайтты. Алафуз (хәзерге льнокомбинат) фабрикасының эшчеләр Сарае. Мисырның үзендә муллалыкка укып кайтып, революция елларында революцион эшкә кереп киткән Минһаж Кунев «Мөхәммәт пәйгамбәрнең төп теләге» турында лекция укый... Бирә кирәген!.. Лекция азагында зал яртыга калды. Мин үзем дә комсомолец булуыма карамастан, әллә кайчан чыгып тайган була идем, Минһаж аганың каенесе белән килгәнгә күрә генә түзеп утырдым.

Иптәш Мөхәммәтжанов кебек оста итеп әйтә алмаганмын, ләкин Минһаж ага турында уем нәкъ иптәш Мөхәммәтжановның миңа карата әйткәне кебек иде.

Ник? Юк инде, миннән дин сөреме чыгып бетә язган, тик шулай да Коръәнне һәм Мөхәммәтне чынбарлыктагыча, Минһаж ага сөйләгәнчә үк дип белми идем әле.

Минемчә, сез дә шуңа күрә генә миңа нәгърә орасыз.

Коръәнне аклау, мине фальшьта гаепләү өчен сез 4 хатын мәсьәләсен кузгатасыз. Уйлап карасаң, бергә генә өйләнергә кушкан бит, дисез... Әйе, тигез шартлар тудыра алмасаң, бер белән генә тор, ди Коръән. Ә кем тигез шартлар тудыра алмый? Кол, фәкыйрь. Ә барлы-көрле? Черегән байлар?.. Шулар өстенә Коръән, йортында никә кол хатын-кыз бар, бөтенесе белән йокларга ярый ди бит әле.

Шуның өстенә тагын никахе мөтга (вакытлы никах), дигәне бар. Бүген никах укытып куенына керәсең, иртән торгач «талак, талак, талак!..» И эшең бетте кодагый!

Мин әле китабымда никахе мөтга турында әйтеп бетермәгәнмен икән. Дөресрәге, кайберсен үзем дә белмәгәнмен. Миңа берничә укучы бу төр фахешлекнең хаж җирләрендә никадәр киң таралганын яздылар. Яучылар хаҗилар арасында, ат базарындагы маклерлар кебек, тыз да быз йөреп торалар.

— ... Ниндиеннән боерасыз, тәкъсир... Янчыгыгыз тартса кыз — кыз да юнәтергә мөмкин... Ә никахны, алла теләсә, үзем чатнатып укып бирәм... Мине онытмасагез, әнә фәлән мәхәллә мулласына әйтербез...

Мин бу хатларга ышанмыйча, Казан хаҗиларын эзләп табып сораштым. Хосусән, 1950 елларда СССРдан хаҗиларга медицина ярдәме күрсәтү тәртибендә барган өлкән врач Мөхәммәт ага Кәримов, тагын элекке мөдәррис Хатип ага Булатов хатларның дөреслекләрен тасдыйк иттеләр.

Мөхәммәтне аклау, хәтта мактау максаты белән сез, иптәш Мөхәммәтжанов: «Мөхәммәт кабиләләргә аерылган, вәхшилеккә баткан гарәпләрне оештырып һәм башка яхшылыклар эшләп, бөтен дөньяда дан казанды» дип язасыз. «Башка яхшылыклар» дигәнегез нәрсәдер, калганы тулысы белән шул ук дини китаплардан.

Бу китаплар элекке хак пәйгамбәрләр белән Мөхәммәт арасындагы дәверне жаһилият (караңгылык, наданлык) заманы дип атыйлар. Имеш, пәйгамбәрләр заманында ал да гөл булган да, пәйгамбәрләр килми торган арада гарәп, сез әйткәнчә, вәхшилеккә баткан.

Беренчедән, батмаган. Гарәп, «Коръән серләре»ндә китерелгән сәбәпләр аркасында үсүдән, алга китүдән туктап торган. Һәм Мөхәммәт аны әз генә дә кузгатып җибәрә алмаган. Биредә кабатлау булса да әйтергә кирәк, киресенчә, ислам дине гарәпнең (бер гарәпнең генә дә түгел, ислам динен кабул иткән һәр милләтнең) прогрессына, культурасына аяк чалды. Коръән шигырьне, гарәпнең өзелеп сөйгән нәфис сәнгатен сихер эше дип хурлады. Кеш*нең үзе белән барлыкка килгән, бергә чәчәк аткан музыка, рәсем, сынлы сәнгать тыелды. Мөхәммәтнең туган ягы булган Сагут

Гарәбстанында бүген дә әле бер скульптура, бер рәсем, хәтта хайван рәсеме эзләп таба алмассын. Кино-театрлар турында әйткән дә юк.

Инде авызны бер ачкан икәнбез, гарәпнең Мөхәммәт дөньяга килгән заманындагы «вәхшилеге» турында да берничә сүз әйтеп үтик. Йолдызлар, кояш, ай турында әзме-күпме белем хасыйл иткән, үсемлекләрне ясалма серкәләндерү серен ачкан төрле мәгъдәннәр, алтын-көмеш эшкәртә белгән, тимер төрәнле сабаны булган, ювелир товарлары белән Иран, Византия, Хәбәш илләрендә дан тоткан, Кызыл диңгездән Һиндстан ярларына кадәр җилкәнле кораблар йөртә белгән гарәпне, бай теле, сокланырлык шагыйрьләре булган гарәпне вәхши дип әйтү — бу бүгенге гарәпнең ерак бабаларын артык хурлау булмас микән?

Инде Мөхәммәтнең гарәпләрне берләштерүе турында. Әйе. Ләкин бу берләшү коллар, ярлылар, хәтта барлы-көрлеләр хыял иткән бөлгенлектән котылуны алып килми генә түгел, халыкне тагын да авырайта төшә. Кабиләләр арасындагы бәрелешләр урынын мәзһәпләр, аерым гарәп илләре арасындагы яман зур сугышлар ала. Инде гарәп каны чиләкләп түгел, елга булып ага башлый. Һәм аның хәзергә кадәр тукталып беткәне юк.

Бу мәсьәләгә китабымда мин җитәрлек урын бирдем. Яки Сез андый урыннарны сикереп үткән. Яки, әлеге дә баягы, Сез мин кайчандыр Минһаҗ Куневкә ышанмаган кебек, миңа ышанып бетмәгәнсез. Мин, әлбәттә, сезне шөбһәләнгәнегез, дөресрәге, ышанмаганыгыз өчен ачуланмыйм, гаҗәпләнмим дә, хәтта табигый күрәм.

Чыннан да, безнең иң түбән сыйфатлы дигән әсәрләребездә дә тычкан үты кадәр генә булса да яктылык җемелди бит. Ә Мөхәммәт, ничек кенә әйтмә, гади кеше түгел... Әлепне таяк дип белмәгәне хәлдә әнә нинди эшләр башкарган, кайбер урыннары хәтта бөек Пушкинны сокландырырлык шундый шигъри әсәрләр иҗат иткән. Ничек бөтен эшләре, идеясе тискәре булсын дияргә нигез бар кебек.

Инде серне ачсаң да ярый торгандыр. Мин эшкә керешкәндә үзем дә шулайрак дип уйладым. Һәм әдәби тәнкыйтьчеләребез үрнәгендә, төгәл гаделлек белән башта уңай якларын күрсәтергә, аннан соң гына тискәреләренә тукталырга исәп иттем.

Ләкин, бөтен җаваплылыкны өстемә алып әйтәм, телгә алып сөйләрлек, «Коръән серләре»ндә фаш ителгән кара тапларны юарлык димим, әз генә булса да сыегайтырлык, ахыргача тезмәле рәвештә уңай диярлек бер җирен тапмадым. Андый юк Коръәндә. Бер дәме, диярсез. «Бер дә» әнә булсын да ди. Ләкин, әгәр, алла булып, Коръән аның сүзе икән, ул «бер дә» түгел, баштанаяк уңай булырга тиеш иде. Үзенең, шулай ук пәйгамбәренең һәр адымы, һәр хәрәкәте безгә үрнәк булырлык булырга тиеш иде. Бу нәтиҗә белән кем генә килешмәс икән.

Ә шулай да ул «бер дә» бармы соң?

Мин китабымның азагында бу мәсьәләгә шактый кин тукталып, урлау гөнаһ, үтерү гөнаһ, зина гөнаһ, эчкечелек гөнаһ, дигән аятьләрнең икенче аять яки хәдисләр белән ничек юкка чыгарылуларын дәлилле күрсәттем шикелле.

Дөрес, мин Коръәннең (Мөхәммәтнең) бердәнбер уңай ягын — ул да булса, әле гарәпләрдә бетеп җитмәгән, беренче корсактан туган кыз баланы терелэй җиргә күмү йоласын туктатырга өндәгәнен әйттем. Ләкин мин бу аятьнең бер читтә посып яткан күңелсез бер искәрмәсен аңлы рәвештә эчтән тындым. Менә ул искәрмә:

«...Әгәр алла теләсә, алар моны эшләмәс иделәр (ягъни балаларын терелэй җиргә күммәсләр иде.— Г. Г.). Калдыр син аларны, ниятләгәннәрен эшли бирсеннәр...»

*(Коръән, «Әнгам» — «Хайван» сурәсе, 138 аять.)*

Әгәр инде Коръәннең икенче бер җирендә кысылып яткан тезмәле рәвештә практик уңай ягын төртеп күрсәтүче була икән... Ләкин, валлаһе әгъләм... Үз сүзләре белән әйтсәк, «...иске мәдрәсәнең һавасын берничә еллар сулаган, Коръәнне тәфсыйллап (тәфсирләп (?) чыккан Фатих ага Сабиров (ул хәзер Донецк өлкәсе Харцыск шәһәре Ждановка поселогында 26/34 квартал, 16 нчы йорт, 30 нчы квартирада тора) «Казан утлары»на менә нәрсә яза:

«Әсәр шулкадәр тырышлык һәм гаделлек белән язылган ки, бер генә җирендә дә шөбһәгә урын калмаган.»

Хәзергә бу хакта сүзне Ленин фикере белән тәмамлап торыйк.

«Он (Ленин) доказал, что религиозная идеология никогда в истории общества не играла прогрессивной роли, и всегда оправдывала социальный гнет, эксплуатацию, невежество и нищету». («Атеистический словарь», 48 стр.)

3. Казанның Ягодный бистәсендә торучы (урамы, йорт номеры юк) Хәйруллин иптәш мине ялганчылыкта гаепләп килә-килә дә шундый сорау бирә:

«Сез Әбүсуфьянны пәйгамбәр белән кардәшләшү, данга кызыгу, малга хирес булу сәбәпле генә ислам диненә кергән итеп күрсәтәсез. Әбүбәкер, каенатасы була торып, Мөхәммәтне, аллаһ тәгаләнең пәйгамбәрен, «йөгәнсез дөя» дип хурлый булган дисез. Бу уйдырмагызны нәрсәгә нигезләмәк буласыз?»

Уйдырма түгел, факт. Нигезләвем — тарихка, бигрәк тә Коръәннең үзенә, иптәш Хәйруллин.

Мөхәммәт үзе исән чакта мондый дөнья күргән кешеләрдә, эшлекле кешеләрдә генә түгел, гомумән гарәптә иман ягы керәле дә чыгалы була. Гарәпне, бигрәк тә бә-

дәви гарәпләрне, ислам диненә иманнан бигрәк ганимәт мал тартып кертә. Моның бәхәссез дәлиле Коръәннең үзендә:

«Бәдәвиләр әйтә: «Без иман китердек инде диләр». Әйт: «сез иман китермәдегез, диген, иман әле сезнең йөрәкләрегезгә үтеп кермәгән», диген.

Тагын:

«Әй рәсүл! Алар «иман китердек» дип авызлары белән генә әйттеләр, йөрәкләре иман китермәде...»

*(Коръән, «Хаҗарати» сүрәсе, 14 нче аять; «Маидә» сүрәсе, 14 нче аять.)*

Алла (чыны Мөхәммәт) андый мөселманнарны икейөзлеләр дип атый һәм шундый хөкем чыгара:

«Тирә-юнегездәге бәдәвиләр белән Мәдинә кешеләре арасында икейөзлеләр бар. Аларда икейөзлелек көчле. Син аларны белмисең, без беләбез. Без аларны ике тапкыр (дөньяда вә ахирәттә — Г. Г.) җәзалаячакбыз...»

*(Коръән, «Тәүбә» сүрәсе, 98, 102 аятьләр.)*

Тарихка шундый вакыйга билгеле. Ни сәбәптәндер Византиягә каршы походтан азат ителгән кайбер мөселманнар, шатланышып, урамда җырлап йөриләр һәм поход чыгучыларга, бу кызуда интегеп йөрмәскә киңәш итәләр. Мөхәммәт аларга алла исеменнән: «Җәһәннәм тагын да кызурак!..» дип кычкыра. Ә поход чыгучыларга: «Алардан йөз чөерегез, кабахәтләр бит алар, үлсәләр дога кылмагыз, аларның урыннары җәһәннәм!» ди.

*(«Тәүбә» сүрәсе, 82—85, 96 аятьләр.)*

Бәдәвиләр генә түгел, исламның иң беренче карлыгачлары булган Мәккә мөселманнарының да кайберләрендә иман дигәнебез кәрәле дә чыгалы була. Алар алла өй түбәләрен алтын-көмеш белән ябып бирергә вәгъдә иткәндә генә иман китерәләр дә, һиҗрәт мәсьәләсе кузгалгач, «мә тәһәрәтеңне, китер кәвешемне...» Өндәп-өндәп өметен өзгәч, Мөхәммәт аларга болай ди:

«Кыямәт көн бу кешеләргә фәрештәләр, алланың җире зур иде бит, нигә күчмәдегез, диячәкләр?.. Хатын-кыз, карт-коры, бала-чагалардан гайриләренең урыннары җәһәннәмдә булачак...»

Алай гына да түгел...

Аларга «җәзаның иң катысы булачак».

*(Коръән, «Ниса» («Хатын-кыз») сүрәсе, 99—100, «Нәхл» («Бал кортлары») сүрәсе, 108 аятьләр.)*

Гарәптә дин Мөхәммәт вафат булгач, аның чын йөзен белгән, маҗараларын үз күзләре белән күргән кешеләр үлеп беткәч, аның турында буыннан-буынга күчеп сөйләнеп йөргән хак сүзләр онытылгач, ә руханилар, дини язучылар тырышып-тырышып, берсен-берсе уздырып, аның «актан ак, сөттән дә аграк» булуына халыкларны тәмам ышандырып житкергәч, янә килеп, төбен тикшерергә ярамаганны әйтеп, кара халыкның котын алып бетергәч кенә көчәя. Көчәя, ләкин бу — ул чакта инде һәркем ышанган икән дигән сүз түгел. Мона Гомәр Хәйям, Насыйр Хөсрәү, Әбугалисиналарның минем китапны бизәп торган шигырьләре, һәм мин телгә алмаган бик күп шигъри әсәрләр, философларның ачынып язганнары шаһит.

4. Лут, Ибраһим, Муса кебек пәйгамбәрләр чыннан да шундый сәер кеше булганнармы, әллә кызык өчен үзегез уйлап чыгардыгызмы? Бу сорауны Мәрзия Фәйзуллина (шагыйрә Фәйзуллина түгел, башка бер ханым) бирә.

Маҗаралары гына түгел, бу пәйгамбәрләр үзләре дә уйлап чыгарылган. Ә уйлап чыгаручылары, һәм үзләрен, һәм сәер маҗараларын уйлап чыгаручылары, мин түгел, Мөхәммәт һәм аңа кадәр яшәгән Тәүрат белән Инҗил авторлары: Марк, Иоанн, Матфей, Лука һ. б. бик күп руханилар. Мин китабымда аларның сәер эшләре турында бөтенесен әйтеп бетермәдем. Бәлкем кайберләрен кирәк тә булгандыр. Мәсәлән, Муса, Коръән хәбәр итүенчә, беләмсез, кайчан иман китерә? 40—50 еллап пәйгамбәр булып йөргәч, Тур тавында алланың йөзен күреп һушсыз булып егылгач.

«Дан сиңа! — ди Муса аллага шул чак.— Менә инде ышандым. Мин сиңа беренче булып иман китердем».

*(Коръән, «Әгъраф» сүрәсе, 139—140 нчы аятьләр.)*

Ә Ибраһим пәйгамбәр, беләсезме кайчан иманлы булырга теләп, аллага мөрәҗәгать итә? Асравы һәм, аңардан көнләшеп, Сара әби бала табып биргәч. Менә Ибраһимның үз сүзләре:

«Карт көнемдә миңа Исмәгыйль белән Исхакны бүләк иткән аллага дан!.. Әй алла, мине һәм токымымны үзеңә гыйбадәт кылучы ит».

*(Коръән, «Ибраһим» сүрәсе, 42 нче аять.)*

Ибраһим үзе дини әкиятләрдә бик күптәннән килә. Бу мифик геройның карьерасы Ассирий илендәге бер кабилә алласы булып йөрүдән башланып китә. Ачыграк итеп әйткәндә, бу кабилә үзе хыял иткән аллага шундый исем куша. Анда әле аның исеме Аби-раму була. «Әтием озын буйлы» дигән сүз. Тәуратка Авраам булып керә, Коръәнгә — Ибраһим.

Коръәнгә килеп кергәч, бу бичарага невезет арты невезет. Алда әйткәнемчә, әнә кайчан гына аллага гыйбадәт кылучы булырга теләп дога кыла. Ә соңга таба Мөхәммәт аны пәйгамбәр дә дими, хәниф иде ул ди.

*(Коръән, «Гыймран» сүрәсе, 60, 68 аятьләр.)*

Ә хәнифләр беләсезме кемнәр? Мөхәммәтнен үз сүзләре белән әйткәндә, ялганчы пәйгамбәрләр, дин дошманнары... Башта кабилә алласы булып йөргән Ибраһим баратора Коръәндә әнә кем булып кала!..

Сөйли китсәң, пәйгамбәрләр тормышында андый кызыклар бихисап күп. Юныс дигән берсе, сезгә ялган, менә чын, арада иң гөнаһлы кеше була. Бер заман дингез ярып бара торган кораб туктый. Тегеләй итеп карыйлар, болай итеп карыйлар. Юк, каккан казыкмыни!.. Корабтагылар төшенеп ала: арабызда бик зур гөнаһлы кеше булырга тиеш... Кем икән?.. Тикшерә-сораша торгач, беләләр. Иң гөнаһлы бәндә — Юныс пәйгамбәр икән!.. И бултых үзен дингезгә... Шунда гына кораб үзенең юлын дәвам итә. Ә пәйгамбәрне, бичара бәни Исраил пәйгамбәрсез калды дип куркышып торганда, ярый әле балык коткара. Кабып йота да, ярга чыгарып ташлый.

*(Коръән, «Калам» 48—49; «Саффат» 139—148; «Әнбия», 87—88 аятьләр.)*

5. «Кайсы дин әйбәтрәк?» «Комсомолец» имзалы егет бу сорауны ислам диненнән чыгып, «әйбәтрәк» дингә керү теләге белән бирми, әлбәттә. Минемчә, аның диннәр белән бертөрле дә алыш-биреше юк, просто беләсе килә. Мондый сорау кайчандыр минем үземнең дә башымда йөри иде. Кызыксынучылар (әлбәттә, динсезләр арасында), тагын булуы мөмкин. Кыскача җавап мондый. Һәр диндә кеше үз динен әйбәт күрә. Ә читтән торып объектив күз белән караганда берсен яманлап, берсен мактый торган түгел. Формалары гына төрле-төрле. Христиан гыйбадәт вакытында ялан баш, побының башында тәреле кара катташи. Ислам әһеленең башында чалма, яки мескен бүрек, кәләпүш, өстендә җилән, ак ыштан, читек-кәвеш [1]. Гыйбадәтләрнең дә формалары гына башка. Мөселман әпәр итә, христиан чебенли, яһүд җиргә тезләнеп күзләрен күккә тери; бахраман һәм будда динен тотучы кул йөзләрен бер-берсенә каплап, каш турысына күтәрә. Ә догалары бер үк, яки бер-берсенә бик якын. Мисал өчен христианның «Отче наш» дигән догалары белән мөселманның «Әлхәм» сүрәсен чагыштырып карагыз.

Шәфкатьле мәрхәмәтле аллага, Галәм алласына, кыямәт көннең хуҗасына дан! Сиңа табынабыз, синнән ярдәм көтәбез. Безне адашканнар юлыннан түгел, ачуыңа дучар булучылар юлыннан түгел, рәхмәтең төшкән кешеләрең юлыннан алып бар.

Күктә яшәүче изге хуҗабызга дан! Җир һәм күкләр бер синең хөкемеңдә. Я алла, безне һәр көн ризыкландыр. Безнең гөнаһларыбызны ярлыка... Безне вәсвәсәле юлга кертмә, шайтан шәреннән (коткысыннан) коткар. Син безнең мәңге патшабыз, синең кодрәтең мәңге. Амин.

Яһүдләрнең дә шуларга якын.

Ә идеяләре? Идеяләре бөтенесенең бер. Ярлы-ябага өстен сыйныфларга буйсынып, шуларга кол булып торырга тиеш. Кол һәрвакыт кол булып калырга тиеш. Кол кеше эш башына үрмәли башласа, тотып алып бугазларга кирәк.

Кыскасы, бу өч дин сәясәтендә, аларның идеяләрендә һичбер төрле аерма юк. Менә шуңа күрә дә Мәдинәгә күчеп килеп, яһүд һәм христиан диннәре белән якыннан танышканнан соң, Мөхәммәт үзе дә шул нәтиҗәгә килә. Онытткан булсагыз, исегезгә төшерим. Мөхәммәт менә нәрсә ди:

«...Без аллага, безгә җибәрелгән Коръәнгә, Муса белән Гайсәгә җибәрелгән китапларга (Тәурат белән Инҗилгә — Г. Г.) ышанабыз... Без алар арасында аерма күрмибез...»

*(Коръән, «Бәкарә» сүрәсе, 130 аять.)*

Менә тагын:

«...Кяферләр өчен борчылма... чынлыкта алла белән кыямәт көнгә ышанып, яхшы гамәл кылучы яһүдләргә дә, христианнарга да куркырга кирәк түгел. Аларга (теге дөньяда) кайгырырга туры килмәс.»

*(Коръән, «Маидә» сүрәсе, 72—73 аятьләр.)*

---

[1] Асылда бу киемнәрнең дингә һичбер мөнәсәбәте юк. Мәсәлән, христиан динендәге гарәпнең башында шул ук чалма, өстендә җилән, чиркәүгә дә шулай йөри, чалма очы белән сөртеп тәре үбә, чукына... Чалма-чапан гарәпнең дини киеме түгел, милли киеме.

Ягъни алар да шул син кергән җәннәткә керер.

Ә мәҗүси диннәр ничек?

Алар бер аллалы диннәр кебек катлаулы булмаулары белән генә аерылып торалар. Аларда тагын кыргыйлык көчлерәк. Анын каравы, аларда коллык богаулары ислам, яһүд, христиан диннәрендәге кебек авыр түгел, яисә бөтенләй юк. Чөнки әле аларда сыйныфлар юк, яисә туып кына килә.

Ә догалары?

Мәсәлән, Иранда ислам дине көчләп тагылганчы мең еллар буенча яшәп килгән (калдыклары Һиндстанда хәзер дә бар) зороастр диненең тәүбә догасы менә нинди.

«Әй аллам! Мин бөтен гөнаһларымнан тәүбә итәмен. Һәртөрле бозык уйларымнан, әшәке сүзләр сөйләүдән, начар гамәлләрдән тәүбә итәм. Ниятләгән, үтәргә җыенган, яки үти башлаган бозык эшләремнән тәүбә итәм. Телемдә, уемда, гамәлемдә булган бөтен гөнаһларымны ярлыка, әй аллам!.. Дөнья вә ахирәт җаным белән тәнемне җәза кыла күрмә, әй аллам!..»

Исламның тәүбә догаларыннан, христианның покаяниесеннән кай җире ким?

6. Хат авторларының, бер берсе белән аваздаш фикерләреннән тыш, һәркайсының аерым сораулары бар. Мин аларның хатларында адреслары күрсәтелгәннәренә хат аша җавап бирдем. Ә күрсәтелмәгәннәре миннән булмаган сәбәпләр аркасында җавапсыз калды. Тегe яки бу укучының сорар сүзе булса, адресын, исемен, белемен, профессиясен күрсәтеп язсын иде. Язучы өчен бу бик әһәмиятле. Мин аларның гомуми әһәмиятләре булырдайларына шулай ук матбугат аша яки хат белән җавап бирергә тырышырмын.

Бу мөрәҗәгать китапны яратмаучы иптәшләргә дә бер үк дәрәҗәдә карый. Рәхәтләнеп сүгенегез, ләкин кем икәнегезне әйтегез. Аннан буш сүз яки ялган язып вакытыгызны әрәм итмәгез. Мәсәлән, Аксубайдан килгән хатта шуларның һәр икесе бар.

1. Бу хат азагындагы имзаларның унбере дә бер кешенеке икәнен сукыр да күрерлек. Почерк бер кешенеке. Аннан ул унбер кешенең алтысы татар авылыннан (Яна үзе, Иске үзе, Яна Ибрай, Иске Ибрай, Кәкре Атау, Киекледән), бишесе башкорт авылыннан (Габдрахман, Сарман, Ильяс... авылларыннан) җыелып язулары мөмкин дә, табигый да түгел. Хат авторы моның белән «Коръән серләре»н ачуга бөтен ил каршы дигән сүзне әйтергә теләгән.

2. Аныңча, «Коръән серләре» шулкадәр зарарлы китап, ул быелгы «язгы чәчүгә киртә» булды. «Казан утлары» бу китапны басудан туктатмаса, урып-җыю бөтенләй хәрап булачак!..»

3. Имеш, бу «унбер» кеше ярты гомерләрен еврейларда кол булып торган ике татар картын эзләп табып Коръәнне башыннан азагына кадәр укып күрсәткәннәр. Татар картлары бер генә дә еврей сүзе тапмаганнар.

4. Имеш, «Коръән серләре» басылган журналны авыл картлары һәм яшьләре йорттан йортка йөреп укыйлар, ләкин тыңлаучылар бернәрсә дә аңламыйлар...

Бу «унбер» кеше хатындагы һичбер сүзнең логикасы булмаганны тәфсыйллап торуның хаҗәте юк шикелле.

«Унбер» кешенең бер сүзе шулай да игътибарга лаеклы. Нигә дингә тиясез, ди ул. Бу сүзне әйтүчеләр бер «унбер» кеше генә түгел, шуңа күрә җавап биреп китүне кирәк таптым. Җавап бик кыска. Казанда Кабан күле буенда ике катлы мәчет бар. Манарасыннан мәәзин көн саен биш кәррә азан әйтә:

«Алла бөек, алла бөек, алла бөек, алла бөек. Гуаһлык бирәмен, бер алладан гайри алла юк; гуаһлык бирәмен, бер алладан гайри алла юк. Гуаһлык бирәмен, Мөхәммәт алланың илчесе, гуаһлык бирәмен, Мөхәммәт алланың илчесе. Ашыгыгыз намазга, ашыгыгыз намазга, ашыгыгыз газаптан котылуга, ашыгыгыз газаптан котылуга, намаз уку йокыдан яхшырак, намаз уку йокыдан яхшырак. Алла бөек, алла бөек, алладан гайри алла юк!»

Бу өндәмә көн саен манарадан биш мәртәбә яңгырый. Кергән керә, кермәгән бер гамьсез үтеп китә.

Минем «азан» да шулай. Мәәзин мәчеткә көчләп кертмәгән кебек, мин дә диннән бизәргә көчләмим, шулай ук китабымны көчләп такмыйм.

Күп кенә укучылар «Коръән серләре» китап булып чыгамы дип сорыйлар. Әйе. Әсәрнең берникадәр тулыландырылган, укучыларның киңәшләре нигезендә төзәтелгән варианты Татарстан китап нәшриятында 1967 елның январь аенда басылып чыгачак.

*Август, 1966 ел.*

—◆—

# Безнең календарь



## КАДЕРЛЕ ДУСТЫБЫЗ, ЯКЫН ИПТӘШЕБЕЗ ӘХМӘТ ЮНЫС!

*Татарстан язучылары союзы правлениесе һәм «Казан утлары» редакциясе Сезгә 50 яшь тулу белән Сезне кайнар котлый һәм үзенең иң яхшы теләкләрен белдерә.*

*Сез татар совет поэзиясенә зур тормыш мәктәбе аша килдегез. Без сезнең бик яшьләй авыл кырларында эшләвегезне, укытучы булуыгызны, ак финнарга каршы сугышта катнашуыгызны беләбез һәм моның өчен чын күңелдән ихтирам итәбез. Хезмәт һәм көрәш фронтыннан поэзиягә килүегез дә бик табигый хәл дибез. «Гүзәл яшьлек», «Әсән елга», «Без кайтырбыз», «Кырларга сәяхәт», «Булдырасың болай син генә», «Канатлана күңел» һәм башка бик күп шигырь һәм поэмаларыгыз, китапларыгыз поэзиягә Сезнең көрәш майданы итеп каравыгызны күрсәтеп тора. Халкыбызны, партиябезне, иҗади хезмәтне зурлап язган шигъри юлларыгыз күңелләргә ямь, шатлык өсти.*

*Иҗатыгызның әле иң кайнап торган чагы икәнен тоеп, Сезгә тагын да зуррак уңышлар, ныклы сәламәтлек, бетмәс-төкәнмәс сөенечләр телибез.*

*ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ПРАВЛЕНИЕСЕ,*
*„КАЗАН УТЛАРЫ“ РЕДАКЦИЯСЕ.*

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ БИТЛӘРЕНДӘ 1966 ЕЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

### ПАРТИЯ ЧАКЫРА

Бакиров Г. **Канатландыргыч карар.** Мәкалә. № 5.
Булгаков А. **Шулай булачак.** Мәкалә. № 5.
Галиев Г. **Быелгы яз.** № 5.
М. Әмир. **Алга карап.** № 6.

### ЛЕНИН ТУРЫНДА ШИГЫРЬЛӘР

Афзал Г. **Буранлы көн.** Шигырь. № 11.
Гамзатов Р. **Тау кешеләре Ленин янында.** Шигырь. № 11.
Гоппе Г. **Очрашу.** Шигырь. № 11.
Лахт У. **Ленин исемендәге канал.** Шигырь. № 11.
Сурков А. **Сүнмәс нурлар.** Шигырь. № 11.

### ПРОЗА ӘСӘРЛӘРЕ

Гази И. **Канатланыр чак.** Повесть. №№ 3, 4.
Гази И. **Тургай картаямы икән?** Хикәя. № 11.
Гаскәров М. **Чәчәкләр; Җир турында жыр; Күк-күк; Язгы су.** Парчалар. № 5.
Гобәй Г. **Корьән серләре.** Повесть. №№ 1 – 6.
Гыйләҗев А. **Берәү.** Повесть. №№ 5, 6.
Еники Ә. **Әйтелмәгән васыять.** Хикәя. № 1.
Маликова М. **Кыр ягы.** Хикәя. № 7.
Минский Г. **Яшенле яңгыр.** Повестьтан өзек. № 12.
Мөхәммәтшин Г. **Изге Галиәкбәр.** Хикәя. № 5.
Мөхәммәтшин Г. **Хәсәен абзый.** Хикәя. № 8.
Рафиков С. **Авыл иртәсе.** Романнан өзек. № 10.
Сабиров С. **Капитаннар.** Хикәя. № 12.
Салахов Н. **Колагир.** Хикәя. № 7.
Сарьян Х. **Әткәм һөнәре.** Повесть. №№ 8, 9.
Тажетдинов С. **Үлемнән яшәүгә.** Документаль повесть. №№ 10, 11, 12.
Тәхфәтуллин Р. **Алсу болытлар.** Хикәя. № 7.
Фәизов Р. **Әниемнең куллары.** Хикәя. № 8.
Хәсәнов А. **Гомер иткән нигез.** Хикәя. № 4.
Хәсәнов А. **Яшь наратлар.** Хикәя. № 9.
Әпсәләмов Г. **Поши баласы.** Хикәя. № 1.
Шолохов М. **Миңле командир.** Хикәя. № 7.

### ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Галимов. **План.** Скетч. № 6.
Гыйльми Н. **Интермедияләр.** № 10.
Кальметов С. **Кәләш күзләгәндә.** Бер пәрдәлек комедия. № 3.
Хөсәенов Ш. **Зөбәйдә — адәм баласы.** Трагикомедия. № 9.

## ШИГЫРЬЛӘР ҺӘМ ПОЭМАЛАР

Афзал Г. **Шагыйрь язмышы; Идел ага; Уй; Язмышлар; Бөтен дөнья күз алдында горур басып.** Шигырьләр. № 1.

Афзал Г. **Дан-дәрәҗә теләмим мин; Ышаныгыз; Шәрип урманы; Кояш нуры сеңеп безнең канга; Тәнкыйтьчегә; Авылда авырып яту.** Шигырьләр. № 8.

Баттал С. **Чирмешән якларында.** Шигъри роман. №№ 3, 4, 5.

Баянов Ә. **Мин — егерменче гасыр кешесе; Язмыш ишек кага; Күбәләкләр куып йөргән чагым; Яклыйсым килә; Ауга төшкән кош күк җилпенәсең; Кеше күңелендә; Унтугыз яшь; Сөйгәнемә гомер теләдем; Яңгыр, яу; Синең өчен; Сары күбәләгем; Ачуланма; Күңләдеңме, әллә болай гына; Күпме йөрерсең син; Тып-тын урам; Дөнья төсле.** Шигырьләр № 11.

Бикбай Б. **Күзләр.** Баллада. № 3.

Булатова К. **Дөньяларның бигрәк матур чагы. Язлар алда. Әңгер-меңгер җитеп килә. Мин төш күрдем бүген.** Шигырьләр. № 6.

Галиев Ш. **Яңа шигырьләр.** № 10.

Гатауллин Р. **Җилкән; Сезнең өчен бер кеше мин; Чакыру; Кайт кире; Алар ничә еллар буе инде; Назыйм Хикмәт турында мин уйлыйм бүген; Дулкынга син тездән атлап кергән идең; Кеше.** Шигырьләр. № 1.

Гатауллин Р. **Лирик сөйләшүләр.** Шигырьләр. № 9.

Гатауллин Рәшит, Шәйхулов З., Уткин Е. Шигырьләр. № 5.

Гәрәй Р. **Сәлам сезгә Себердән; Тайга эчендә; Сабан туен көткәндә; Ферма буйларында эзләр бар.** Шигырьләр. № 7.

Ерикәй Ә. **Лирик шигырьләр.** № 1.

Ерикәй Ә. **Лирика.** № 10.

Закиров Р. **Кары катлы-катлы. Көзге пейзаж. Кышкы иртә. Яратмасаң качмас идең. Урман шаулый. Чын дус. Ялгыз каен. Шунсыз булмас. Кышкы төн. Мин таптым да, югалттым да сине.** Шигырьләр. № 6.

Камалов Х. **Әнкәй истәлеге.** Шигырь. № 5.

Камалов Х. **Лирика.** № 12.

Латыйп Г. **Ташлар ни сөйлиләр; Пермь төрмәсендә; Көзге кояш; Капкалар; Синең җырың; Барыр юлың шома булсын диеп; Мин бер мескен татар идем диеп; Үстерә бакчаны Кәрим.** Шигырьләр. № 6.

Латыйп Г. **Исте җилләр; Әйтерсең, йолдыз атыла; Хатлар алдамыйлар; Россиянең ап-ак каеннары; Кыйгак-кыйгак кайта кыр казлары; Окоп казып әрәм итәләр дип; Җил-җил атлап кына бер кыз килә.** Шигырьләр. № 11.

Маликов Ә. **Яндырылган хатлар. Әйтелми калган сүзләр; Алда өр-яңа язлар;** Шигырьләр. № 7.

Мингалимов Р. **Шигырьләр.** № 8.

Насыйров Г. **Сүз. Больницада. Мәхәббәт. Игенче.** Шигырьләр. № 8.

Нури З. **Кечке күренешләр.** Шигырьләр. № 2.

Нури З. **Уйланулар һәм елмаюлар.** Шигырьләр. № 10.

Рәхим Г. **Шигырьләр.** № 8.

Садри М. **Сайлау таңында.** № 6.

Сирай Д. **Шигырьләр.** № 8.

Сөләйманова С. **Язылмаган җырлар.** Поэма. № 4.

Сөләйманов Б. **Мин соям. Син тугансың минем йөрәгемдә. О Кеше, әйтче, синме бу?! Син аңларсың минем йөрәгемне. Азат бер кошка җим, тозак салып. Бер күрүдә. Бокалдагы язу. Кыр казлары.** Шигырьләр. № 10.

Фәсәхов К. **Мин — пионер хәзер; Әтнә кызларына.** Шигырьләр. № 1.

Фәйзуллин Р. **Минем телем; Әгәр җирдә; Болын кебек бу маңгаем; Нигмә кулларың орынгач; Бераз үзгә, бераз бөтән; Сине күптән күргәнем юк; Күкне ниндерсп; Вулканнар бар диңгез төбендә; Өшеткеч бәс, кар сырышкан.** Шигырьләр. № 7.

Фәйзуллин Р. **Карт һәм шагыйрь.** Шигырь. № 12.

Хуҗиев Г. **Кайбыч урманнарын сагынып; Фәридә Кудашеваны тыңла-**

гач; Җитенкәй; Кошлар китә җылы якларга; Үз юлы бар һәрбер чишмәнең. Күзләр җитсә. Шигырьләр. № 2.
Хуҗиев Г. Таныш күзләр, таныш карашлар. Шигырь. № 9.
Хәким С. Ярлар, ярлар; Җырларымның артыннан мин очтым; Мин юл сорыйм; Декабристлар чиркәвенә бардым; Татар хатыны. Шигырьләр. № 11.
Хәлимов Б. Шигырьләр. № 9.
Хөсәен М. Автобиография. Яшәү кызык. Ашкыну. Шигырьләр. № 10.
Әхмәтҗанов Рәшит. Шигырьләр. № 7.
Шакиров С. Миләүшә. Бер легенда. Шигырьләр. № 8.
Яруллин Ф. Шигырьләр. № 8.

## ДУСЛАР ҖЫРЫ

Аппаз Х. Авыр еллар истәлеге. Борчуым. Ватан улы. Шигырьләр. № 8.
Бездә кунакта Ленинград шагыйрьләре. Шигырьләр. № 9.
Халид Р. Шигырьләр. № 6.
Хәйям Г. Шигырьләр. № 8.
Эралиев С. Йолдызларга сәяхәт. Поэмадан өзек. № 7.

## СОВЕТ ВЛАСТЕНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Аитов Л. Артистның тормыш юлы. Истәлекләр. №№ 6, 7, 8.
Дәүләтшин И. Идел өстендә таң. Очерк. № 2.
Румянцев Я. Ильич белән бергә. Мәкалә. № 4.
Рәхим К. Көрәш еллары. №№ 11, 12.
Урманчеев Ф. Совет чоры бәетләре. Мәкалә. № 6.
Шакир С. Безне онытмасыннар иде. Мәкалә. № 5.
Юсупов А. Полкташымның якты язмышы. Очерк. № 6.

## ОЧЕРКЛАР

Ахунов Г. Авыл сәхифәләре. № 3.
Беляев Р. Америкада 22 көн. № 1.
Максудова Ш. Башкортстан белән очрашу. № 9.
Мостафин Ф. Бәхетле кеше. № 8.
Мостафин Ж. Кечкенә булса да... № 8.
Рамазан Н. Төньяк күршеләргә сәяхәт. № 10.
Рәхимов Ж. Кобзарь бүген Тукай кунагы. № 10.
Сабитов Г. Һәр нигезнең тарихы бар. № 9.
Хәкимуллин Н. Европа тирәли. Фотоочерк. № 10.
Юдин В. Съезд делегаты. № 7.

## ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

Мостафин Р. Шигърият чишмәсе. С. Хәкимнең иҗат портретына эскизлар. № 11.
Мусин Ф. Нык адым белән. № 12.

## Г. ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Бикбай Б. Беренче укыган шагыйрем. Истәлек. № 4.
Бикбаев З. Минһаҗ кем иде? Истәлек. № 4.
Ганиева Р. Уртак кояшыбыз. Мәкалә. № 4.
Исәнбәт Н. Тукайның моңарчы чыккан җыентыкларына кермәгән кайбер шигырьләре. Мәкалә. № 4.
Исәнбаев С. Архив актарганда. Мәкалә. № 4.

Кайбицкая Г. Ул минем туган абыем кебек иде. Истәлек. № 4.
Сыздыков Җ. Син Җаекта канат кактың. Шигырь. № 4.
Сәгъдеваккасов Г. Уйгур әдәбиятына Г. Тукайның тәэсире. Мәкалә. № 4.
Туфан Х. Чәчәкләр китерегез Тукайга; Юл. Шигырьләр. № 4.
Халит Г. Бәхәссез һәм бәхәсле хакыйкатьләр. Мәкалә. № 4.
Халит Г. Г. Тукай хаты. Публикация. № 4.
Ханзафаров Н. «Печән базары яхут яңа Кисекбаш» һәм хәмсә, назирә традициясе. № 4.
Хикмәтуллин Г. Тукай турында исемдә калганнар. Истәлек. № 6.
Хәсәнов Х. Шагыйрь һәм патша цензурасы. Мәкалә. № 4.
Әхмеров Ш. Тукай һәм Сәйдәш. Истәлек. № 4.

## ФИКЕР АЛЫШУ, БӘХӘСЛӘР

Нуруллин И. Шагыйрьне өйрәнү юлында. Мәкалә. № 3.
Байчура Ш. Инәсеннән җебенә кадәр. Мәкалә. № 7.
Госман Х. Татар поэзиясе тарихында Тукайның урыны. Мәкалә. № 10.
Гайнуллин М. Дөреслекне төгәл яктыртыйк. Мәкалә. № 7.
Зәбиров Х. Тукайның тәрҗемәи хәле хакында берничә сүз. Мәкалә. № 9.
Нәфигов Р. Г. Тукай биографиясен өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре. Мәкалә. № 8.
Сафаров Р. Тукайга — яхшы тылмач. Мәкалә. № 7.
Халит Г. Бер бәхәс уңае белән. Мәкалә. № 9.
Редакциядән. Мәкалә. № 10.

## МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Алишев С. Көрәштәшләр. Истәлек. № 2.
Ахунов Г. Химкида җәлилчеләр. Мәкалә. № 2.
Баттал С. Син — политрук. Шигырь. № 2.
Бикбай Б. Күңел аша үткән яктылык. Истәлек. № 2.
Дудин М. Мәңгелек җыр. Шигырь. № 2.
Исхаков Ф. Аны комсомол тәрбияләде. Мәкалә. № 2.
Камалов Х. Синең язмышың. Шигырь. № 2.
Кашшаф Г. Аның шигырьләреме? Мәкалә. № 2.
Кәримуллин Ә. Шагыйрь турында чит ил матбугаты. Мәкалә. № 2.
Латыйп Г. Ромашкалар. Шигырь. № 2.
Мостафин Р. Талант һәм хезмәт. Мәкалә. № 2.
Максуд Х. Иптәш, дус һәм туган. Истәлек. № 2.
Салихов Х. Якташым. Истәлек. № 2.
Туфан Х. Европа өстендә Җәлил тавышы. Шигырь. № 2.
Таһиров Р. «Алман илендә» шигыре турында кайбер фикерләр. № 2.
Хузангай П. Син урнаштың дөнья күкрәгенә. Шигырь. № 2.
Юзиев Н. А. Фадеев һәм Җәлил. Мәкалә. № 2.
М. Җәлил турында совет язучылары. Фикерләр. № 2.

## К. БАСЫЙРОВНЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Гыйззәтуллин Н. Язучы истәлегенә. № 4.

## ЭЖЕН ПОТЬЕНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Э. Потье. Шигырьләр. № 12.

## Ш. РУСТАВЕЛИНЫҢ ТУУЫНА 800 ЕЛ

Руставели Ш. Автандилның күк яктырткычларына ялваруы. «Юлбарыс тиресе ябынган батыр» шигъри романыннан. № 9.

## Х. ФӘЕЗХАНОВНЫҢ ТУУЫНА 145 ЕЛ

Госманов М. **Олы мирас.** № 9.

## ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Әмирхан Ф. **Хатлар.** № 1.
Шамов А. **Бер кичәдә.** Истәлек. № 1.
Байчура Ш. **Татар яшьләре хәрәкәте һәм Ф. Әмирхан.** № 1.
Бәдәйли М. **Барысы да хәтердә.** Истәлек. № 1.

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Еники Ә. **Әдипнең терелеп кайтуы.** Мәкалә. № 11.
Ибраһимов Г. **Яңа табылган хат.** № 12.
Рәми И. **Якташым.** Истәлек. № 10.
Хаҗиәхмәтов Т. **Илһам чыганагы.** Иллюстрация һәм әдипнең үз фикерләреннән үрнәкләр. № 12.

## ГАБДУЛЛА КАРИЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Кумысников Х. **Якты йолдыз.** Мәкалә. № 5.
Тинчурина З. **Безнең Кариев.** Истәлек. № 5.
**Син безнең күңелләрдә.** Артист турында атаклы кешеләрнең фикерләре. № 5.

## Г. БАКИРОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Бакиров Г. **Авыл иртәсе.** Очерк. № 3.

## ЗЫЯ МАНСУРНЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Мәҗитов З. **Таләпчән художник.** Мәкалә. № 12.

## ӘХМӘТ ЮНЫСКА 50 ЯШЬ

**Ә. Юныска редакция котлавы.** № 12.

## М. ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Фәйзи М. **Хат һәм шигырь.** № 11.

## ИДЕЛ БУЕ «ГӨЛСТАН»ЫНА 575 ЕЛ

Госман Х. **Ерак гасырларның шигъри авазы.** Мәкалә. № 12.
Саран С. **Төрки «Гөлстан», тәрҗемәләр, назыйрәләр, шигырьләр.** № 12.

## НИЗАМИ ГАНҖӘВИНЕҢ ТУУЫНА 825 ЕЛ

Ганҗәви Н. **Явыз патша белән туры сүзле карт турында; Кибетче һәм төлке; Акылы булса; Чигенә җиттем җиһанның; Дүртьюллыклар.** Шигырьләр. № 10.

## СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

Гобәйдуллин Х. **Сабит Яхшыбаев.** № 3.
Гыйммранова Д. **Юлның дәвамы һәм зур хыяллар.** № 1.
Зөбәерова Д. **Гаҗәп һәйкәл сала.** № 6.

Латифуллин М. **Җырга салып хат җибәрәм. № 7.**
Рябков Г. **Театр яшьтәше. № 5.**
Файнберг А. **Художникның эзләнүе. № 9.**

## СӘНГАТЬ

Вәлиев Ф. **Халкыбызның чигү сәнгате.** Мәкалә. **№ 8.**
Гыймранова Д. **Сәхнә индивидуальлеге.** Мәкалә. **№ 3.**
Ключарев А. **Онытма.** Җыр. **Н. Дәүли** сүзләре. **№ 9.**
Мозаффаров М. **Туган як.** Җыр. М. Мазунов сүзләре. **№ 4.**
Җәләлиев Ә. **Тамашачы сүзе.** Мәкалә. **№ 4.**
Яхин Р. **Китмә, сандугач.** Җыр. **Г. Зәйнашева** сүзләре. **№ 7.**

## МОРАЛЬ ТЕМАГА

Гыйниятуллина А. **Тормыш баскычларын узганда.** Журналист язмалары. **№ 3.**

## ПУБЛИЦИСТИКА

Дунай Ф. **Экранда күрсәк икән. № 8.**
Мостафин М. **Актаныш ашлыгы. (Партиябезнең XXIII съездына.) № 3.**
Таҗетдинов Ә. **КПССның XXIII съезды һәм культура төзелеше мәсьәләләре. № 11.**
**Барган саен еллар яктырак.** Редакцион мәкалә. **№ 12.**

## ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ

Бәширов Г. **Каләмнең зур көче бар. № 11.**
Бәширов Г. **Без бөтен кешелек дөньясы алдында җаваплы.** Азия һәм Африка илләре язучыларының Баку киңәшмәсендә сөйләнгән речь. **№ 11.**
Сөләйманова С. **Ленинградта татар язучылары. № 2.**

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ганиев Ф. **Милли телләрнең функцияләре һәм үсү диалектикасы. № 7.**
Маннапов Ш. **Әнвәр Давыдов поэтикасы. № 7.**
Хатипов Ф. **«Ихтыярсыз» геройлар һәм кырыс дөреслек. № 9.**

## 1965 ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Әмир М. **Җыелышны ачу алдыннан. № 4.**
Мостафин Р. **Киң колачлы, тирән фикерле. № 4.**
Миннуллин Ф. **Без кичәсе үрләр. № 5.**
Маликов Ә. **Нәниләр өчен. № 5.**
Гыйззәтуллин Н. **Очерк — заман юлдашы. № 5.**
**Заман яхшырак әсәрләр сорый.** Информацион мәкалә. **№ 5.**

## ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Исәнбәт Н. **Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыркөйләре. № 11.**

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Билалов Ү., Тарасов А. **Иҗтимагый-политик карашлар үсеше буенча житди хезмәт. № 6.**
Иделле Г. **Иҗат җимешләре. № 7.**

Касыймов Э., Галиуллин Т. Гүзәл шигърият хәзинәсе. № 7.
Касыймов Э. Кояшны каршылап. № 9.
Киекбаев Г. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. № 8.
Миннегулов Х. Гади кешене олы итеп. № 6.
Мәһдиев М. Өлкән әдипнең тормыш сукмаклары. № 3.
Нурмөхәммәтов Т. Җыр белән очрашу өчен. № 6.
Садретдинов Ш. Үткәннәр белән очрашу. № 6.

## ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

Гатауллин Р. Шагыйрь күңеленә сәяхәт. № 7.
Гәрәй Р. Шагыйрьнең иҗат шатлыгы. № 9.
Садри М. Арфа моңнары. № 10.
Хуҗиев Г. Үрләргә күзем текәлгән. № 3.

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Биги Г. Шигырьләр. № 8.
Госманов М. Яңа табылган әдәби, тарихи истәлекләр. № 7.
Мәһдиев М. Солтан Рахманколыйның иҗат эшчәнлеге. № 11.
Һади Такташ хатлары. № 7.
Шакир А. Борынгы әдәбиятыбызны өйрәнүнең өлгергән проблемалары. № 6.
Шмаков А. Көньяк Уралның әдәби үткәне. № 8.
Яфаров Л. Киләчәккә өмет белән. № 8.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

Абилов Ш. Татар әдәбиятында Нәван. Мәкалә. № 6.
Г. Тукай премиясе лауреатлары. Редакция котлавы. № 6.
Беркутов В. Көн исемнәре. № 6.
Булатов Э. Ибраһим хан ярлыгын укуга карата кайбер фикерләр. Мәкалә. № 8.
Бәкер Ф. «Сәйяр» труппасы составында. Истәлек. № 10.
Гыйльманова Ф. «Тун» журналы. № 6.
Ишмөхәммәдов М. Ничек аңлаштылар икән? № 10.
Истәлекләр. № 8.
Кәримуллин Э. Әдәби мирас һәм библиография. Мәкалә. № 5.
Надиров И. Тукай — чит телләрдә. Мәкалә. № 10.
Мозаффаров Р., Гафаров Б. Халык тарихы — фольклорда. Мәкалә. № 8.
Нәбиуллин Р., Нәбиуллин М., Сәрвәретдинова Н. Сабан туйлары кызыклырак булсын. № 11.
Петров К. Чуваш журналистикасы Казанда туган. Мәкалә. № 1.
Рәми И. Мәдрәсәдән — университетка. Мәкалә. № 3.
Рәми И. Чәй һәм чәйчеләр. Мәкалә. № 7.
Саттаров Г. Шагыйрьнең исеме кем? Мәкалә. № 1.
Суркова В. Мөслимдә шулай эшлиләр. Мәкалә. № 9.
Тумашева Д., Якупова Г. Тюркологлар киңәшмәсе. Информация. № 1.
Фәсиев Ф. Исемнәр дөньясына сәяхәт. № 10.
Хәсәнова А. Безгә — кырык яшь. № 8.
Укучыларыбызга җавап. №№ 7, 10.
Урманчы Б. Ле Корбюзье вафат. Мәкалә. № 1.
Тузга язмаган спортчылар. № 6.
Иң-иң. № 3.

**Юбилярларны котлыйбыз.** № 9.
**Казан утларын балкытучылар.** № 4.
**Редакция сорауларына язучыларның җаваплары.** №№ 1, 2.

## ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ТИРӘСЕНДӘ

Г о б ә й Г. **Минем җаваплар.** № 12.
М а н н у р Ш. **Муса үзе сорады кебек.** № 5.

## САТИРА ҺӘМ ЮМОР

Б а т у л л и н Р. **Яшел пакет.** Хикәя. № 3.
Г а л и е в Ш. **Сөзгәк үгез маҗаралары.** Поэма. №№ 1, 2.
Г а л и е в Ш. **Дусларча шаярулар.** № 7.
Р а ф и к о в Б. **Аның хыялы; Иҗат үтте; Гаҗәпләнгән кычыткан; Белмәсен бала-чага; Швейцар фикере; Тиз өлгергән тел белгече.** Шигырьләр. № 10.
Х ө с н и Ф. **Сабан туе.** Хикәя. № 10.
Х ә м з и н К. **Проблемалы дәрес.** Хикәя. № 8.
Ш а м у к о в А. **Чүлмәкче белән исерек.** Шигырь. № 7.
Ш ә р ә п о в Ш. **Игелекле ир; Җаен тапты.** Шигырьләр. № 7.
Я х и н А. **Кыска хикәяләр.** № 3.

## УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ

Д и м с к а я Р. **Урал әкияте.** Шигырь. № 8.

**Яңа китаплар.** Кечкенә рецензияләр. №№ 5, 7, 9, 11.

**Укучылар сүзе.** №№ 1, 2, 3, 6, 8, 9.

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары.** №№ 1—11.

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/X-1966 ел. Басарга кул куелды 30/XI-1966 ел. ПФ 07205. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 35000. экз. Заказ Н-1492. Бәясе 40 тиен

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1966 ел.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73210

*Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ